Ниязетдин мулла
Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Балаларга пәйгамбәрләр тарихы

(Дәреслек итеп тәкъдим ителә)

Түбән Кама 2009

*Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи 1972 елның 31 маенда Башкортостан Җөмһүрияте Илеш районы Кадыр авылында туа. 1996 елда Башкортостандагы Октябрьский шәһәренең "Нуруль-Ислам" мәдрәсәсен тәмамлый. 1996-1998 елларда Татарстан Җөмһүрияте Түбән Кама шәһәрендә Үзәк Җәмигъ мәчете каршында "Рисәлә" мәдрәсәсен оештыра һәм шунда ук гарәп теле вә шәригать фәннәрен укыта. 1998-1999 елларда Түбән Кама шәһәренең Үзәк Җәмигъ мәчетенә имам-хатыйп итеп билгеләнә. 1999-2002 елларда Сәгуд Гарәбестанының эр-Рияд шәһәрендәге "Имам Мүхәммәд бин Сәгуд" җәмигасы (университеты) каршындагы "Мәгъһәд Тәглим әл-Лүгьа әл-Гарәбия" дип аталган, гарәп телендә сөйләшмәгән чит ил шәкертләре өчен, әзерлек институтын тәмамлый. 2002-2008 елларда эр-Риядтагы "Имам Мүхәммәд бин Сәгуд" җәмигасының "Усул әд-Дин" күллиясенең (факултетының) "Гакыйдә, Коръән һәм Сөннәт" буенча гомуми бүлекне, яхшы нәтиҗәгә тәмамлый.*

Бу китапны чыгаруда Аллаһ Раббыбызның ризалыгын өмет итеп, һәм дә динебезнең вә милләтебезнең үсешен теләп ярдәм иткән кардәшләребезнең гамәлләрен Аллаһ тәгалә кабул итеп, әҗер-савапларын бирсә иде.

**«Берәү Аллаһка бурычка биргән кебек яхшы эшләрне, изге гамәлләрне Аллаһ ризалыгы өчен генә кылса, Аллаһ ул мөэминнең әҗерен күп мәртәбә арттырыр. Аллаһ кайбер кешенең тормышын тар кылыр, кайбер кешенең тормышын киң кылыр. Хөкем өчен, әлбәттә, Аллаһка кайтасыз».** (Бәкара: 245)

**«Һәм Аллаһка изгелекне бурычка бирсәгез, ул вакытта, әлбәттә, бу изге эшләрегез бәрабәренә, яман эшләрегезне вә гөнаһларыгызны җуярбыз һәм әлбәттә, асларыннан елгалар агучы Җәннәтләргә кертербез».** (әл-Мәидә: 12)

بسم الله الرحمن الرحيم

# Кереш сүз

إن الحمد لله نحمده ونستعينه ونعوذ بالله من شرور أنفسنا ومن سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له ومن يضلل فلا هادي له وأشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له وأشهد أن محمدا عبده ورسوله، أما بعد.

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребез Мөхәммәднең (ﷺ) юлы. Шушы ике асыл белән өммәтебезнең әүвәлгеләре туры вә хак юлда булдылар. Ул ике асыл, бу дөньяда да, ахирәттә дә кешенең уңышка вә бәхеткә ирешү юлы. Кем дә кем аларга тотынса — туры юлда булды, ә кем алардан ераклашса, читләшсә — ул адашты вә хәсрәткә батты.

Хәзерге заманда бик күп балаларның үз диннәрен, телләрен белмәүләре, хәтта белсәләр дә ана телләрендә сөйләшергә оялулары, динебезгә муафыйк булмаган төрле кинофильмнар караулары, андагы әдәпсезлек белән шөгыльләнүчеләрнең исемнәрен, сүзләрен отып алулары, шулай ук динебезгә дә, милләтебезгә дә хас булмаган кабахәт әхлаклар белән тәэсирләнүләре, юньсез шигырьләр, җырлар ятлаулары һәм бик зур кызганычка каршы "безнең" дип әйтергә тел дә әйләнмәгән, кабахәт җәмгыятьнең тәрбиясе белән тәрбияләнүләре, мине ошбу кыйссаларны язарга мәҗбүр итте.


Аллаһ тәгаләнең ярдәме белән, мин үземнең көчемнән килгәнчә балаларыбызны ошбу юньсезлектән ерагайтыр-

га, һәм динебезгә, милләтебезгә якынайтырга дип ошбу кыйссаларны тәкъдим итәм. Мин бу пәйгамбәрләр кыйссасын, кадерле вә газиз балалар өчен җиңел вә аңлаешлы итеп һәм дә булдыра алганча кыскартып язарга тырыштым. Һәрбер пәйгамбәр кыйссасы азагында, балаларның аңлауларын ныгытыр өчен сораулар куйдым вә кыйссадан алынган кайбер файдалар һәм гыйбрәтләрне билгеләп уздым. Хәтта әти-әниләре дә балаларына бу матур вә сөйкемле кыйссаларны укып, кыйссалардан да һәм балаларының хаклыкны аңлап тормышта иманлы, ихсанлы булуларыннан да файда алырлар дим, иншәАллаһ. Алар бу кыйссалардан Аллаһ тәгаләнең кешеләрне вә җеннәрне ни өчен бар кылганын һәм ни өчен аларга пәйгамбәрләр җибәргәнен аңларлар.

Аллаһ тәгалә барчабызга һидәят-тәүфыйкъ бирсен. Кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп итсен.


Я Раббым, безне Үзеңнең туры юлыңнан алып бар, хакны хак итеп белгерт һәм безне хаклыкка якынайт, батылны батыл итеп белгерт һәм безне батылдан ерагайт, Коръән вә Сөннәткә тотынучылардан кыл һәм ихлас вә тәкъва бәндәләреңнән әйләп, Үзеңнең рәхмәтең белән Фирдәвес Җәннәтләреңә керт. Әмин.

Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи
Хатлар өчен: **mullaniyaz@mail.ru**



Аллаһы Тәгаләнең Гарәп ярымутравына жибәргән һәм Коръәндә язылган пәйгамбәр һәм рәсүлләре
Фарсы жирләре
Бәхрәйн култыгы
Оман култыгы
Оман
Гарәп ярымутравы
Һинд океаны
Гарәп диңгезе
Һуд галәйһис сәлам
Салих галәйһис сәлам
Адәм галәйһис сәлам
Ибраһим галәйһис сәлам
Шөгәйб галәйһис сәлам
Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм
Хадрамаут
Йәмән
Нәжрән
Мәккә
Ясриб (Мәдинә)
Шам жирләре
Тәбук
Әйләт
Синай
Урта диңгез
Кызыл диңгез
Мисыр жире
Судан жире
Төньяк
Көньяк
Көнчыгыш
Көнбатыш


Гыйрак җирлегенә килгән
һәм Коръәндә язылган
пәйгамбәр һәм рәсүлләр
Төньяк
Көнбатыш
Көнчыгыш
Көньяк
Мосул
Ассирия
Сөләймәния
Фарсылар
җире
Гыйрак
Евфрат елгасы
Шам (Сүрия)
чүле
Рамади
Багдад
Әл-Фәллүҗә
Бабил
Күфә
Тигр елгасы
Нух
Идрис
Юныс
Ибраһим
Басра
Бәхрәйн
култыгы


Аллаһы Тәгаләнең Мисыр җиренә
җибәргән һәм Коръәндә язылган
пәйгамбәр һәм рәсүлләре
Урта диңгез
Кәнган
җире
Әл-Хәлил
(Хеврон)
Үле диңгез
Искәндәрия
Думьят
Әл-Мансура
Әл-Гәриш
Исмагилия
Каһирә
Гелиополис
Әче
Күл
Мемфис
Хилвән
Синай чүле
Карун
күле
Әл-Фәйюм
Нил елгасы
Сүәеш (Суэц) култыгы
Гакаба култыгы
Мисыр
Тур өлкәсе
Катерин
тавы
Тур
Йосыф
Муса
Һарун
Кызыл диңгез




Шам илләренә һәм Фәлыстынга җибәрелгән һәм Коръәндә язылган пәйгамбәр һәм рәсүлләр

**Әссәламу галәйкүм кадерле балалар!**

Сез беләсезме икән, бу дөнья, җир-күкләр, елгалар, диңгезләр, фәрештәләр, җеннәр, кешеләр, хайваннар, кошлар, кояш-йолдызлар һәм башка бик күп безнең күзебезгә күренгән вә күренмәгән әйберләр ничек барлыкка килгәнен?

Ничек шул күкләрдә кошлар очып йөри, елгаларда батмыйча көймәләр йөзә, элекке заманаларда нинди кешеләр яшәгән, нәрсә белән шөгельләнгәннәр һәм гомүмән, ул вакытларда Ислам динен тотучылар булганмы, әллә бернинди дә дин булмаганмы?

Балалар! Моңа җавапны дөрес итеп, хәтта күп кенә зур абый-апалар да әйтә алмый. Шушыларга һәм башка бик күп сорауларга җавапларны без, Аллаһның илчеләре булган, Аның динен башкаларга җиткерүдә зур көч куйган пәйгамбәрләр дөньясына сәяхәт итеп таба алырбыз.

Нәниләрем! Якынрак килеп, бергәләшеп утырыгыз, һәм бик игътибар белән тыңлагыз! Пәйгамбәрләр тарихына булган сәяхәтебезне башлыйбыз.

# Адәм عليه السلام

Аллаһ Сөбханәһү вә тәгалә Үзенең иксез-чиксез көч-кодрәте белән җир-күкләрне һәм алар арасында булган һәрнәрсәне алты көндә халикъ кылгач, барча мәхлуклар Аның бөеклегенә сәҗдә кылдылар.

Шул мәхлуклар арасында фәрештәләр һәм җеннәр бар иде. Фәрештәләрне Аллаһ тәгалә нурдан ярат-ты. Алар Аллаһ кушканнарны гына үтәп, тыйганна-рыннан тыелып, һичбер гөнаһ кылмыйча һәрвакыт Аңа гыйбадәттә булулары белән билгеле булдылар. Ә җеннәрне Ул уттан яратты. Аларның кайберләре мөэминнәр, ә кайберләре кәферләр булып — икегә бүленделәр.

Аллаһ тәгалә әйтте (мәгънәсе): **«Ул — Аллаһ, җирдәге барча нәрсәне сезнең өчен халикъ кыл-ды, соңра күкне төзергә теләде һәм күкне җиде кат итеп төзеде. Ул һәр нәрсәне белүче. Һәм әйтте синең Раббың фәрештәләргә: «Мин җир өстендә хәлифә итеп Адәмне кылмакчымын». Фәрештә-ләр әйттеләр: «Әй Раббыбыз! Бозыклык кылу-чы, сугышып кан түгүче затны җир өстенә хәлифә кыласыңмы? Без исә Сине мактап тәсбихләр әйтәбез, һәм Сине һәр кимчелектән пакьсең дип игътикад итәбез». Аллаһ фәрештәләргә: «Дөреслектә, Мин сез белмәгәнне беләмен», — диде».** (Бәкара: 29 – 30)

Адәм галәйһиссәламне Аллаһ тәгалә балчыктан яратты һәм шуның өчен дә балалар, кеше үлгәч аны җиргә күмә торган булдылар.

Шулай итеп, нәниләрем, Адәм галәйһиссәлам балчыктан, фәрештәләр нурдан, җеннәр уттан яратылган булып чыкты.

Аллаһ тәгалә Адәм галәйһиссәламне бар кылгач, фәрештәләргә Адәм галәйһиссәламне ихтирам итеп сәҗдә кылырга боерды. Барча фәрештәләр Аллаһның әмеренә буйсынып Адәм галәйһиссәламгә хөрмәт сәҗдәсе кылдылар, бары тик, алар арасында булган иблис исемле бер җен генә Аллаһның әмеренә каршы килеп, Адәм галәйһиссәламгә хөрмәт сәҗдәсен кылмады һәм шул гамәле белән ул Аллаһка мәңгелек дошманлык кылды.

Аллаһ тәгалә Адәмне, аның балаларын вә барча кешеләрне — бер Үзенә генә гыйбадәт кылып, Исламга, хаклыкка өндәр өчен барлыкка китерде.

Шуннан соң Аллаһ тәгалә Үзенең кодрәте белән Адәм галәйһиссәламгә барча нәрсәләрнең исемнәрен өйрәтте (мәсәлән: фәрештәләр, җенннәр, җимешләр, елгалар вә башкалар) һәм фәрештәләргә: «Миңа шушы нәрсәләрнең исемнәрен белгертегез», — диде. Фәрештәләр: «Бездә һич белем юк, мәгәр Син белдергәнне генә беләбез, Син әлбәттә, һәрнәрсәне белүче гыйлем һәм һәрнәрсәне үз урынына куя белүче хикмәт иясе», — диделәр. Аллаһ Адәмгә шул әйберләрнең исемнәрен әйтергә кушкач, ул әйтеп бирде.

Раббыбыз бу күренеш хакында Коръән Кәримдә менә ничек диде балалар (мәгънәсе): **«Ул — Аллаһ, Адәмгә бар нәрсәнең исемнәрен өйрәтте, шуннан соң шул нәрсәләрне фәрештәләргә дә күрсәтте һәм аларга: «Әгәр сүзегезне дөрес дисәгез, Миңа боларның исемнәрен әйтеп күрсәтегез», — диде. Фәрештәләр Аңа: «Әй Раббыбыз, барча кимчелектән пакьлегеңне раслыйбыз, Син өйрәткән гыйлемнән тыш, без башка гыйлемгә ия түгел, хакыйкатьтә, Син — бар нәрсәне белеп торучы гыйлем иясе, һәрнәрсәне үз урынына куя белүче хикмәт иясе», — диделәр. Шулчак Аллаһ: «Әй Адәм! Син фәрештәләргә боларның исемнәрен хәбәр ит», — диде, Адәм аларга бар исемнәрне хәбәр иткәч, Аллаһ аларга: «Мин сезгә күкләрдә һәм җирдә яшерен булган нәрсәләрне белүемне әйтмәдемме әллә? Мин бит сезнең ачыктан-ачык әйткәнегезне дә, әйтмичә яшереп калдырганыгызны да беләм», — диде. «Адәмгә сәҗдә кылыгыз», — дип фәрештәләр-гә Аллаһ әйткәч, һәммасе сәҗдә кылдылар, иллә-мәгәр иблис кенә инкяр итте вә тәкәбберләнде һәм кәферләрдән булды».** (Бәкара: 31 – 34)

Мәгънәсе: «Аллаһ тәгалә әйтте: **«Әй иблис, Мин Үземнең ике кулым илә яраткан Адәмгә сәҗдә кылудан сине нәрсә тыйды? Тәкәбберләндеңме? Яки бөекләрдән булдыңмы?». Иблис әйтте: «Мин Адәмнән яхшыракмын, чөнки мине уттан, ә Адәмне исә балчыктан халикъ кылдың». Аллаһ әйтте: «Алай булса Җәннәттән чык, тәхкыйк, син рәхмәтемнән сөрелмешсең. Әлбәттә сиңа Кыямәт**

**көненә чаклы Минем ләгънәтемдер».** (Сад: 75 – 78)

Иблис Җәннәттән ачуланып чыгып китте. Хәтта эшләгән гөнаһасы өчен, тәкәбберлеге аркасында тәүбә итәргә дә теләмичә, киресенчә Адәм галәйһиссәламгә һәм аның балаларына Кыяматкә кадәр явызлык эшләп, туры юлдан яздырырга уйлады. Шушы мәкерлегән гамәлгә ашыру өчен, Аллаһтан аны Кыяматкә кадәр калдыруын ялварып сорады. Аллаһ тәгалә иблиснең ялваруына уңай җавап биреп, аның вә аңа ияргәннәрнең Җәһәннәмгә керәчәген әйтте. Ә инде гөнаһ эшләп тәүбә иткән мөселманнарны, иблискә ияреп кәфер булмасалар, Җәннәткә кертәчәген белдерде.

Аллаһ тәгалә Адәм галәйһиссәламне халык кылып Җәннәткә керткәч, ул анда ашап-эчеп, Җәннәт нигъмәтләре белән нигъмәтләнеп ялгыз гына яши башлады. Ялгызлыгын уртаклашырга аның хатыны да, балалары да юк иде. Чөнки ул, Аллаһ халык кылган кешеләр затыннан беренчесе булды.

Көннәрдән бер көнне уянып киткәч, Адәм галәйһиссәлам үзенең янында бер хатын-кызның утырганын күреп:

– Син кем?, — дип сорады. Ул хатын бик әдәп һәм тыйнаклык белән генә:

– Мин Хәва, — дип җавап бирде.

Аллаһ аны Адәм галәйһиссәламгә иптәш булсын өчен, Адәмнең кабыргасыннан халык кылды. Аллаһ тәгалә биргән бу нигъмәткә Адәм галәйһиссәлам бик

ныk шатланып сөенде һәм Раббысына шөкраналар кылды.

Балалар, белегез ки! Әгәр бәхет-шатлык килсә, мөэмин-мөселман һәрвакыт Аллаһны бөекләп — шөкраналар кыла, ә кайгы-хәсрәт килсә, Раббысының аңа биргән сынавы дип, сабыр итә.

Инде балалар, без Адәм галәйһиссәлам белән Хәваның ничек барлыкка килүләрен белдек, ә хәзер аларның алга таба ничек тормыш иткәнен тыңлагыз.

Аллаһ тәгалә Адәм галәйһиссәлам белән Хәвага Җәннәттә булган барча нигъмәтләр белән ләззәтләнергә рөхсәт биргәннән соң, бер агачның җимешләрен ашаудан тыелып, иблис явызның мәкерлегеннән сакланырга кушты. Шушы тыюны ләгънәт төшкере булган иблис белеп калып, Адәм галәйһиссәлам белән Хәваны хәйлә белән алдалап, ялганлап тыелган агачтан ашатты. Алар ялгышып хата эшләгәннәрен аңлагач, Раббыларыннан гафу сорап тәүбә кылырга ашыктылар.

Бу күренеш хакында Аллаһ тәгалә Коръәндә болай ди (мәгънәсе): **«Тәхкыйк, Без сезне халикъ кылдык, соңра күркәм сурәтле иттек, моннан соң фәрештәләргә әйттек: «Адәмгә сәҗдә кылыгыз», — дип, фәрештәләр Адәмне хөрмәтләп сәҗдә кылдылар, иллә-мәгәр иблис кенә сәҗдә кылучылардан булмады. Аллаһ тәгалә әйтте: «Әй иблис! Мин сине Адәмгә сәҗдә кылырга әмер иткәч, сине сәҗдә кылудан ни нәрсә тыйды?». Иблис әйтте: «Мин аңардан яхшырак, чөнки Син мине уттан, ә Адәмне балчыктан яраттың». Аллаһ әйтте:**

«Алай булса, Җәннәттән чык! Аллаһның кушканына карышып Җәннәттә сиңа тәкәбберләнү һич мөмкин булмас, чык аннан, хур вә рисвайлар җөмләсеннәнсең». Иблис әйтте: «Әй Раббым, мине кубарылачак көнгә кадәр кичектер». Аллаһ әйтте: «Әлбәттә, син мәгълүм вакыткача рөхсәт бирелүчеләрдәнсең», — дип. Иблис әйтте: «Адәм өчен мине аздырганың өчен, әлбәттә, бәндәләреңне алдап аздырмак өчен туры юлың өстендә утырачакмын. Янә аларны аздырмак өчен алларыннан да, артларыннан да һәм уңнарыннан да, сулларыннан да килермен. Шуннан соң аларның күбрәген шөкер итүчеләрдән тапмассың». Аллаһ тәгалә әйтте: «Бозылганың вә рәхмәттән сөрелгәнең хәлдә — чык Җәннәттән! Кешеләрнең сиңа ияргәннәре белән бергә һәммәгезне салып Җәһәннәмне тутырачакмын. Аллаһ әйтте: «Әй Адәм, үзең вә хатының — Хәва, Җәннәттә торыгыз вә теләгән урыннан ашагыз, әмма ошбу агачка якын бармагыз, әгәр якын барсагыз — залимнәрдән булырсыз». Шәйтан аларның ябык гаурәтләрен ачмак өчен вәсвәсә кылды һәм әйтте: «Аллаһ сезнең фәрештә булуыгызны теләмәгәне өчен, яки Җәннәттә мәңге калуыгызны теләмәгәне өчен, сезне ошбу агачтан тыйды. Тәхкыйк, мин сезгә яхшылыкны телимен», — дип ант итте иблис. Алдап аларны агачка якын китерде. Алар агачтан ашадылар, гаурәтләре ачылды вә Җәннәт яфраклары белән гаурәтләрен капларга ашыктылар, аларга Раббылары дәште: «Мин сезне ошбу агачтан тыймадыммы? Вә тәхкыйк —

**шәйтан сезгә ачык дошман, сакла624ыгыз, — дип әйтмәдемме?». Адәм вә Хәва: «Әй Раббыбыз, үзебезгә золым кылдык, әгәр безне ярлыкамасаң һәм безгә рәхмәт кылмасаң, әлбәттә, хәсрәткә калучылардан булачакбыз», — дип әйттеләр. Аллаһ әйтте: «Әй Адәм белән иблис, бер-берегезгә дошман булганыгыз хәлдә җиргә иңегез! Сезгә торачак урын һәм әҗәлегезгәчә файдаланачак җай җирдә». Аллаһ әйтте: «Җирдә тереклек итәрсез вә җирдә үләрсез һәм җирдән чыгарылырсыз».** (Әгъраф: 11 – 25)

Аллаһ Адәм илә Хәваның тәүбәсен кабул итеп шәйтаннан сакланырга кушты, чөнки ул үзенең мәкерлеген Кыяматкә кадәр дәвам итәчәген белгерткән иде инде.

Шуннан соң Аллаһ тәгалә Адәм белән Хәваны Җәннәттән чыгарып җиргә төшерде. Ибен Сәгъд, ибен Гасәкир тарих китапларында һәм Суюутый тәфсирендә ибен Габбастан риваять кылулары буенча, Адәм عليه السلام Һиндстан (Индия) җиренә, ә Хәва Җиддә җиренә төшерелгәч, Адәм عليه السلام аны эзләп Мәккә җирләренә килде һәм алар Мөздәлифәдә кавыштылар.

Ибен Габбастан тагын бер риваятьне имам Табари үзенең тарих китабында болай китерә: «Адәм Һиндстан (Индия) җиренә төшерелгәч Хәваны эзләп (гарәп ярымутравына) килде һәм алар Мөздәлифәдә кавыштылар, ә Гарәфә җирендә бер-берсен белештеләр».




Адәм галәйһиссәлам, Мәккә Мөкәррәмә һәм Җиддә урыннары.

Шулай ук, бу хакта башка риваятьләр дә бар һәм аларның барысыннан да, Адәмнең Һиндстан җирендә төшеп, Хәва белән хәзерге Мәккә урыннарында очрашулары аңлашыла.

Адәм белән Хәва җирдә очрашкач, Раббыларына гыйбадәттә булып бик матур тормыш итә башладылар. Аллаһ тарафыннан бирелгән гакыл белән алар үзләренә йорт кордылар, ау кораллары ясап җәнлекләрне ауладылар һәм ерткыч хайваннардан саклана торган булдылар.

Аларның беренче ике игезәк балалары туып, берсе малай, ә икенчесе кыз булды. Малайны «Кабил» дип исемләделәр. Ул балалар әти-әнисенең кочагында, Аллаһка гыйбадәт кылып, Раббыларының кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә һәм иблиснең мәкерлегеннән вә аңа иярмәскә кирәклеген белеп тәрбияләнеп үстеләр.

Бераз вакыт узгач, Адәм галәйһиссәлам белән Хәваның тагын ике игезәк баласы дөньяга килде. Аларның шулай итеп дүрт баласы — ике малай вә ике кыз булды. Әйтүебезчә, беренче улының исеме «Кабил» булса, ә икенчесенә «Һәбил» дип исем куштылар. Кабилне Адәм галәйһиссәлам җир эшенә, ә Һәбилне сарык көтәргә өйрәтте һәм алар үзләренә йөкләнгән ошбу гамәлләр белән көн итә торган булдылар.

Шулай итеп көннәр, айлар, еллар узды. Адәм галәйһиссәлам белән Хәва үзләренең шундый матур тормыш итүләренә шатланып бетә алмадылар. Ләкин, Кыяматкә кадәр вәсвәсә кылырга мөмкинчелек

бирелгән шәйтан, ничек тә булса кешеләрнең шатлыклы тормышларына комачауламакчы булып үзенең кабахәт мәкерлек ятьмәләрен үрә башалды. Көннәрдән бер көнне, аңа мәкерлеген тормышка ашырырга насыйп булды. Ул хәл менә ничек булды нәниләрем.

Бер көнне, Кабил (Адәм галәйһиссәламнең зур улы) үзенең игезәк кыз туганына өйләнергә сорады. Аллаһ тәгалә Адәм галәйһиссәламгә Кабилне — Һәбилнең игезәк кыз туганына, ә инде Һәбилне — Кабилнең игезәгенә өйләндерергә дип белгерткән иде.

Һәбил Аллаһның әмеренә итагать итеп ризалыгын белдерде, чөнки ул, Раббысының бу дөньяда булган һәрнәрсәне Аңа итагать итәр өчен яратканлыгын белә иде. Бу низагтан шәйтан файдаланып, Кабил белән Һәбил арасына фетнә салмакчы булды. Кабил үзенең игезәк кыз туганына өйләнер өчен, энесенә каршы мәкерлек уйлый башлады. Адәм галәйһиссәлам бу низагны белеп, ике улына да Аллаһ тәгалә өчен корбан китерергә кушты, һәм кемнең корбаны кабул булса — кыз шуныкы булыр, диде.

Кабил, шәйтан вәсвәсәсе һәм үзенең саранлыгы белән, бик начар, бозылган җимешләрне алып килде. Һәбил инде Раббысына гөнаһ эшләүдән куркып, иң яхшы сарыктан корбан бирде. Аллаһ Һәбилнең тәкъвалык һәм ихлас күңел белән биргән корбанын кабул итте, чөнки Ул — тәкъваларның гамәлләрен юкка чыгармый, ә инде Кабилнең корбаны кабул булмады.

Кабилнең корбаны кабул булмагач, аның йөрәге Һәбилгә карата тагын да күберәк ачу белән тулды һәм аны үтерергә карарлады. Һәбил моны белеп абыйсына: «Әй абыем, бу бит Аллаһның әмере вә тәкъдире белән, шуның өчен безгә моңа риза булырга кирәк, син мине үтерергә уйлама, чөнки мин бит синнән көчлерәк һәм сине алдан үтерә алам, ләкин сине үтерергә риза булмыйм, син минем абыем һәм Аллаһ каршында гөнаһлы буласым килми», — дип кисәтте. Кабил инде энесенең әйткәненә игътибар да итмичә, шәйтан вәсвәсәсенә бирелеп, үзенең бертуган энесенең башына нәрсә беләндер бик каты итеп сугып үтерде. Иблис шушы мәкерлеге белән Кабилне җир йөзендә иң беренче җинаятькә этәрә алганы өчен, аңардан явыз рәвештә көлде.

Кабил эшләгән гөнаһына бик үкенде. Шунда Аллаһ тәгалә аның янына карга җибәрде. Ул карга Кабилгә җирне казып күрсәтте, ягъни Һәбилнең гәүдәсен күмәргә өйрәтте. Үлгән энесенең гәүдәсен нишләтергә белмәгән Кабил, шушы каргадан өйрәнеп Һәбилне җиргә күмде.

Бу хакта Коръән Кәримнең «әл-Маидә» сүрәсенең 27 – 31нче аятьләрендә болай диелде (мәгънәсе): **«Аларга Адәм галәйһиссәламнең уллары хакындагы хак хәбәрне укы. Алар икесе дә корбан китергәч, берсенеке, ягъни Һәбилнеке кабул булды, икенчесе — Кабилнеке кабул булмады. Кабил әйтте: «Әй Һәбил, мин сине, әлбәттә, үтерәчәкмен», — дип. Һәбил: «Әлбәттә, Аллаһ тәгалә тәкъва кешеләрнекен кабул итә. Әгәр син мине үтерергә кулыңны суза торган булсаң да,**

**мин сине үтерергә кулымны сузачак түгелмен. Мин бөтен галәмнәрнең Раббысы булган — Аллаһтан куркамын. Әгәр мине үтерсәң, син минем гөнаһымны һәм үз гөнаһыңны йөкләп Аллаһка кайтуыңны телимен, бу золым эшеңне эшләсәң ут әһеленнән булырсың. Ут газабы — залимнәргә тиешле җәзадыр». Кабилнең нәфесе Һәбилне үтерергә этәрде, Кабил Һәбилне үтерде вә хәсрәтләнүчеләрдән булды. Аллаһ Кабил янына бер карга җибәрде, ул карга Һәбилнең гәүдәсен күмәргә өйрәтеп, җирне казып күрсәтте (Чөнки Кабил Һәбилне үтергәч кайда куярга белмичә, берничә көн күтәреп йөрде). Карганы күргәч, Кабил әйтте: «Һай миңа үкенеч! Абыемның гәүдәсен яшерүдә мин әллә шушы карга кебек тә булдыра алмыйммы?», — дип һәм шулай ул үкенүчеләрдән булды».**

Шулай итеп, балалар, җир йөзендә иң беренче кан түгелде һәм бу җинаятьтне шәйтан вәсвәсәсенә бирелеп Кабил ясады.

Газизләрем! Шәйтаннан вә аның мәкерле эшләреннән бик тә сак була күрегез! Чөнки ул кешегә ачык дошман!

Адәм галәйһиссәлам үзенең соңгы көннәрендә балаларын, оныкларын җыеп, араларында булган Шис исемле абыйларын тыңларга вәсыять итеп калдырды һәм вафат булды.

Инде Адәмнең عليه السلام кабере кайда икәнлегенә килгәндә, кемнәрдер аны Мәккәдәге Әбү Кубәйс тавында күмелгән дисәләр, башкалар Кудста яки

Гарәфәдә яки инде Һиндстанда (Индия) булуы мөмкинлеген дә әйтеп уздылар. Ничек кенә булсада, бу мәсьәләләрне төпченүдән безгә файда юктыр, балалар. Аллаһ тәгалә һәрнәрсәне белүчерәк.

Кадерлеләрем! Шушының белән Адәмнең ﷵ кыйссасын тәмамлап, икенче пәйгамбәр тормышына сәяхәт башлаганчы, мин сезгә ошбу кыйссадан алырга мөмкин булан кайбер файдаларны әйтеп узам һәм сезнең аңлаганлыгыгызны төшенер өчен берничә сорау бирәм:

**Беренче:** Ошбу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Һәрбер нәрсә Аллаһның кодрәте белән барлыкка килә, Аннан да бөек һичбер зат юк.

**2)** – Аллаһ тәгалә кешене балчыктан, фәрештәләрне нурдан, җеннәрне уттан яратты.

**3)** – Аллаһ тәгалә Адәм балаларын җирдә хәлифә кылды.

**4)** – Фәрештәләр Адәм галәйһиссәламгә хөрмәт сәҗдәсе кылды.

**5)** – Аллаһка буйсынмау — Аның рәхмәтеннән сөрелмешкә сәбәп.

**6)** – Эшләгән гөнаһка үкенеп Аллаһтан гафу сорау, Аллаһның ризалыгына ирешүгә сәбәп.

**7)** – Дошманнар зарар китермәсен өчен, мөселманнарга бик уяу булып шәйтаннан ерак булырга кирәк.

**8)** – Тәкәбберлек һәм хөсетлек — изгелекләрдән ерагайтып, хәсрәтле нәтиҗәләргә илтә.

**Икенчесе:** Үз-үзеңнең тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Ни өчен Аллаһ Адәм галәйһиссәламне халикъ кылды?

**2)** – Ни өчен Аллаһ тәгалә иблисне Үзенең рәхмәтеннән сөрде?

Дөрес җөмлә артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата җөмлә артына (Х) ошбу билгене куй:

**1)** – Фәрештәләрне Аллаһ нурдан яратты ( )

**2)** – Аллаһ тәгалә бу галәмне кеше файдасы өчен булдырды ( )

**3)** – Шәйтан Адәм галәйһиссәламне алдалап, Аллаһ тыйган агачтан ашатты ( )

**4)** – Кабил үзенең энесе Һәбилне, Адәм галәйһиссәламнең әмере белән үтерде ( )

**5)** – Аллаһ тәгалә Кабилгә, энесен күмергә өйрәтер өчен карга җибәрде ( )

Буш урыннарга дөрес сүзләр куеп җөмләләрне тулыландыр:

**1)** – ____________ тәгалә _________________ нурдан яратты, кешеләрне ______________ яратты, ә җеннәрне ____________________ яратты.

**2)** – _________________ үзенең энесе Һәбилне, ______________ вәсвәсәсенә ияреп үтерде.

**3)** – Аллаһ Адәмне хөрмәтләп фәрештәләргә ____________ кылырга әмер итте, фәрештәләр барчасы да сәҗдә кылды, бары тик ____________ кенә сәҗдә кылмады.

# Идрис عليه السلام

Адәм галәйһиссәламнең балалары күбәеп, алар арасында изге-салихлары һәм хаклыктан ераклашып, Аллаһны онытып иблискә иярүчеләре дә булды. Аллаһ тәгалә Идрис галәйһиссәламне адашканнарны туры юлга чакырыр өчен, кешеләр арасыннан пәйгамбәр итеп сайлады.

Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Янә Коръәннән Идрис галәйһиссәламне сөйлә, хакыйкатьтә, ул гаять хакны сөйләүче иде һәм пәйгамбәр булды. Вә Без аны югары урынга күтәрдек. Алар шулардыр — кемнәргә Аллаһ нигъмәт кылды, Адәм балаларыннан булган вә Нух белән коткарылган, шулай ук Ибраһим вә Исраиль балаларыннан булган пәйгамбәрләр һәм Без сайлаган вә туры юлга күндергәннәр. Әгәр аларга Коръән аятьләре укылса, сәҗдәгә китәләр вә елыйлар».** (Мәрьям: 56 – 58)

Аллаһ аны мактап вә дөреслекне генә сөйләүче кеше итеп һәм пәйгамбәр итеп сыйфатлады.

Идрис عليه السلام Адәм һәм Шис галәйһиссәламнәрдән соң килүче пәйгамбәр иде. Ибен Исхак исемле галим аны иң беренче каләм белән язуны башлаучы һәм ул Адәм галәйһиссәламнең тормышыннан 308 елын күрде, дип әйтеп узды.

Коръәндә: **«Без аны югары урынга күтәрдек»,** — дигәне, ул пәйгамбәребезнең ﷺ Исра вә Мигъраҗ кичәсендә Идрис عليه السلام белән күкнең дүртенче катында очрашуыдыр. Аңарга без сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ тарихында тукталырбыз.

Тәфсир галимнәре әйтүенчә, аның хакында бик күп хикәяләр бар, әмма аларның дөреслеге билгеле түгел. Шуның өчен дә балалар, без ул хикәяләргә тукталып тормыйбыз һәм Идрис галәйһиссәлам хакындагы кыйссабызны шушында тәмамлыйбыз.

Инде балалар, мин сезгә берничә сорау бирермен:

**1)** – Аллаһ тәгалә Коръәндә Идрис галәйһиссәлам хакында нәрсә әйтте?


**2)** – Идрис галәйһиссәлам нинди пәйгамбәрләрдән соң килде?

**3)** – Тәфсир галимнәре Идрис галәйһиссәлам хакында нәрсә әйтә?




Идрис галәйһиссәламнең Бабилдәге урыны, аның Мисырга күченүе

Идриснең عليه السلام кайда тууы хакында тарихчылар берничә карашта. Берәүләре аны Мисырда туды дип әйтсә, икенчеләре Идрис عليه السلام Гыйракта Бабил шәһәрендә туды диделәр. Зур яшькә җитеп пәйгамбәрлек килгәч, аңа иман китергән бик аз кешеләр белән Мисырга күчте һәм анда ул кешеләрне бер Аллаһка гыйбадәткә чакырып, ширектән сакланырга боерды.


Идрис галәйһиссәлам
Ярид
Миһләиэл
Кыйнан
Анүш
Шис
Адәм галәйһиссәлам
(Бар кешеләрнең атасы)
Идрис галәйһиссәламнең нәселе

# Нух عليه السلام

Адәм عليه السلام вафат булганнан соң бик күп еллар узып, кешеләр саны да шактый арткач, күбесе үзләренең Раббыларыннан ераклашып аларны халикъ кылучыны вә ризыкландыручыны онытa төшкәч, зур хаталарга вә гөнаһларга бата башладылар. Араларыннан бик азы гына туры юлда калып, башкаларны да хаклыкка чакырып, үгет-нәсыйхәт кылдылар. Шул замандагы ихлас вә изгелек белән билгеле булганнар — Вәд, Сүвагъ, Йәгус, Йәгук, Нәсер вафат булганнан соң, кешеләр динннән ераклашып Аллаһны гомүмән оныттылар.

Шушы форсаттан файдаланып, шәйтан ләгънәт төшкере, шул изге кешеләрне башкаларга «иләһ» итеп тасвирлый башлады. Җәһиллекләре (гыйлемсезлекләре) сәбәпле туры юлдан язган кешеләр шәйтанннның мәкерлегенә алданып, шул үлгән кешеләрне үзләренә «иләһ» итеп алдылар. Аларның сыннарын ясап, Аллаһтан тыш шул потларга табына башладылар. Шулай итеп җир йөзендә Раббул-Гыйззәгә ширек таралды.

Әлбәттә, белүебезчә Аллаһның рәхмәте киң һәм Ул бәндәләргә туры юлны күрсәтүчене җибәрмичә калдырмый. Аллаһ тәгалә хак юлны күрсәтүче итеп, шул кавемнәр арасыннан изгелеге, тәкъвалыгы белән

билгеле булган Нух галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрде.

Нух галәйһиссәлам балта остасы иде. Ул үзенең Аллаһ тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр икәнен белгәч, кешеләрнең потларга табынуларын инкяр кылып, фәкать бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга өнди башлады. Аларның үзләренә «иләһ» итеп алган потларының файда да, зыян да итә алмаганнарын аңлатты. Аллаһтан тыш бернәрсәнең дә һич нинди көчкә ия булмаганлыгын дәлилләр белән ачык бәян кылса да, азгынлыкта булган кешеләр аның дәгъватын кире кактылар. Шуңа карамастан да, Нух галәйһиссәлам аларны көнен дә, төнен дә, ачык рәвештә дә, яшерен итеп тә бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга кирәклегенә өндәвеннән туктамады.

Инде тиешле нәтиҗәгә китермәгәч, ул Раббысына ялварды (мәгънәсе): **«Нух әйтте: «Әй Раббым, кавемемне ислам диненә кичләрен дә вә көндезләрен дә чакырдым. Минем өндәвем аларны ислам диненнән качуны гына арттырды. Әй Раббым, һәркайчан мин аларны Синең ярлыкавыңа, гафу итүеңә чакырсам, минем сүземне ишетмәс өчен бармакларын колакларына тыгалар һәм киемнәренә бөркәнәләр вә көферлектә дәвам итеп каты тәкәбберләнү илә тәкәбберләнәләр».** (Нух: 5 – 7)

Нух галәйһиссәлам кавеменнән бик күп җәфалар күрде. Аны төрле җәзалар, газаплар белән җәберләп аңардан көлделәр, мыскыл иттеләр (мәгънәсе): **«Кавеменең кәфер булган олуглары әйтте: «Әй**

**Нух, син безнең кебек адәмсең, бездән артык җирең юк, дәхи сиңа ияргән кешеләр дә арабызда иң түбән кешеләрдер һәм безгә караганда сездә дә бернинди артыклык күрмибез, бәлки без сезне ялганчылар дип уйлыйбыз».** (Һуд: 27)

Ягъни аңа: «Әй Нух, сиңа бары тик фәкыйрьләр, мескеннәр генә ияреләр, әгәр дә безнең сиңа иярүбезне теләсәң, ул фәкыйрь-мескеннәрне куып җибәр, аларны үзеңә якын да китермә, чөнки без алар белән бергә утыра алмыйбыз», — дип аны түбәнсеттеләр.

Нух галәйһиссәлам аларның бу сүзләренә колак салмады. Чөнки Аллаһ каршында байлар да, фәкыйрьләр дә, түрәләр дә, гадиләр дә, мескеннәр дә, барсы да бертигез икәнен белә иде. Кешеләрне йомшак тел вә хикмәт белән Аллаһ диненә чакыруын дәвам итте. Аларны Аллаһның газабы, хисап көне, Җәһәннәм уты белән куркытты.

Мөшрикләр Нух галәйһиссәламнән көлүләрен дәвам иттеләр. Аны мыскыл итеп: «Син безнең кебек үк фәкыйрь һәм зәгыйфь бер бәндәсең, ни өчен Аллаһ сине пәйгамбәрлеккә сайлады, ә безне юк?», — дип мәсхәрәләделәр. Хәтта алар үзләренең азгынлыклары белән Аллаһ тәгаләгә дә сүз тидерделәр. Нух галәйһиссәлам аларга: «Аллаһ — Ул, һәрнәрсәне белүче һәм һәрнәрсәгә көче җитә, пәйгамбәрлеккә теләгән хәерле бәндәсен сайлый», — дип җавап биргәч, ул кавем тагын да ныграк ачуланып (мәгънәсе): **«Хакыйкатьтә, без сине ачык адашуда дип күрәбез», — диделәр».** ( Әгъраф: 60)

Кавеме Нух галәйһиссәламне адашуда гаепләп, аны мәҗнүн дип, аның үзен дә, аңа иярүчеләрне дә бик нык рәнҗетеп иза кылудан һич туктамадылар.


Шуңа карамастан, ул Аллаһка чакыруын дәвам итте. Шулай итеп 950 ел узды һәм шушы еллар эчендә аңарга бик аз кеше генә иман китерде. Раббысы аңа вәхи кылды (мәгънәсе): **«Дәхи, Нухка вәхи булды: синең кавемеңнән иман китерәселәре иман китерделәр, ә инде калганнары иман китермәсләр, аларның кылган кабахәт эшләре өчен кайгырма!».** ( Һуд: 36)

Ул үзенең хатынын да баласын да иманга чакырды, әмма алар аны кире кагып көферлектә калдылар. Шуннан соң Нух عليه السلام, потларга табынып ширеккә баткан мөшрикләрнең вә кәферләрнең юкка чыгуын сорап Аллаһка дога кылды (мәгънәсе): **«Нух әйтте: «Әй Раббым, җир өстендә кәферләрне һич калдырма, һәммәсен һәлак ит! Әгәр Син аларны җир өстендә тере калдырсаң, алар синең бәндәләреңне адаштырырлар һәм алар яхшы бала тудырмаслар, мәгәр явызны вә хакны инкяр итүчене генә тудырырлар. Әй Раббым, мине ярлыка вә мөэмин булган ата-анамны ярлыка һәм минем өемә яки көймәмә мөэмин булып кергән кешене ярлыка һәм дә барча мөэмин ирләрне вә мөэминә хатыннарны ярлыка! Һәм залим кәферләргә һәлак булуларын гына арттыр!».** (Нух: 26 – 28)


Аллаһ тәгалә аның догасын кабул итте һәм аңа көймә ясарга әмер кылды. Нух галәйһиссәлам үзенә иман китергән аз санлы кешеләр белән бергә көймә ясый башлагач, кәферләр аларның яныннан узган

саен аңа: «Кара әле, син элгәре пәйгамбәр идең бит, ә хәзер инде балта остасы булдыңмени? Ха-ха. Карагыз әле бу җүләрне, сусыз коры чүл өстендә көймә белән йөзмәкче була! Ха-ха», — дип, төрлечә көлеп, мәсхәрә кылып үтәләр иде. Шул чагында, ул аларга (мәгънәсе): **«Бүген сез безне мәсхәрә кылсагыз, иртәгә без сезне мәсхәрә кылырбыз, сез безне мәсхәрә кылган кебек. Кемгә рисвай кылучы газаб килгәнен тиздән белерсез һәм кемгә мәңгелек газаб булачагын белерсез!»,** — дип әйтә иде. ( Һуд: 38 – 39)


Көймәне төзеп бетергәч, Аллаһ аңа һәрбер хайван затыннан аталы-аналы берәр парны алып шул көймә-гә кертергә кушты. Нух галәйһиссәлам белән, аңа иман китергән мөселманнар һәм барча хайваннар көймәгә кереп беткәч, Аллаһ тәгалә күкләргә үзенең барлык суларын да җиргә явдырырга кушты. Ә җиргә бөтен суларын да өскә чыгарырга боерды. Шуннан соң коточкыч мәхшәр башланды. Күкләр ярылып, эчендәге бар сулар бер өзлексез җиргә яварга тотынды. Җирләр ярылып, эчендәге бар сулар көчле шарлавыклар кебек өскә кайнап, атылып чыкты. Барча җир йөзен су басты һәм көймәне күтәреп алып, иге-чиге булмаган диңгез-суларга алып кереп китте. Ә инде кәферләр зур дулкыннар астында, бер-бер артлы батып калдылар.





Җүдий тавы Төркиянең көньяк-көнчыгышында урнашкан




Нух галәйһиссәламнең шәҗәрәсе



Җүдий тавы. Әгәр игътибар белән карасагыз, аның аскы өлешендә көймә әсәре чагыла




Тарихчылар бу сурәтләрдәге көймә әсәрен Нух г.с.нең Җүдий тавына тукталган көймәсе булуы мөмкинлеген әйтәләр

Мәгънәсе: **«Ул көймә аларны күтәреп таулар кебек зур дулкыннар эчендә йөрер. Шул вакытта Нух галәйһиссәлам, көймәгә кермичә кәферләр арасында торучы үзенең улын күреп, аны чакырды: «Әй улым, безнең белән көймәгә кер, кәферләрдән булма». Улы аңа әйтте: «Бу судан тау башына менеп котылырмын». Нух әйтте: «Бүген Аллаһ газабыннан котылу юк, сине тау да коткара алмас, мәгәр Аллаһ рәхмәт кылган кешеләр генә көймәгә менеп котылырлар», — дип. Соңра араларына дулкын төшеп аларны аерды вә карышкан улы суга батып һәлак булды».** (Һуд: 42 – 43)

Нух үзенең улын коткаруын сорап Раббысына ялварды (мәгънәсе): **«Нух нида кылып әйтте: «Әй Раббым! Улым минем әһелемнән, Синең вәгъдәң хак вә Син хәкимнәрнең дә хәкимерәгесең», —** диде. Әмма Раббысы аңарга улының көферлек кылуы белән аның әһеленнән түгел икәнлеген белдерде. Нух пәйгамбәр кәфер улын коткаруын сораган өчен, Аллаһтан аның бу хатасын кичерүен үтенде һәм Раббысы аны гафу итте.

Шулай итеп, балалар, җир йөзендәге барча кәферләр батып бетеп, бары тик Нух галәйһиссәлам белән аңа иман китергән кешеләр һәм көймәдәге хайваннар гына калгач, Аллаһы тәгалә җиргә суларын сеңдерергә, күккә яңгырларын туктатырга кушты. Су кими башлагач, Нух галәйһиссәламнең көймәсе Аллаһ тәгаләнең әмере белән “Җүдий” исемле тауга килеп туктады. Барча кешеләр һәм хайваннар көймәдән төшеп, җир йөзендә таралдылар.

Нух галәйһиссәлам үзенә иман китергән кешеләр белән, җир йөзендә Аллаһка гына гыйбадәт кылып бик күп еллар яшәде. Раббылары аларны иманлы балалар белән ризыкландырды. Ә үлер алдыннан ул үзенең кавеменнән — бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга, Аңа ширек катмаска вә Аллаһның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелырга — дип, вәгъдә алды һәм ошбу дөньяны калдырып китте.

Инде балалар, шушының белән Нух عليه السلام кыйссасын тәмамлыйбыз. Мин сезне ошбу кыйссадан бик күп гыйбрәтләр вә үрнәкләр алгансыздыр дип уйлыйм. Аллаһ тәгалә алган гыйлемнәребез белән файдаланырга насыйп итеп, гөнаһлы гамәлләрдән ерак кылсын. Әмин.

Ә хәзергә, киләсе пәйгамбәр тормышына яңа сәяхәтебезне башлаганчы, узган дәресләрдәге кебек үк мин сезгә шушы кыйссадан алган кайбер файдаларны әйтеп узармын һәм берничә сорау бирермен.

**Беренче:** Ошбу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Пәйгамбәрләр хак дингә өндәп, батылдан тыючылар.

**2)** – Потлар, сыннар һәм башка тере мәхлукларның сурәтләрен ясау хәрам, чөнки ул ширеккә китерә.

**3)** – Нух галәйһиссәлам иманга чакыруда бик күп мәшәкатьләр, авырлыклар очратса да, бу эшендә бик нык сабыр, чыдам булды һәм бернинди өметсезлеккә дә бирелмәде.

**4)** – Нух галәйһиссәлам үзенең кавемен 950 ел буе ширектән тыелып, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырды.

**5)** – Аллаһ тәгалә Нух галәйһиссәламнең кавемен иман китермәгәннәре өчен һәлак итте.

**6)** – Иман китермәгән кеше бу дөньяда да хәсрәттә, Кыямәт көнендә дә Аллаһ тәгаләнең газабында була.

**7)** – Тәкъвалык — зур бәхеткә илтә.

**Икенче:** Ошбу сорауларга җавап биреп үзеңнең бу кыйссаны ничек аңлавыңны тикшер:

**1)** – Нух галәйһиссәламнең кавеме нәрсәгә табына иде?

**2)** – Нух галәйһиссәлам кавеме, изге кешеләрнең потларына табына иде. Бу кешеләрнең исемнәрен әйтеп бир!

**3)** – Аллаһ тәгалә ул кавемнең күпләре иман китермәячәген белгерткәннән соң, Нух галәйһиссәламгә нәрсә эшләргә боерды?

**4)** – Нух галәйһиссәламнең улы иман китердеме?

**5)** – Аллаһ җиргә суларны сеңдерергә, күккә яңгырларны туктатырга әмер биргәч, Нух галәйһиссәламнең көймәсе нинди җиргә туктады?

**6)** – Аллаһ тәгаләнең Нух галәйһиссәламгә биргән могҗизасын әйтеп уз!

**7)** – Ни өчен Аллаһ тәгалә Нух галәйһиссәламнең улын туфаннан (көчле су басудан) коткармады?

**Өченче:** Җәя эчендәге җавапларның кайсы дөрес булганын күрсәт:

**1)** – Нух галәйһиссәлам (балтачы – тегүче – тимерче) иде.

**2)** – Аллаһ Нух галәйһиссәламнең кавемен (туфан (су басу) – көчле җил – ут) белән һәлак итте.

**3)** – Нух галәйһиссәлам көймәне (Аллаһ әмере белән – үзлегеннән – кешеләр кушуы буенча) төзеде.

# Һуд عليه السلام

Аллаһ тәгалә Нух галәйһиссәламне һәм аның белән булганнарның барсын да коткаргач, кешеләр төрле җирләргә таралып, Нух галәйһиссәлам вафат булгач та, аның васыяте буенча бер Аллаһка гына гыйбадәт кылып яшәүләрен дәвам иттеләр.

Әмма иблис, ләгънәт төшкере, аларны туры юлдан яздырыр өчен үзенең мәкерлекләрен дәвам итте. Ничек инде ул җир йөзендә була торып, кешеләрнең тыныч кына бер Раббыларына гыйбадәт кылып яшәүләрен күзәтсен? Кешеләрнең мөэмин булып яшәүләренә риза булмыйча, ул, көньяк Хиҗазның Йәмән җирендә "әл-Әхкаф" исемле урында булган "Гад" кавеменә, үзенең ширеккә китерүче вәсвәсәсен сала башлады. Шәйтан аларга потка табынуны иң хәерле нәрсә итеп тасвирлады. Алар потлар ясап шуларга сәҗдә кыла башладылар, корбаннар чалдылар һәм җир йөзендә ширек вә бозыклык уяттылар. Куәтле булуларына таянып, алар үзләрен иң яхшы кешеләр дип мактандылар. Ул вакытларда "Гад" кавеме үзләренең көчле вә зур гәүдәле булулары белән билгеле иде.


Белүебезчә, балалар, Аллаһ үзенең колларына рәхимле. Ул кешеләрне үзләрен генә, бернинди ярдәмсез, өметсез калдырмый. Бәлки аларга хак

юлны табып, батылдан, ширектән ераклашыр өчен, шуларны аңлатучы пәйгамбәр җибәрә.

Инде башка кавемнәргә дә пәйгамбәр җибәргән кебек, Аллаһ тәгалә Гад кавеменә Һуд галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрде. Ул Раббысына гына гыйбадәт кылып, тәкъва булуы белән билгеле иде. Коръәндә аның хакында болай диелде (мәгънәсе): **«Гад кавеменә кардәшләре Һудны пәйгамбәр итеп җибәрдек. Ул әйтте: «Әй кавемем, Аллаһка итагать итегез, Аңа гыйбадәт кылыгыз! Сезгә Аннан башка һич иләһ юк. Сез хак эшне эшләүче түгел».** (Һуд: 50)




Бу сурәттә, сез Йәмән җирендәге Һуд кавеменең яшәгән урынын күрәсез



Һуд галәйһис сәлам
Габдулла
Рабах
Әл-Халуд
Гад
Гус
Ирам
Сам
Нух галәйһиссәлам
Һуд галәйһис-сәламнең нәсәбе

Шулай итеп, ул кавеменә, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга кирәклеген бәян итте. Потларның файда да, зыян да китерә алмаганнарын аңлатты. Әмма кавеме аннан көлеп, аны мәсхәрә генә кылды һәм аңа (мәгънәсе): **«Һудның кавеменнән кәфер булганнары әйтте: «Әй Һуд, без сине наданлыкта вә диваналыктасың дип беләбез һәм сине ялганчы дип уйлыйбыз». Һуд әйтте: «Әй кавемем! Миндә диваналык юк, ләкин мин барча галәмне тәрбия кылучы Аллаһның расүлемен. Сезгә Раббымның хөкемнәрен ирештерәмен вә мин сезне яхшылыкка өндәп үгет-нәсыйхәт кылучы, сүземдә ышанычлы пәйгамбәрмен. Әллә арагыздан үзегез кебек бер кешегә, Аллаһтан китап иңдерелүгә гаҗәпләнәсезме? Ул китап сезне Аллаһ газабы белән куркытыр өчен иңдерелде. Янә хәтерләгез, Нух кавемен һәлак иткәннән соң, Аллаһ сезне алар урынына китерде һәм сезне халык кылынышыгызда куәт белән артык кылды, Аллаһның сезгә биргән нигъмәтләрен хәтерегездә саклагыз, шаять газабтан котылырсыз!».** (Әгъраф: 66 – 69)

Һуд ﵇ аларга: «Әй кавемем! Мин сезгә нәсыйхәтчемен һәм аның өчен сездән хак сорамыйм, минем эшемнең әҗере үземне юктан бар итүче Аллаһ тәгалә өчен генә. Шуны да аңламыйсызмы әллә?», — диде. Кавеме аннан көлүен дәвам гына итте. Һуд галәйһиссәлам аңа карамастан аларга Аллаһның биргән нигъмәтләрен исләренә төшерде һәм дә аларга: «Әгәр дә сез көферлектә булуыгызны дәвам итсәгез, сезгә Аллаһ тәгаләнең каты газабы булыр. Нух галәйһиссәламнең кавеме ничек һәлак булганын

белмисезме әллә?», — дип кисәтте. Шуңа карамастан, Һуд галәйһиссәламнең диненә бик азлары гына керде. Күпчелеге көферлектә калып, бозыклык таратуларын дәвам иттеләр.

Шулай итеп көннәр, айлар, еллар узды. Һуд галәйһиссәлам үзенең дәгъватын дәвам итте, әмма күбесенең йөрәкләре таш кебек иде инде. Алар Һуд галәйһиссәламгә (мәгънәсе): **«Әй Һуд! Безләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз дип боерырга килдеңме? Вә аталарыбыз гыйбадәт кылган сыннарны ташлагыз, дип әйтергә килдеңме? Безгә вәгъдә кылган газабыңны китер, әгәр дөрес сөйләүче булсаң», — диделәр. Һуд әйтте: «Тәхкыйк, сезгә Раббыгыздан газаб вә ачуның килмәге тиешле булды, әйе сез үзегез вә аталарыгыз «иләһ» дип атаган сыннарыгыз хакында минем белән низаглашасызмы? Сыннарга гыйбадәт кылуның дөреслеге хакында Аллаһ һичбер дәлил иңдермәде бит, башыгызга киләчәк һәлакәтне көтегез! Мин дә сезнең белән бергә үземә тиешле дәрәҗәләрне көтүчеләрдәнмен».** (Әгъраф: 70 – 71)

Кавеменең тәкәбберлеге һәм каршы торуы дәвам иткәч, Һуд галәйһиссәлам Раббысына дога кылды (мәгънәсе): **«Йә Раббым, мине ялганчы дигәннәре өчен, миңа ярдәм бир!». Аллаһ әйтте: «Алар сине ялганчы дигәннәре өчен, аз вакыт эчендә, әлбәттә, үкенүче булып әверелерләр».** (Мөэминнәр: 39 – 40)

Аллаһ Һуд галәйһиссәламнең догасын кабул итте һәм аларга яңгырны туктатты. Җирләр коры-

ды, хәтта кояшның эсселгеннән яшелләкләр корып көйде, чәчүлекләр янды. Шул газапның Аллаһтан икәнен белеп Һуд галәйһиссәлам кавемен хаклыкка өндәде, потларга табынуны ташлап бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырды. Алар потларга табынуларын ташламасалар, Аллаһ тәгалә тагы да катырак газап белән газаплар дип кисәтте. Ләкин кәферләрнең тәкәбберлекләре йөрәкләрен каплаган иде.

Көннәрдән бер көнне, күк йөзендә болыт күренде. Кешеләр безгә яңгыр килде дип шатланыштылар. Иллә-мәгәр Һуд галәйһиссәлам бу болытның Аллаһ газабы икәнен белеп, кешеләрне тагын да иманга чакырды. Ул болытның зур газап билгесе икәнен әйтте, әмма кавеме аның сүзләрен кире какты. Шуннан соң, Һуд галәйһиссәлам, иман китереп аңа ияргән кешеләр белән, ул җирдән башка урынга күченеп китте. Шул көнне үк Аллаһ тәгалә мөшрикләргә көчле давыл җибәрде, хәтта йортларны, сарайларны, агачларны, хайваннарны, кешеләрне һәм башка барча әйберләрне җимереп, үтереп бетерде.

Аллаһ тәгалә алар хакында Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Әмма Гад кавеме каты тавышлы үткен җил белән һәлак ителделәр. Ул җилне аларга җиде төн вә сигез көн тоташтан иреклe кылды. Ул җилдә кешеләрнең, үзәге черек һәм куыш булган хөрмә агачы авып төшкән кебек, һәлак булганнарын күрер идең. Алардан калган берәр кешене күрерсеңме?».** (Хаккат: 6 – 8)

Әлбәттә, Аллаһ Үзенең вәгъдәсенә хилафлык кылмый, мөэминнәрне саклап калып, кәферләрне газап кыла.

Нәниләрем! Һуд галәйһиссәламнең тарихына булган сәяхәтебезне шушында тәмамлыйбыз. Ошбу кыйссадан да гыйбрәтләр алып, Раббыбызның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп булсын. Әмин!

Киләсе пәйгамбәр кыйссасында очрашканга кадәр, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

**Беренче:** Ошбу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Начарлыкка изгелек белән җавап бирү кирәк.

**2)** – Үзеңнең көчлелегең белән горурланмыйча, мактанмыйча — тыйнак булу тиешле.

**3)** – Кешеләргә пәйгамбәрләр килүе — бу аларга Аллаһ тәгаләнең рәхмәте.

**4)** – Пәйгамбәрләргә ияромичә аларга каршылык күрсәтү — кешене бу дөньяда да, ахирәттә дә һәлакәткә илтә.

**5)** – Һуд галәйһиссәлам кавеме белән киң күңелле булды.

**6)** – Аллаһ тәгалә Һуд галәйһиссәламнең кавемен көферлек кылу сәбәпле, каты газап белән газаплады.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Һуд галәйһиссәлам кавеменең кайбер сыйфатларын әйтеп уз!

**2)** – Ул кавем кайда яшәде?

**3)** – Һуд галәйһиссәлам, кавемен нәрсәгә чакырды?

**4)** – Ул кавем көферлеккә баткач, йөрәкләре ниндигә әйләнде?

**5)** – Аллаһ тәгалә аларга нинди газап җибәрде?

**6)** – Һуд галәйһиссәлам кавеменең барчасы да иман китердеме?

Дөрес җавапны сайлап ал:

**1)** – Һуд галәйһиссәламнең кавеме: (Йәмәндә әл-Әхкаф дигән урында – Египетта – Сүриядә) яшәде.

**2)** – Һуд галәйһиссәламнең кавемен Аллаһ тәгалә (су басу – ут – көчле каты җил) белән һәлак итте.

Дөрес җөмлә артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата булган җөмлә артына ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Кавемен иманга чакырган өчен, Һуд галәйһиссәлам алардан акча түләүне таләп итте ( )

**2)** – Һуд галәйһиссәламнең кавеме сыерга табыналар иде ( )

**3)** – Аллаһ тәгалә Гад кавемен Үзенә буйсынмыйча көфрәнә кылганнары өчен һәлак итте ( )


**4)** – Аллаһ тәгалә Гад кавеменә пәйгамбәр итеп Нух галәйһиссәламне җибәрде ( )

# Салих عليه السلام


Җирдә бозыклык һәм фәсәд тараткан Гад кавеме һәлак булып бик күп вакытлар узгач, Гарәп ярымутравының төньягында, хәзерге Тәбүк шәһәренә якында, яңа кавем барлыкка килде. Ул кавем, Аллаһ тәгалә туфаннан коткарган Нух галәйһиссәлам кавеменең нәселеннән булып, шул җирдә урнашкан иделәр. Аларга да Аллаһ көч-куәт, мал-мөлкәт һәм башка бик күп нигъмәтләр биреп нигъмәтләгән иде. Ул кавем — «Сәмүд» исемле булды.


Сәмүд кавеме бик яхшы тормышта яши торган булып, үзләренә йортларын да зур кыя ташларын кисеп, таулар эчен тишеп, матур, зур-зур сарайлар кылдылар һәм тирә ягына агачлар утырттылар. Ул йортларны тауда шул кадәр зур кылдылар ки, хәтта аларны ул көчле җил-яңгырдан, эссе-суыктан һәм башка нәрсәләрдән саклый ала торган булды. Болар барсы да аларга бирелгән Аллаһның нигъмәте икәнлеген күрсәтә иде.

Ләкин, алар үзләрен юктан бар итеп, аларга шундый нигъмәтләрне биргән Аллаһ тәгаләне онытып, Һуд галәйһиссәламнең кавеме кебек җирдә фәсәд вә бозыклык тарата башладылар.



Мисыр
Синай
Кызыл диңгез
Мәдйән
Әйләт
Тәбүк
Сәмуд кавеменең йортлары
Гарәп ярым утравы
Салих галәйһис сәлам һәм сәмуд кавеме


Салих гәләйһиссәлам
Габид
Әссаф
Мәсих
Габид
Хариз
Сәмүд
Гамир
Ирам
Сам
Нух гәләйһиссәлам
Салих гәләйһиссәламнең нәсебе






المؤلف أمام نحت صخري في الجبل ( مدائن صالح )




الديوان




المؤلف أمام محلب الناقة



واجهة أخرى لإحدى المنحوتات الصخرية في الجبل



قبر من الداخل



تشكل طبيعي من العُلا ( خرطوم الفيل )



Шуңа карамастан, без беләбез балалар, Аллаһның рәхмәте киң, вә Коръәндә (мәгънәсе): **«Минем рәхмәтем киң, һәрнәрсәне сыйдырды»,** — диде. (Әгъраф: 156)

Аллаһ тәгалә Сәмүд кавеменә, араларында тәкъвалык вә изгелек белән мәшһүр, гыйлеме һәм нәсәбе белән иң хәерлесе булган Салих галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрде.

Салих عليه السلام Раббысының әмеренә буйсынып, Сәмүд кавемен иманга чакыра башлады. Аларга ул потларның файда да, зыян да китерә алмаганлыгын һәм көч-куәтнең аларга Аллаһ тәгаләдән нигъмәт итеп бирелгәнлеген аңлатты. Салих عليه السلام күпме генә иманга чакырмасын, ләкин алар аны инкяр итте.

Моның хакында Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Сәмуд кавеме пәйгамбәрләрне ялганга тоттылар. Кардәшләре Салих пәйгамбәр аларга әйтте: «Әллә сез Аллаһтан курыкмыйсызмы? Аны ташлап һичнәрсәгә ярамаган нәрсәләргә гыйбадәт кыласыз. Әлбәттә, мин сезгә хак пәйгамбәрмен ки, миннән зарар күрүдән иминсез. Аллаһтан куркыгыз вә минем әмерләремә итагать итегез. Мин сезгә Ислам шәригатен өйрәткәнем өчен хак сорамыйм, минем дәгъватемнең савабы — галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһ хозурында. Әллә сез — мөшрикләр, ошбу азгынлыкта булган хәлегездә бу дөньяда имин калырга уйлыйсызмы? Яхшы бакчаларда вә яхшы елгалар-да, игеннәрдә вә өлгергән йомшак хөрмәләрдә. Вә шатланганыгыз хәлдә тауларны тишеп өйләр ясыйсыз, ошбу нигъмәтләр эчендә мәңге калырга уйлыйсызмы? Куркыгыз, Аллаһка каршылык күрсәтүдән сакланыгыз вә минем әмеремә итагать итегез. Юлдан чыккан мөшрикләргә итагать итмәгез. Ул мөшрикләр динне, кешеләрне вә тормышны бозучылар, алар һичнәрсәне төзәтмиләр».** (Шүгара: 141 – 152)

Салих галәйһиссәлам төрле юллар белән аларга дәгъват кылуга карамастан, аңа бик аз кеше иярде. Күпләре инкяр итеп аны ялганганчылыкта гаепләделәр һәм аңа: «Әй Салих! Моңа кадәр без сине хикмәтле сүзләр сөйләгәнең өчен тыңлый идек, инде хәзер син яңа, безгә билгеле булмаган хәбәрләр сөйлисең, синеңчә без ата-бабаларыбызның динен ташлап, син алып килгән яңа дингә керикмени?

Без синең динеңнән шикләнәбез, әй Салих! Үзеңнең элекке динеңә кайт һәм безнең белән бул, алайса иләһләр синнән разый булмас», — дип, көферлектә калуларын уңай күрделәр.

Салих галәйһиссәлам аларның сүзләренә, мәсхәрә итүләренә, сабырлык белән җавап бирде. Аллаһ тәгалә алардан элек булган Нух галәйһиссәламнең кавемен суга батырып, ә Һуд галәйһиссәламнең кавемен көчле җил белән һәлак кылганлыгын исләренә төшерде. Ләкин алар үгет-нәсыйхәт итүгә карамастан көферлекләрендә кала бирделәр.

Аллаһ тәгалә Коръәндә бу хакта болай диде (мәгънәсе): **«Вә Сәмуд халкына кардәшләре Салихны пәйгамбәр итеп җибәрдек. Ул әйтте: «Ий кавемем, Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, Аннан башка сезгә иләһ юк, Ул сезне җирдән яратты вә җирдә торырга гомер бирде, Аннан ярлыкау өстәгез, соңра тәүбә итеп Аңа кайтыгыз! Тәхкыйк, Раббым рәхмәтендә ихлас булып тәүбә кылырга ашыккан кешегә, әлбәттә,Ул якын һәм аның догасына җавап бирүче». Әйттеләр: «Әй Салих, син пәйгамбәрлек дәгъвасен кылганчы арабызда бер өметле егет идең. Ә инде хәзер безне аталарыбыз гыйбадәт кылган сынымнарга гыйбадәт кылудан тыясыңмы? Тәхкыйк, без син өндәгән диндә вә Аллаһның бер генә булуында шикләнәбез». Салих әйтте: «Уйлап карагыз, мин сезгә Раббым тарафыннан пәйгамбәрлегемә ачык дәлилләр белән килгән булсам вә Ул миңа рәхмәтен биргән булса, шуннаң соң шикләнергә урын каламы? Инде мин үземә күп нигъмәт бирүче Раббыма гөнаһлы бул-**

**сам, ягъни Ул әйткәнчә эш кылмыйча сез әйткәнчә эш кылсам, ул вакытта мине Аның газабыннан кем коткарыр? Әгәр сез әйткәнчә эш кылсам, әлбәттә, үземә һәлакәттән башка һичнәрсәне арттыра алмам!».** (Һуд: 61 – 63)

Элекке кавемнәргә килгән газапны исләренә төшергәч, аралырыннан кайберәүләре уйланып вә газап килүеннән куркып, Салих галәйһиссәламгә иман китерделәр. Моны күреп кәферләр, үзләре һәм байлыклары өчен мөэминнәрдән куркып, Салих галәйһиссәламне дәгъватеннән туктатыр өчен төрле мәкерлекләр кыла башладылар.

Алар пәйгамбәрне ялганга чыгарыр өчен, Салих галәйһиссәламнән могҗиза китерүен сорадылар. «Әгәр хак булсаң, без дә сиңа иярербез», — диделәр. Салих галәйһиссәлам аларга: «Әй кавемем, мин сезнең кебек кешеләр затыннанмын һәм могҗизаны үзем генә кыла алмыйм, ләкин Раббымнан сорап дога кылырмын. Ул могҗиза минем хак сөйләгәнемне исбатлап, Кыямәт көнендә сезгә Аллаһ каршында акланырга чара калдырмас», — диде. Аллаһ тәгалә Салих галәйһиссәламнең догасын кабул итте һәм аңа могҗиза итеп зур дөя җибәрде. Кешеләр бу могҗизаны күргәч, Салих галәйһиссәлам аларга (мәгънәсе): **«Әй кавемем, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз! Сезнең Аллаһтан башка иләһәгез юк. Тәхкыйк, сезгә минем пәйгамбәрлегемә галәмәт килде, ошбу Аллаһның дөясе сезгә могҗизадыр, аңарга ирек бирегез, Аллаһ җирендә ашасын, явызлык белән аңарга кул тидермәгез, юкса сезгә рәнҗетүче газаб ирешер»,** — диде. (Әгъраф: 73)

Инде Сәмүд кавеме шул могҗизаны күреп тә, Аллаһка иман китермәделәр. Әмма бу могҗиза, моңа кадәр иман китергән мөэминнәрнең иманнарын тагы да ныграк арттырды һәм алар тагы да көчлерәк дәгъват кыла башладылар. Ләкин, могҗизаны күреп тә һәм Салихның ﷺ хаклыкка өндәвен белеп тә, бик аз кеше аңа иман китерде.

Ул дөя Аллаһ биргән нигъмәтләрдән ашап, кешеләр эчкән коедан су эчә иде. Салих галәйһиссәлам аларга (мәгънәсе): **«Ошбу дөягә һәм сезгә коедан су эчмәк, сезнең билгеле бер көннәр буенча, чират буенча коедан бер көн су эчмәк — бу дөянең өлеше вә икенче көнне коедан су эчмәк — сезнең өлешегез. Бу дөягә явызлык белән кагылмагыз. Югыйсә сезне олуг Кыямәт көненең газабы тотар», — диде».** (Шүгара: 155 – 156)

Сәмүд кавеме дөяне суярга дип мәкерлек кора башладылар. Салих галәйһиссәлам аларны кисәтеп: «Әй кешеләр, дөягә явызлык белән кагылмагыз, чөнки сез аңа явызлык белән кагылсагыз — Аллаһ сезне газап кылачак», — диде.

Күп вакытта узмыйча, тәкәбберлек күрсәтеп Салих галәйһиссәламнән көлгән кәферләр, дөянең су эчеп кайтканын саклап торып, уңайлы форсат табып үтерделәр. Алар Салих галәйһиссәлам янына шатланып килеп: «Әй Салих! Безне газап белән куркыткан идең, без дөяне үтердек, инде газабыңны китер, кайда ул газап?», — дип көлештеләр.

Аллаһ бу хакта Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Алар дөяне үтерделәр һәм Раббыларының**

**әмеренә каршы тәкәбберлек кылдылар вә: «Әй Салих, безгә вәгъдә кылган газабыңны китер, әгәр син Аллаһ тарафыннан җибәрелгән расүлләрдән булсаң», — диделәр».** (Әгъраф: 77)

Салих галәйһиссәлам аларга өч көн кичектерде һәм: «Сезгә тиешле газап киләчәк», — диде.

Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Алар дөяне үтерделәр, Салих әйтте: «Өч көн торып йортларыгыздан файдаланыгыз, соңра сезгә газап ирешер. Бу вәгъдә — ялган вәгъдә түгел».** (Һуд: 65)

Шуннан соң кәферләр Салих пәйгамбәрне яшерен рәвештә үтерергә вәгъдәләштеләр, (мәгънәсе): **«Сәмүдләрнең шәһәрендә җир йөзендә төрле бозыклык кылып, һичбер яхшылык кылмый торган тугыз кеше бар иде. Алар бер-берсенә әйттеләр: «Аллаһ исеме белән ант итешегез, төнлә Салихны һәм җәмәгатен басып кереп үтерәбез, соңра аларның кан хакын таләп итүче вәлиенә, без аларны үтерүчеләр янында булмадык, кемнәр үтергәнен белмибез вә без бу сүзләребезне дөрес сөйлибез диярбез».** (Нәмел: 48 – 49)

Алар Салих галәйһиссәламне һәм җәмәгатен үтереп, кем үтергәнен белмәсеннәр өчен мәкерлек кылдылар. Ләкин, Аллаһ тәгалә һәрбер нәрсәне белүче вә кәферләрне бу дөньяда да, ахирәттә дә газап кылучы.

Ул Коръәндә бу хакта болай диде (мәгънәсе): **«Әнә шулай, Салихны үтермәк өчен, мәкерлек кылдылар һәм Без аларга каршы мәкерне мәкер**

**кылдык, сизми дә калдылар, һәлак булдылар. Күр! Аларның мәкеренең ахыры ничек булды, Без аларны һәм кавемнәрен барчасын җимереп һәлак иттек. Ошбу җимерелгән урыннар аларның өйләредер, золым итүләре сәбәпле өйләре буш калмыштыр. Салих кавеменең һәлак булуында да гыйбрәт бар. Иман китереп Аллаһка тәкъвалек кылган мөэминнәрне коткардык».** (Нәмел: 50 – 53)

Мәкерлекләрен кылганчы ук, аларга Аллаһ тәгаләнең газабы төште. Ибен Кәсир "Әнбияләр тарихы" китабында әйтүенчә: «Аллаһ тәгалә Салихны үтерергә теләүчеләргә таш яудырды һәм алар, үзләренең кавемнәренә кадәр үк һәлак булдылар», — диде.

Сәмүд кавеме кисәтелгән өч көннең беренчесендә уянсалар, Салих галәйһиссәлам әйткәнчә, йөзләре саргайган иде. Кич белән бер – берсенә: «Кичектерелгән көнебезнең берсе үтте», — диделәр. Икенче көнне торсалар, йөзләре кызарганын күрделәр һәм кич белән: «Кичектерелгән көнебезнең икенчесе узды», — диештеләр. Өченче көнне торсалар, йөзләренең каралганын күрделәр һәм кич белән: «Кичектерелгән көннәребез тәмам булды», — диделәр. Инде дүртенче көнне аларга каты куркыныч тавыш килде һәм алар мәет булып катып калдылар.

Аллаһ тәгаләгә гыйбадәт кылырга теләмичә, җир йөзендә бозыклык тараткан кәферләрне — Ул шулай каты газап кыла.

Шуның белән, кадерле балалар, Салих галәйһиссәлам турындагы кыйссабызны тәмамлыйбыз. Инде

киләсе пәйгамбәр тарихында очрашканчыга кадәр, әссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Ошбу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Без Аллаһ тәгалә биргән нигъмәтләргә шөкер кылырга тиешлебез, чөнки шөкер итү — нигъмәтне арттыра, ә зарлану — нигъмәтне бетерә.

**2)** – Салих галәйһиссәламнең кавеменә Аллаһ бик күп нигъмәтләр бирде, әмма ул кавем шөкер итмәде.

**3)** – Аллаһ тәгалә Сәмүд кавеменә тәүбә итәр өчен бик күп мөмкинчелек биргәннән соң гына газап кылды.

**4)** – Изгелеккә өндәп кылынган нәсыйхәтләрне, без кабул итәргә тиешлебез.

**5)** – Аллаһка иман китерү бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә илтә.

**6)** – Элекке кавемнәр тарихыннан без үзебезгә гыйбрәт алырга тиешлебез.

**Икенче:** Үзеңнең ошбу кыйссаны ничек аңлавыңны тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Салих галәйһиссәлам нинди кавемгә пәйгамбәр итеп җибәрелде?

**2)** – Аллаһ тәгалә Салих галәйһиссәламне ни өчен җибәрде?

**3)** – Салих галәйһиссәламнең кавеме аның белән ничек мөгамәлә итте?

**4)** – Аллаһ тәгалә Салих галәйһиссәламне нинди могҗиза белән куәтләде.

**5)** – Аллаһ тәгаләдән Салих галәйһиссәламнең кавеменә нинди газап иреште?

Дөрес җөмлә артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата булган җөмлә артына ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Аллаһ тәгалә Салих галәйһиссәламнең кавеменә бик күп нигъмәтләр бирде һәм алар ул нигъмәтләрне ихсан белән кабул иттеләр (  )

**2)** – Салих галәйһиссәлам кавеменә нәсыйхәт кылды, әмма алар аны кабул итмәде (  )

**3)** – Сәмүд кавеме Аллаһка иман китерде һәм берсе дә көферлек кылмады (  )

**4)** – Аллаһ тәгалә Салих галәйһиссәламнең кавемен көферлек кылганнары өчен һәлак итте (  )

# Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһиссәламнәр

Кадерле балалар, хакыйкатьтә, Ибраһим галәйһиссәламнең шәхсияте хакында язып бетерү мөмкин түгел. Шуның өчен дә без аның хакында кыскача гына язып узарбыз. Әмма шушы кыска гына тарихтан да бик күп гыйбрәтләр һәм вәгазьләр алырга мөмкин.

Ибраһимның әтисе Әзәр, Нух галәйһиссәламнең балаларыннан булган — Сәм нәселеннән иде.

Ибраһим галәйһиссәлам Гыйракның Бабил исемле урынында дөньяга килеп, аның тууы әтисе өчен бик тә сөенечле һәм бәхетле көннәренең берсе булды. Ул әти-әнисе белән үсеп, үзенең тапкырлыгы һәм акыллылыгы белән аерылып торды.

Аның әтисе агачтан һәм таштан ясап саткан потларны, кешеләр үзләренә «илаһ» итеп алып табыналар иде. Ибраһим галәйһиссәлам бу нәрсәләрне күреп: «Ничек инде кешеләр әтием үз куллары белән ясаган агач вә таш потларны «илаһ» итеп алып табыналар? Илаһ — ул үзе һәрнәрсәне булдыручы булырга тиеш, ә кемдер тарафыннан ясалырга тиеш түгел. Шулай булгач, ул потлар гыйбадәткә лаек түгел», — дип уйланды.

Ибраһим галәйһиссәлам бәлигъ булып күпмедер еллар узгач, Аллаһ тәгалә аңа вәхи иңдерде.

Көннәрдән бер көнне, Ибраһим галәйһиссәлам әтисе янына килеп, туры-хак юлны аңлата башлады (мәгънәсе): **«Ибраһим, атасы Әзәрга әйтте: «Потларны «иләһ» дип белеп, аларга гыйбадәт итәсезме? Тәхкыйк, мин сине вә кавемеңне ачыктан-ачык адашуда булганыгызны күрәмен»,** — диде. ( Әнгам: 74)

Әзәр бернәрсә дә ишетмәгән кебек баласының сүзләренә игътибар итмәде. Аңа карамастан, Ибраһим галәйһиссәлам әтисен йомшаклык вә әдәп белән, потларга табынуын калдырып бер Аллаһка гына иман китерүенә өндүен дәвам итте.

Аллаһ Коръәндә Ибраһим галәйһиссәламнең әтисенә булган дәгъват итү рәвешен болай тасвирлый (мәгънәсе): **«Ибраһим галәйһиссәламнең Коръәндәге хәбәрен зикер ит! Ул гаять дөрес сүзле изге пәйгамбәр булды. Ибраһим әйтте: «Әй атам, ни өчен ишетми, күрми һәм сиңа файда да, зарар да ирештерә алмый торган нәрсәгә гыйбадәт кыласың? Әй атам, Аллаһтан миңа гыйлем вә дәлилләр килде. Ул гыйлем вә дәлилләр синдә юк. Миңа ияр, туры юлга күндерермен! Әй атам, шәйтанга гыйбадәт кылма, чөнки шәйтан Аллаһка гөнаһкәр булды. Әй атам, сине Аллаһ газабы тотуыннан куркамын, ул вакытта газап эчендә шәйтанга якын булырсың». Ибраһимның атасы әйтте: «Әй Ибраһим, син безнең иләһләребездән баш тартасыңмы? Әгәр ул эшеңнән туктамасаң, әлбәттә, мин сине ташлар белән атармын. Мине ялгыз калдырып, күп вакытка кит!». Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Ярый, алай булса сәламәт**

**вә тыныч бул, мин сине мәҗбүр итмәм, синең өчен Раббымнан гафу итүен сорармын, чөнки Ул догаларымны кабул итүче. Инде үзегезне вә Аллаһтан башка мәгъбүдләрегезне ташлап китәмен. Мин Раббыма дога кыламын һәм кылган догаларымның кире кайтарылмавын өмет итәмен».** (Мәрьям: 41 – 48)

Шуннан соң, Ибраһим галәйһиссәлам кавемен иманга чакырды: «Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз, Ул — терекләндерүче вә үлеләндерүче һәм барча нәрсәгә Кодрәт иясе. Мин сезне ошбу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле булырга чакырам», — дип нәсыйхәт кылды.

Ләкин, алар Ибраһим галәйһиссәламнең дәгъватен кабул итмичә, көферлекләрендә кала бирделәр. Хәтта аның әтисенә барып зарландылар. Шуңа карамастан да Ибраһим عليه السلام иманга чакыруын дәвам итте.

Коръәндә бу хакта болай диелде (мәгънәсе): **«Янә игътибар итегез! Ибраһим атасы Әзәрга әйтте: «Сыннарны «иләһ» дип белеп, аларга гыйбадәт кыласызмы? Хакыйкатьтә, сине вә кавемеңне адашмакта күрәмен». Әнә шулай Ибраһимга кавеменең эшен күрсәткәнебез кебек, Җир вә Күкләрдә булган нәрсәләрне — могҗизаларны аңа күрсәттек, Аллаһ тәгаләнең бөтен эшләренә якыннан — шиксез ышанучылардан булсын өчен. Кич булгач, Ибраһим йолдызларны күрде, йолдызларга гыйбадәт кылырга ярамаганлыкны аңлатыр өчен хәйлә корып, йолдызга ишарә кылып: «Бу йолдыз минем Раббым», — диде, иртән**

йолдыз югалгач, мөшрикләр янына килеп, аларга: «Үзгәреп-югалып киткән нәрсәләрне һич сөймим, «иләһ» дияргә риза түгелмен», — диде. Ибраһим айның туганын күргәч: «Будыр минем Раббым», — диде, ә ай югалгач мөшрикләргә карап: «Ай да үзгәрде — югалды, әгәр Раббым мине туры юлга күндермәгән булса, әлбәттә, мин дә сезнең кебек адашкан кавемнәрдән булыр идем», — диде. Кояш чыккач, аңа карап, көлеп: «Бу Кояш минем Раббымдыр, барысыннан да зуррак, «иләһ» булырга яраклы», — диде. Кояш баегач, мөшрикләргә карап әйтте: «Әй кавемем! Күрдегезме, Кояш та үзгәрде — югалды, мин, әлбәттә, сез Аллаһка тиңдәш иткән нәрсәләрнең һәммәсеннән дә бизүчемен». Ибраһим әйтте: «Батылдан хакка авышканым хәлдә Җир вә Күкләрне төзүче Аллаһка йөземне юнәлдердем вә мин Аллаһка һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылучы түгелмен». Ибраһимнең кавеме үзләренең батыл, пычрак эшләрен яклап Ибраһим белән әрепләштеләр. Аларга Ибраһим әйтте: «Әй мөшрикләр! Аллаһ һәм Аның хөкемнәре хакында минем белән әрепләшәсезме? Хәлбуки, чынлыкта Ул мине туры юлга күндерде. Аллаһ белән тиңләштергән сезнең сынымнарыгыздан һәм Нәмрудыгыздан курыкмыймын, мәгәр Аллаһның миңа берәр зарар теләвеннән куркам, Раббымның белеме һәрнәрсәне чолгап алды. Әллә сез вәгазьләнмисезме?». Ибраһим әйтте: «Аллаһка тиңләштергән сыннарыгыздан мин ничек куркыйм? Ә сез исә һичнәрсәгә ярамаган сыннарыгызны Аллаһка тиңдәш кыла-

**сыз да, Аллаһтан һич курыкмыйсыз, бит Аллаһ сыннарны иләһ урнына тотарга ярый дип дәлил иңдергәне юк. Ике фирканың кайсысы Аллаһ газабыннан имин булырга хаклырак? Ягъни, Коръән юлыннан баручы хак мөэминнәр Аллаһ газабыннан имин булырлармы? Яки, Коръән юлын күрмәүче мөшрикләрме имин булыр? Белсәгез әйтегез! Иман китереп — иманнарына Аллаһка тиңдәшлекне һәм башка золым эшләрне катыштырмаган хак мөэминнәр Аллаһ газабыннан имин булачаклар һәм алар туры юлга күнүчеләр. Күңеле саф, иманы көчле һәм дине дөрес булган мөселман гына Аллаһ газабыннан имин булачагына китергән дәлилебез — көчле дәлил, без аны Ибраһимгә бирдек, саф иманы, дөрес дине һәм хак эше белән өскә чыкканлыгын мөшрик кавеме күрсен өчен. Әнә шулай Үзебез теләгән кешеләрнең дәрәҗәсен дөньяда да, ахирәттә дә бөек кылабыз. Шиксез, синең Раббың һәрнәрсәне белеп хикмәт белән эш кылучы».** (Әнгам: 74 – 83)

Шулай ук, ул вакытларда Нәмруд исемле бик явыз патша бар иде. Барча кешеләр аны «иләһ» урынына күреп, табына торган булдылар. Ибраһим галәйһиссәлам Нәмруд патша янына килеп: «Син кешеләргә: «Мин сезнең иләһегез» дигән сүзеңнән кире кайтып, бер Аллаһка гына гыйбадәт кыла башларга тиешсең», — дип, үгет-нәсыйхәт кылды. Нәмруд аңа: «Синең Раббың кем?», — дип сорады. Ибраһим галәйһиссәлам җавап итеп: «Минем Раббым тергезә һәм үтерә» дигәч, Нәмруд: «Мин дә үтерәм һәм тергезәм», — дип әйтте. Шул вакытта Ибраһим

галәйһиссәлам: «Минем Раббым — Аллаһ, кояшны көнчыгыштан чыгара, ә син көнбатыштан чыгар, әгәр көчең җитсә», — диде. Нәмруд бу эшне эшли алмаячаклыгын аңлап, каушап, сүзсез калды һәм хурлыкка төште.

Бу күренеш хакында Коръәндә менә ничек әйтелә (мәгънәсе): **«Әй Мөхәммәд ﷺ, белдеңме Аллаһ биргән байлыгына таянып, Раббысы хакында Ибраһим عليه السلام белән тартышкан кешене? Ул Нәмруд патша иде. Ибраһим عليه السلام Нәмрудка әйтте: «Мин гыйбадәт кыла торган зат үлекне тергезә һәм үлеләндерә». Нәмруд әйтте: «Мин дә үтерәм һәм тергезәм». Ибраһим عليه السلام әйтте: «Аллаһ кояшны мәшрыйктән чыгара, ә син мәгърибтән чыгар», — дип. Кәфер Нәмруд бу эшне эшли алмагач хәйран булды, хурлыкка төште. Аллаһ, әлбәттә, хакны инкяр итүче залимнәрне туры юлга күндермәс».** (Бәкара: 258)

Нәмрудның: «Мин тергезәм һәм үтерәм», — дип әйтүе, аның наданлыгын һәм ахмаклыгын гына күрсәтте. Аның шулай әйтүе менә нәрсәдер: Нәмруд әйтүебезчә ул вакытта патша иде. Ул үзенең янына төрмәдән ике кешене китерергә боерды. Боларның берсе үлем җәзасына хөкем ителгән булса, ә икенчесе төрмәдән азат ителергә тиеш иде. Үлем җәзасына хөкем ителгәнен ул үзенең хөкеме белән азат итте, һәм: «Кара! Мин аны үлемнән тергездем!», — диде. Ә инде азат ителергә тиешен, ул үтерергә әмер итте, һәм: «Кара, мин аны үтердем!», — диде. Ләкин, бу Нәмрудның акылсызлыгын вә ахмаклыгын гына күрсәтте, чөнки Аллаһ теләмәсә, бу эшләрнең берсе

дә булырга мөмкин түгеллеге көн кебек ачык. Шулай бит, балалар?!

Ибраһим галәйһиссәлам ул кавемне күпме генә иманга чакырмасын, алар иманга килмәделәр.

Көннәрнең берендә, мөшрикләр үзләренең бәйрәмнәрен бәйрәм итәргә дип шәһәрдән чыгып киткәч, Ибраһим галәйһиссәлам кулына балта алып, алар потларын куя торган урынга килде. Андагы потларның барчасын да җимереп бетереп, бары тик берсен, иң зурысын гына калдырды. «Зур пот үзе белән бергә кечкенә потларга табынганнары өчен мөшрикләрдән риза түгел икән, шуңа кечкенәләрен ватып бетергән», — дип уйласыннар өчен, балтаны шул зур потның кулына тоттырып куйды.

Алар бәйрәмнәреннән уйнап-көлеп кайтып, потлары янына табынырга дип килсәләр, ни күрсеннәр, сыннары ватылып-җимерелеп беткән. Моңа бик борчылып, бу эшнең кем эшләгәнлеген белер өчен берберсеннән сораша башладылар. Арадан кайберләре: «Без Ибраһимның ошбу потларны начар итеп искә алганын ишеткән идек», — диештеләр. Шуннан соң, Ибраһим галәйһиссәлам янына килеп (мәгънәсе): **«Әй Ибраһим, безнең иләһләребез белән бу эшне син эшләдеңме?», — диделәр».** (Пәйгамбәрләр: 62)

Ибраһим عليه السلام аларга: «Ник үзләреннән сорамыйсыз соң?», — дигәч, алар: «Без алардан ничек сорыйк, алар бит сөйләшми», — дип, аптыраштылар. Ибраһим عليه السلام аларга: «Сез ничек инде зарар да, файда да китерә алмаган потларга табынасыз?», — диде.

Мөшрикләрнең ачулары чыкты. Алар җимерелгән потлары өчен Ибраһим галәйһиссәламнән үч алырга уйладылар. Зур итеп учак яктылар да, аны шунда ыргыттылар. Әмма ул дөнья утыннан курыкмады һәм аның күңеле тыныч иде. Ут, Аллаһ тәгаләнең әмере белән Ибраһимга бернинди зарар китермичә, салкын һәм имингә әверелде.

Аллаһ тәгалә бу вакыйга хакында Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Тәхкыйк, Мусага Тәүратны, ә Мөхәммәдкә ﷺ Коръәнне иңдергәнчегә кадәр, Без, Ибраһим عليه السلام бәлагатькә ирешкәнче үк аңа хак юлны белгерттек һәм биргән нәрсәбезгә аның лаеклы ия икәнен белдек. Атасына вә кавеменә әйтте: «Сез бик нык бирелеп, даим гыйбадәт кылган бу сурәтләр, алар нәрсә?». Әйттеләр: «Аталарыбызны шул сурәтләргә гыйбадәт кылучылар итеп таптык, без дә шул сурәтләргә гыйбадәт кылабыз». Ибраһим әйтте: «Хакыйкатьтә, сез үзегез вә аталарыгыз ачык адашуда булдыгыз». Әйттеләр: «Аталарыбыз адашкан булса, ә син хак юл белән килдеңме яки бу сүзләреңне безгә уйнап сөйлисеңме?». Ибраһим әйтте: «Бәлки сезнең Раббыгыз — җир вә күкләр Раббысы, Ул — җир, күкләрне халык кылды, бу эшләрнең хаклыгына мин — шаһитларданмын. Аллаһ исеме илә ант итеп әйтәм, сыннарыгызны җимерермен, сез алар яныннан киткән вакытыгызда». Мөшрикләр китеп беткәч, Ибраһим балта белән потларны ваклады, мәгәр бер зур потны гына калдырды, мөшрикләр килгәч, кем ватканын шул поттан сорасыннар өчен. Мөшрикләр килеп күргәч, әйттеләр:**

«Безнең иләһләребезгә бу әдәпсезлекне кем кылды? Тәхкыйк, ул кеше залимнәрдән». Әйттеләр: «Бер егетне ишеттек, безнең иләһәләребезне гаепләп сөйли иде, ул егеткә, Ибраһим, дип әйтелә». Нәмруд вә башкалары әйттеләр: «Ул Ибраһимне тотып, кешеләр күз алдына китерегез — шаять, күргән кешеләр шәһадәт бирерләр». Әйттеләр: «Әй Ибраһим, безнең иләһләребезгә бу эшне син эшләдеңме?». Ибраһим әйтте: «Бәлки бу эшне ошбу зур потыгыз эшләгәндер, үзен калдырып кечкенә сыннарга гыйбадәт кылганыгыз өчен хурланмыштыр, инде ватылган сыннардан сорагыз, әгәр алар сөйләшә торган булсалар». Нәмруд вә кавеме гакыл-фикерләренә кайтып уйлап тордылар һәм бер-берсенә әйттеләр: «Ошбу сөйләшми торган нәрсәләргә гыйбадәт кылып — сез залим булдыгыз». Соңра дәлилләре булмагач, оялып Ибраһим алдында башларын иделәр, һәм әйттеләр: «Дөреслектә, син беләсең бит, безнең потларыбыз сөйләшмиләр, алардан ничек сорыйк?». Ибраһим әйтте: «Сез ничек инде Аллаһтан башкага, файда итәргә дә, зарар итәргә дә көче җитмәгән нәрсәләргә гыйбадәт кыласыз? Сезгә һәм Аллаһтан башка гыйбадәт кылган нәрсәләрегезгә — кабахәтлектер! Шуны да аңламыйсызмы?». Ачулары кабарып, Нәмруд вә кавеме әйттеләр: «Ул Ибраһимне утка салып яндырыгыз, әгәр үзегезнең потларыгыздан ярдәм сорый торган булсагыз, Ибраһимне яндырырга алардан ярдәм сорагыз!». Ибраһимне тау хәтле утка ыргыттылар, Ибраһим дөнья утыннан ку-

**рыкмады, күңеле тыныч булды. Әйттек: «Әй ут! Ибраһимгә салкын бул һәм салкынлык белән дә зарар тидермә», — дип. Алар Ибраһимгә мәкер вә зарар теләделәр. Һәм Без аларны хәсрәтләнүчеләрдән кылдык. «Күпме генә көч куйсалар да, максатларына ирешә алмадылар, бөтен көчләре җилгә очты».** (Пәйгамбәрләр: 51 – 70)

Әлбәттә, потларның җимерелүе һәм Аллаһ тәгаләнең Ибраһимне عليه السلام уттан коткаруы, кешеләр өчен зур дәрес булды. Могҗизаны үз күзләре белән күреп моның Аллаһтан икәнлегенә ышангач, бәгъзе берләре иман китерделәр. Әмма күбесе тәкәбберлек кылып, көферлектә кала бирделәр.

Кавеме Ибраһим галәйһиссәламгә шулай золым кылгач, ул хатыны Сара һәм абыйсының энесе Лут белән Фәләстыйн җиренә һиҗрәт кылды. Анда кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга һәм ширектән ераклашырга чакырырды. Күп кенә еллардан соң, абыйсының улы Лутны анда калдырып, Мисырга күченде. Анда да ул кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырды. Андагы патша да бик залим булып, Ибраһим галәйһиссәлам белән Сараны төрле юллар белән газапламакчы булды. Ләкин ничек кенә тырышмасын, аның бу эшләре барып чыкмады. Ул ниндидер Зур Көч Иясенең Ибраһим галәйһиссәлам белән Сараны саклаганын аңлады. Алардан гафу үтенеп, Хәҗәр исемле хатын-кызны бүләк итте.

Инде Ибраһим галәйһиссәлам белән Сараны бу явыз патшадан саклаучы Зур Көч Иясе — Аллаһ тәгалә икәнен без беләбез, шулай бит, балалар!?

Мисырда күп кенә еллар кешеләрне таүһидкә чакырганнан соң, Ибраһим عليه السلام гаиләсе белән яңадан Фәләстыйнга күченде. Аларның, Сара белән озак еллар бергә торуларына карамастан, балалары юк иде. Сара Ибраһим галәйһиссәламнең яше зурая барганын вә балалары юклыгын искә алып, аны Хәҗәргә өйләндерү турында уйлады. Бераз вакыттан соң, Ибраһим галәйһиссәлам Хәҗәргә өйләнде, һәм Аллаһ тәгалә аларны угыл белән ризыкландырды. Моңа Ибраһим галәйһиссәлам бик тә шатланды вә аңа «Исмәгыйль» дип исем кушты.

Шушы вакытларда Аллаһтан Ибраһим галәйһиссәламгә, Хәҗәрне вә Исмәгыйльне Мәккә җиренә илтеп калдырырга, дигән әмер килде. Ул чорларда Мәккәдә кешеләр дә, агачлар да, су да юк иде. Шуңа карамастан, Ибраһим галәйһиссәлам Раббысының әмеренә буйсынып, хатыны белән улын шунда калдырып, кире кайтып китте. Ошбу Мәккә урыны бәрәкәтле урын булсын, дип Аллаһка дога кылды.




Ибраһимнең عليه السلام йөргән җирләре


Исхак
Исмәгыйль
Ибраһим
галәйһиссәлам
Расья
Лут
галәйһис-
сәлам
Лутның
ике
улы
Азәр
һарун
Зәгратә
Нахур
Саруҗ
Рагу
Фалиҗ
Габир
Шалих
Ибраһим галәйһис-
сәламнең нәсәбе
Өрфахшәд
Хам
Сам
Яфис
Нухның өч улы
Нух галәйһиссәлам

Бу хакта Коръән Кәримдә болай диелде (мәгънәсе): **«Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Әй Раббым! Бу Мәккә шәһәрен бәла-казалардан имин кыл вә үземне һәм балаларымны сыннарга гыйбадәт кылудан сакла! Әй Раббым! Ул сыннар күп кешене адаштырдылар, кем миңа иярсә — ул минем өммәтемнән, ә кем миңа иярмәсә, Синең ихтыярыңда, теләсәң — газап кылырсың, теләсәң — ярлыкарсың, чөнки Син Ярлыкаучы Рәхимлесең. Ий Раббым! Бәгъзе балаларымны иген үсми торган җиргә Кәгъбә янына, ягъни Кәгъбә төзеләчәк чокыр җиргә илтеп куйдым (Хәҗәр илә баласы Исмәгыйльне). Әй Раббым! Аларга тәүфыйк бир, намазларын үтәргә вә адәмнәрнең күңеленә аларның мәхәббәтен сал, шул Кәгъбә җиренә барып сәүдә итеп, кардәшлекне арттырып тормышларын киңәйтсеннәр вә аларга җимешләрдән ризык бир, шаять, Синә шөкер итәрләр. Әй Раббыбыз! Син безнең ачык кылган вә яшерен кылган һәр эшебезне беләсең, бит Аллаһка җирдә һәм күкләрдә һичбер нәрсә яшерен түгел. Карт көнемдә миңа Исмәгыйль вә Исхакны бирүче Аллаһ тәгаләгә барча мактау! Тәхкыйк, Раббым догаларны ишетүче вә кабул итүче. Йә Раббым! Минем үземне һәм балаларымны намазларны үтәүче кыл! Әй Раббыбыз! Догаларыбызны кабул кыл! Әй Раббыбыз! Үземне вә ата-анамны һәм барча мөэминнәрне ярлыка, Кыямәт көнендә хур итмә!».** (Ибраһим: 35 – 41)

Ибраһим галәйһиссәлам хатыны белән малаен калдырып киткәч, бераздан Исмәгыйль сусап, елый

башлады. Анасы Хәҗәр су эзләп, башта Сафа тавына менде, аннары Мәрвага китте. Шулай итеп ике тау арасында җиде кат йөрде вә соңгы җиденчесендә зур могҗиза булды. Чүллек уртасында, Исмәгыйль галәйһиссәламнең аяк астыннан чишмә бәреп чыкты. Хәҗәр үзе эчеп, малаен да эчергәч, суга: «зәмзәм», — диде. Су бик тә каты ташып чыккан иде. Шул вакыттан алып, ул изге су — «зәмзәм», дип аталды.

Хәзерге вакытта хаҗга, гомрәгә баручылар ошбу изге су белән ләззәтләнәләр һәм дә үзләре белән туганнарына, дус-кардәшләренә алып кайтып китәләр.

Суны кошлар да белеп алды. Алар бу чишмә янына төшеп үзләренең сусаганнарын баса торган иде. Әлбәттә, бу гадәти булмаган күренеш чүлдә узып баручы караваннарга да күренде. Кошлар юкка гына ул җиргә төшмиләр, бәлки анда су бардыр дип, шул урынга килеп карасалар, чынлыкта да анда чишмә күрделәр. Хәҗәрдән бу җиргә урнашырга рөхсәт алгач, шунда күченеп килеп яшәргә калдылар.

Ибраһим галәйһиссәлам хатыны һәм улы янына барып йөри торган иде. Төннәрдән бер төнне, ул төшендә бердәнбер улы булган Исмәгыйль галәйһиссәламне, Аллаһ ризалыгы өчен корбан кылганын күрде. Бу төш берничә тапкыр кабатлангач, ул үзенең газиз баласы Исмәгыйльне корбан итеп чалырга тиешлеген аңлады. Чөнки пәйгамбәрләрнең төшләре хак. Үзенең төшен улына хәбәр иткәч, Исмәгыйль Аллаһның әмеренә буйсынып, үзен корбан итәргә ризалыгын белдерде. Аллаһу әкбәр! Бу, Аллаһка буйсынуның, итагатьнең зур дәрәҗәдә булуын күрсәтте.

Ибраһим галәйһиссәлам Исмәгыйльне Аллаһ ризалыгы өчен корбан кылырга алып барганда, шәйтан Ибраһим галәйһиссәлам янына килеп: «Мин шәйтан, төшеңә дә мин килдем», — дип, аны ошбу эшеннән биздереп үзенә буйсындырмакчы булды. Ибраһим галәйһиссәлам җиде таш алып шәйтанга атты. Бераздан ул икенче, өченче тапкыр килде һәм анысында да Ибраһим галәйһиссәламнән шул ук җавапны алды.

Инде Ибраһим галәйһиссәлам бердәнбер булган улын — Исмәгыйльне, Раббысы ризалыгы өчен корбан чалам дигәндә, Аллаһ Исмәгыйльне саклап алып калды. Исмәгыйль урынына Ибраһим عليه السلام сарык чалды. Бу бөек гамәл Кыяматкә кадәр шәригатебездә сак-ланып калды.

Бу хакта Коръәндә менә ничек әйтелә (мәгънәсе): **«Без Ибраһимгә бер ир бала белән шатлык хәбәрен бирдек, ул бала кечкенә чагында галим, олуг хәлендә йомшак күңелледер. Ул бала үсеп атасы илә йөри башлагач, Ибраһим әйтте: «Әй улым, мин төшемдә Аллаһ тарафыннан сине корбан итеп чалырга боерыламын, бу эшкә ничек карыйсың?». Улы Исмәгыйль әйтте: «Әй атам, ни белән боерылган булсаң, шуны эшлә, мин Аллаһ хөкеменә ризамын, бу эштә мине, Аллаһ теләсә, сабыр итүчеләрдән табырсың». Безнең әмерне икесе дә риза булып кабул иттеләр һәм Исмәгыйльне корбан кылырга дип яны белән яткызды. Без нида кылдык: «Әй Ибраһим, төшеңдә күргән Безнең әмерне тәсдыйк кылдың, үтәгән хөкемендә булдың». Әнә шулай Үзебезгә итагать иткән яхшы**

**мөэминнәрне изге җәзалар белән нигъмәтлибез. Аллаһның: «Изге балаңны корбан итеп чал!», — дигән әмере, әлбәттә, зур һәм авыр сынау. Без аңа Исмәгыйль урынына корбан итеп бугазлар өчен сарык малын бирдек. Яхшылыгы белән искә алу өчен, дөньяга соңыннан килгәннәргә Ибраһимнең яхшы әсәрләрен калдырдык. Ул Ибраһимгә барча галәм сәлам әйтер. Яхшы эшләрне кылучыга, Без шулай изгелек итәбез. Ибраһим, Безнең хак мөэмин колларыбыздан».** (Саффәт: 101 – 111)

Шуннан соң Аллаһ тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә Кәгъбәтулланы күтәрергә (төзергә) боерды. Аңа бу эшендә Исмәгыйль галәйһиссәлам булышты. Аллаһның ярдәме белән Кәгъбәтулланы күтәреп бетергәч, алар бик тә шатланып Раббыларына ялварып дога кылдылар.

Коръәндә бу хакта болай диелде (мәгънәсе): **«Ибраһим илә Исмәгыйль Кәгъбатулланың нигезен күтәргәч: «Әй Раббыбыз! Эшебезне кабул ит! Син ишетүче һәм күңелләрне белүчесең», — дип дога кылдылар. «Әй Раббыбыз! Икебезне дә үзеңә итагать итүче мөселманнардан кыл һәм нәселебездән дә мөселман булган җәмәгатьне насыйп ит һәм безгә хаҗ гамәлләрен өйрәт вә тәүбәләребезне кабул итеп гөнаһларыбызны гафу ит! Син, әлбәттә, тәүбәләрне кабул итүче, рәхимлесең. Әй Раббыбыз! Бездән соң нәселебезгә үзләре арасыннан пәйгамбәр күндер! Ул пәйгамбәр, аларга Синең Китабыңны, Ислам диненең бөтен хөкемнәрен өйрәтер һәм аларны мөшриклектән вә хәрамнардан пакьләр. Әй Раб-**

**бызбыз! Шиксез, Сиңа тиңдәш юк, Син көч-кодрәт һәм хикмәт иясесең».** (Бәкара: 127 – 129)

Ибраһим галәйһиссәламнең олы яшьтә булган вә бала таба алмаган Сарадан тагын бер малае туды. Аңа «Исхак» дип исем куштылар. Бу аларга Аллаһның зур бүләге иде.

Коръәндә бу хакта болай әйтелде (мәгънәсе): **«Ибраһимнең ﷺ хатыны да шунда аяк өстендә иде һәм көлеп җибәрде. Ул хатынга Исхак исемле бала тудырмагы белән сөенеч хәбәр бирдек вә Исхактан Ягъкуп исемле бала булыр, дип. Ул хатын әйтте: «Вәй, нинди гаҗәп! Карт карчык булганым хәлдә бала тудырырмынмы? Ошбу минем ирем дә карт инде, без карт кешеләрдән бала булуы бер гаҗәп эштер». Фәрештәләр әйттеләр: «Аллаһ тәгаләнең әмеренә гаҗәпләнәсезме? Әй пәйгамбәрлек заһир булган өй кешеләре! Сезгә Аллаһның рәхмәте вә бәрәкәте булачак. Ул — Аллаһ, эшләгән эшләрендә макталырга тиешле булган бик олуг бер зат».** (Һүд: 71 – 73)

Сара Раббысы ризалыгы өчен сабыр иткәненә күрә, Аллаһ аны шулай бүләкләде һәм Исхактан соң Ягъкуп дөньяга килде.

Шуның белән, без Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәр хакындагы кыйссабызны тәмамлыйбыз. Раббыбыз ошбу гыйбрәтләр белән вәгазьләнеп, изге гамәлләр кылырга насыйп итсен.Әмин!

Инде балалар, киләсе пәйгамбәр тормышында очрашуга кадәр, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Әтисе көферлектә булса да, Ибраһим галәйһиссәлам аның белән яхшы мөгамәлә итте.

**2)** – Ибраһим عليه السلام кавемен төрле ысуллар белән иманга чакырса да, бик азы гына иман китерде.

**3)** – Аллаһ тәгаләнең Ибраһим галәйһиссәламне уттан саклап калуы бер могҗиза булып, аның иманын тагы да арттырды.

**4)** – Аллаһка буйсыну, итагатьле булу — иманнан.

**5)** – Ибраһим عليه السلام Аллаһ ризалыгы өчен хәтта бердәнбер баласын да кызганмады.

**6)** – Исмәгыйль عليه السلام әтисенә итагатьле икәнлеген белдерде.

**7)** – Аллаһ тәгалә Исмәгыйльне عليه السلام Үзенең чиксез кодрәте белән саклап алып калды һәм башка нәрсәне корбанга боерды.

**8)** – Ибраһим عليه السلام белән Исмәгыйль عليه السلام бергә, Аллаһның әмерен җиренә җиткереп үтәделәр.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Аллаһ тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне ни өчен пәйгамбәр итеп җибәрде?

**2)** – Аллаһ тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне нинди кавемгә пәйгамбәр итеп җибәрде?

**3)** – Ибраһим галәйһиссәламнең әтисе иман китердеме?

**4)** – Ибраһим галәйһиссәлам потларны нишләтте?

**5)** – Ни өчен Ибраһим галәйһиссәлам потларны җимерде?

**6)** – Мөшрикләр потларның җимерелгәнен белгәч Ибраһим галәйһиссәламне нишләттеләр?

**7)** – Ибраһимне عليه السلام уттан кем коткарды?

**8)** – Ибраһимнең عليه السلام балаларын әйтеп уз!

**9)** – Исмәгыйльнең عليه السلام әнисенең исеме ничек?

**10)** – Исмәгыйль عليه السلام әтисенә итагать иттеме?

**11)** – Ибраһим галәйһиссәлам нинди төш күрде?

Буш урыннарга тиешле сүзләрне куй:

**1)** – Ибраһим عليه السلام мөшрикләрнең ............................. җимерде.

**2)** – Ибраһим галәйһиссәлам ................................. исемле залим патшаны иманга чакырды.

**3)** – .................................... галәйһиссәлам хатыны .................... белән малае Исмәгыйльне ...................... калдырды.

Дөрес җөмлә артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата булган җөмлә артына ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Ибраһим галәйһиссәламнең Исмагыйль һәм Исхак исемле ике баласы булды (  )

**2)** – Сара Исмәгыйль галәйһиссәламнең әнисе (  )

**3)** – Ибраһимнең عليه السلام әтисе аучы иде (  )

**4)** – Исмәгыйль عليه السلام әтисенә Кәгъбәтулланы күтәрергә булышты (  )

# Исхак عليه السلام

Әйтүебезчә, Ибраһим галәйһиссәлам белән хатыны Сараның башта балалары юк иде. Шулай ук мәгълүм булганча, әгәр хатын-кыз зур яшькә җитә икән, ул вакытта ул бала таба алмый. Сара менә шундый бала таба алмый торган олы яшькә җиткәч, Аллаһ тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне, хатыны Сараның Исхак исемле ир бала табачагы белән шатландырды. Ә Исхакның Ягъкуп исемле малае булачагын белгертте.

Гәҗәеп, бик тә гәҗәеп бу хәл. Безнең акылларыбыз сурәтли торган эш түгел бу. Без иләһи көч каршында зәгыйфьбез. Аллаһ бер нәрсәгә бул дисә, ул әйбер була. Шуңа да без Аллаһ тәгаләгә буйсынып, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә тиешбез. Фәрештәләр килеп Ибраһим галәйһиссәламне шул хәбәр белән шатландыргач, Ибраһим галәйһиссәлам дә, хатыны Сара да, инде олы яшьтә булганга моңа аптырап калдылар.

Аллаһ тәгалә бу хакта Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Тәхкыйк, Безнең илче фәрештәләребез, бала белән сөенеч бирмәк өчен Ибраһим галәйһиссәламгә килеп сәлам бирделәр. Ибраһим: «Сезгә дә сәлам булсын», — диде. Озакка сузмыйча, Ибраһим симез бозау итен пешереп кунаклар**

**алдына алып килде. Кунаклар кулларын иткә сузмагач, Ибраһим аларны яратмыйча, хәтта алардан шикләнеп куркуга төште. Фәрештәләр әйттеләр: «Син бездән курыкма, тәхкыйк, без Лут кавемен һәлак итәр өчен җибәрелгән фәрештәләрбез». Ибраһимнең** عليه السلام **хатыны да шунда аяк өстендә иде, хатыны Ибраһимның куркуыннан көлде. Сөенеч хәбәр бирдек, ул хатынга Исхак исемле бала тудырмагы белән вә Исхактан Ягъкуп исемле бала булыр, дип. Ул хатын әйтте: «Вәй, нинди гаҗәп! Карт карчык булганым хәлдә бала тудырырмынмы? Ошбу минем ирем дә карт инде, без карт кешеләрдән бала булуы бер гаҗәп эш». Фәрештәләр әйттеләр: «Аллаһ тәгаләнең кодрәтенә гаҗәпләнәсезме? Әй пәйгамбәрлек заһир булган йорт әһелләре! Сезгә Аллаһның рәхмәте вә бәрәкәте булачак. Ул — Аллаһ, эшләгән эшләрендә макталырга тиешле булган бик олуг бер зат».** (Һуд: 69 – 73)

Мәгънәсе: **«Минем хак мөэмин бәндәләремә хәбәр бир, тәхкыйк, Мин үземә итагать итүче бәндәләремне ярлыкаучы вә аларга рәхмәт итүчемен. Дәхи, Минем газабым Миңа итагать итмәгәннәргә бик каты газап. Дәхи, бәндәләремә Ибраһимнең кунакларыннан хәбәр бир!». Кунаклар Ибраһим янына кергәч, сәлам бирделәр, алар фәрештәләр иде, Ибраһим: «Мин сездән куркамын», — диде. Фәрештәләр әйттеләр: «Син бездән курыкма, без сиңа шатлыклы хәбәр китердек, сездән бер галим бала туачак». Ибраһим гәләйһиссәлам әйтте: «Гаҗәп, сез миңа карт кө-**

**немдә бала белән сөенеч бирәсезме? Нинди гаҗәп нәрсә белән хәбәр бирәсез!». Фәрештәләр әйттеләр: «Без сиңа булачак хак хәбәр белән сөенеч бирәбез, син өмет өзүчеләрдән булма!». Ибраһим әйтте: «Әлбәттә, мөэмин бәндә Раббысының рәхмәтеннән өмет өзмәс, мәгәр адашкан кешеләр генә өмет өзәрләр».** (Хиҗер: 49 – 56)

Исхак галәйһиссәлам туып әтисе вә әнисенең кочагында тәрбияләнде. Зурайгач, әтисе кебек үк кешеләрне иманга чакыра башлады. Иман китереп Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылып, Аңа ширек катмасалар, аларны бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхет көткәне белән шатландырды. Ә инде көферлекләрендә калып Аллаһка буйсынмасалар, ул вакытта аларны мәңгелек Җәһәннәм газабы көткәнлеге белән куркытты.

Исхак галәйһиссәлам өйләнгәч, аның Ягъкуп исемле малае туды. Шушы бала белән, Аллаһ тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне шатландырган хәбәр тормышка ашты.

Коръәндә бу хакта болай диелде (мәгънәсе): **«Ул Ибраһимгә, барча галәм сәлам әйтер. Яхшы эшләрне кылучыга, Без шулай изгелек итәбез. Ибраһим, Безнең хак мөэмин колларыбыздан. Дәхи, Исхакны бирәчәгебез белән шатлыклы хәбәр бирдек, ул Исхак изгеләрдән вә пәйгамбәрләрдән булды. Ибраһимгә вә Исхакка эшләрендә вә нәселләрендә бәрәкәт бирдек вә аларның нәселеннән килгән кешеләрнең бәгъзеләре изгеләр һәм бәгъзеләре көферлек**

**вә бозыклык белән үзләренә ачык золым итүчеләрдән».** (Саффәт: 109 – 113)

Исхак галәйһиссәлам ошбу дөньядан киткәнчегә кадәр кешеләрне туры-хак, иман юлына чакырды. Ул вафат булгач, аның дәгъват юлын, малае Ягъкуп галәйһиссәлам дәвам итте.

Шушының белән, балалар, без Исхак галәйһиссәлам турындагы кыска гына булган кыйссабызны тәмамлыйбыз. Аллаһ тәгалә файдалы гыйлемнәр белән изге гамәлләр кылырга насыйп итсен. Әмин!

Киләсе пәйгамбәр тарихында очрашканга кадәр, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!




Исхак عليه السلام Фәләстыйн җиренең Хеврон (Хәлил) шәһәрендә туып үсте. Аллаһ тәгалә аны шул җирдәге халыкларга пәйгамбәр итеп җибәрде һәм ул Хевронда вафат булып күмелде.

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Аллаһ тәгаләһәрнәрсәгә көче җитүче.

**2)** – Сара бала табасын белгәч, бу хәбәрдән аптырап калды, чөнки ул инде зур яшьтә иде.

**3)** – Сара иманга чакыру юлында Ибраһим عليه السلام белән бергә авырлыкларга сабыр итте.

**4)** – Исхак عليه السلام, әтисе Ибраһим عليه السلام кебек үк дәгъват юлында булды.

**5)** – Без Аллаһка буйсынып яшәргә тиешбез.

**6)** – Аллаһка тәвәккәл кылып, Аннан риза булу — бәхеткә илтә.

**7)** – Аллаһ тәгалә бернәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа: «Бар бул», — ди һәм ул була.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Исхак عليه السلام туганда, Ибраһим عليه السلام белән Сара нинди яшьтә иделәр?

**2)** – Исхак عليه السلام дәгъваттә нинди юл сайлады?

Буш урыннарга дөрес сүзләр куеп җөмләләрне тулыландыр:

**1)** – Ибраһимнең عليه السلام Хәҗәрдән ............. исемле малае туды, ә Сарадан ............... исемле малае туды.

**2)** – Сара Ибраһимгә عليه السلام .............. өйләнергә тәкъдим итте, хәтта баласы булып аңа ................. чакыруда ярдәмче булсын өчен.

**3)** – Исхак галәйһиссәламнең ..................... исемле малае булды.

# Лут عليه السلام

Иорданиядә, «Үле диңгез» буенда, «Сәдүм» дигән борынгы шәһәрләрдән саналган бер шәһәр бар. Аның кешеләре дәими рәвештә бозыклыкта яшәделәр. Аллаһ хәрам кылган нәрсәләрне үзләренә хәләл кылып, барча бозыклыкларны яхшыга санап, изгелекләрне начарга чыгардылар. Алар яңадан яңа бозыклыклар уйлап чыгарып көннәрен үткәрә торган иделәр. Хәтта, Аллаһ хәләл кылган хатыннарын ташлап, ир-атлар белән зина кыла башладылар. Һәм шуның белән, моңа кадәр җир йөзендә кеше кылмаган беренче зур фәхишәлек вә гөнаһ эшләделәр. Үзләренең бозык әхлаклары белән, Үзенә гыйбадәт кылыр өчен яраткан Раббыларын бөтенләй оныттылар.

Аллаһ тәгалә аларга туры юлны күрсәтүче итеп, Лут галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрде. Ул Ибраһим галәйһиссәламнең абыйсының малае иде. Аның белән Фәләстыйн җиренә күченеп шунда калды.

Лут галәйһиссәлам Сәдүм шәһәренә барып, бозыклыкка баткан кавемне, көферлекләрен ташлап вә тәүбә кылып, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыра башлады. Гөнаһлы эшләрен ташламасалар, аларны Аллаһ тәгаләнең газабы тотачаклыгы белән

куркытты. Ә инде тәүбә итеп Аллаһка кайтсалар һәм Аңа гына гыйбадәт кылып иман белән бу дөньядан китсәләр, ахирәттә аларга Җәннәт булачагы белән вәгазьләде.

Әмма аларның йөрәкләрен тәкәбберлек баскан иде. Шуңа да Лут галәйһиссәламгә бик азы гына ияреп иман китерде. Калганнары аны мыскыллап көлделәр вә: «Без сиңа иман китермибез, чөнки син безнең кебек үк бер бәндәсең һәм әгәр дә син шул эшеңне туктатмасаң, без сине бу җирдән куып чыгарабыз», — диделәр.

Лут галәйһиссәлам бу сүзләргә игътибар бирмичә дәгъватен дәвам итте. Бу хакта Аллаһ тәгалә Корьәндә болай диде (мәгънәсе): **«Кардәшләренә Лут пәйгамбәр әйтте: «Әллә сез Аллаһтан курыкмыйсызмы, Аллаһка гыйбадәт кылу урынына һичнәрсәгә ярамаган нәрсәгә гыйбадәт кыласыз. Мин, әлбәттә, сезгә хак пәйгамбәрмен ки, миннән зарар күрүдән иминсез. Аллаһтан куркыгыз, Аңа каршы барудан сакланыгыз һәм минем әмеремә итагать итегез! Ислам шәригатен өйрәткәнем өчен сездән хак сорамыйм, минем гамәлемнең савабы — галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһ хозурында».** (Шәгыйрьләр: 161 – 164)

Лут аларга карата рәхимле булды. Аларның шундый хәлдә булуларын кызганып яхшылык теләп кабаттанкабат аларны тәүбә кылырга чакырды. Ул фәхишәлек гамәлләрнең дингә дә, акылга да сыймаганлыгын аңлатты. Корьәндә бу хакта болай диелде (мәгънәсе): **«Дөньяда кешеләр арасыннан сез ирләргә якынлык кылып, Раббыгыз сезнең**

**өчен халык кылган хатыннарны калдырасызмы? Бәлки сез хәләлдән хәрамга үтүче юньсез кавемсез!».** (Шәгыйрьләр: 165 –166)

Мәгънәсе: **«Лутны хәтерләгез, ул кавеменә әйтте: «Ничек инде сез белә торып, бик яман фәхеш эшне эшлисез? Ничек инде сез хатыннарны куеп, ирләргә якынлык кыласыз? Бәлки сез эшегезнең ахыры ничек булачагын уйламый торган җәһил кавемсез!».** (Нәмел: 54 – 55)

Кәферләр Лут галәйһиссәламне вә аңа иман китергән барча мөэминнәрне изгелеккә чакырганнары өчен, җирләреннән куып чыгармакчы булдылар.

Аллаһ тәгаләдән бу бозык кавемне юкка чыгару турында боерык килде. Башта фәрештәләр Ибраһим галәйһиссәлам янына килделәр. Ул аларны кунак итеп ризык тәкъдим итте. Әмма фәрештәләр нурдан яратылган нәфис мәхлуклар; ашамыйлар, эчмиләр, Аллаһка гөнаһ кылмыйча Аның кушканнарына гына буйсыналар. Алар Раббыларының теләге белән төрле сурәтләргә керергә мөмкиннәр.

Фәрештәләрнең Ибраһим галәйһиссәламгә ки-лүе хакында Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Сиңа ирештеме Ибраһим пәйгамбәрнең хөрмәтле кунакларының хәбәре? Ул кунаклар Ибраһим хозурына кергәч, сәлам бирделәр, Ибраһим дә аларга сәлам бирде һәм күңеленнән: «Болар ят кунаклар, танымыймын», — диде. Ибраһим кунакларга кайда барганын белдермичә, хатыны янына аш хәзерләргә китте, бераз вакыт үткәч, симез бозау итен китерде. Ул итне кунакларның аллары-**

**на якын куйды, кунаклар исә ашамадылар, чөнки алар фәрештә иделәр, ләкин Ибраһим белми иде. Ибраһим кунакларга: «Ашамыйсызмы?», — диде. Кунаклар ашамагач Ибраһимнең күңеленә курку төште, ихтимал бу кешеләр начар ният белән килгәннәрдер, дип уйлады. Кунаклар үзләренең фәрештәләр икәнне белдереп, Ибраһимгә: «Курыкма», — диделәр һәм зур галәмәт буларак, бер ир бала белән Ибраһимгә сөенеч бирделәр. Кунакларның сүзен ишетеп, Ибраһимнең хатыны Сара, кунаклар алдына тавышланып чыкты вә йөзенә сугып әйтте: «Мин бала тапмый торган карчыкмын, миндә кайдан бала булсын?», — дип. Фәрештәләр әйттеләр: «Раббың — Аллаһ, без әйткәнчә әйтте, чынлыкта Ул — Аллаһ, һәр эшне хикмәт белән эшләүче вә һәрнәрсәне белүче». Ибраһим җибәрелгән илчеләрдән: «Әй илчеләр, сез нинди эш белән килдегез?», — дип сорады. Фәрештәләр: «Без, бозыклык кылучы кавемне һәлак итәр өчен җибәрелдек, алар өстенә балчыктан ясалган ташларны яудырмак өчен, ул ташлар Раббың хозурында чиктән чыгып азган кавемнәрне үтерү өчен хәзерләнгән», — диделәр. Без ул шәһәрдән, Лут кавеменнән мөэмин булган кешеләрне чыгардык. Лут пәйгамбәр кавеме шәһәрләрендә бер генә мөселман йортын таптык, ягъни Лут пәйгамбәр йорты гына мөселман йорты иде. Алар яшәгән шәһәрләрдә, аларның һәлак булганлыгын күрсәтүче галәмәтләр калдырдык, рәнҗетүче Аллаһ газабыннан куркучылар өчен».**
(Зарият: 24 – 37)

Ибраһим галәйһиссәлам: «Ул кавем бәлки тәүбә итәр вә аларның араларында Лут галәйһиссәлам бар», — дип, фәрештәләргә бераз кичектерергә сорагач, фәрештәләр: «Без анда кем барлыгын беләбез», — диделәр.

Аллаһ бу күренеш хакында болай диде (мәгънәсе): **«Җибәрелгән фәрештәләр Ибраһимгә шатлык хәбәре илә килгәч, ул фәрештәләр әйттеләр: «Без бу Лут шәһәренең халкын һәлак итүчебез, тәхкыйк ул шәһәрнең халкы имансыз залим булдылар». Ибраһим әйтте: «Бит ул шәһәрдә Лут пәйгамбәр бар». Фәрештәләр әйттеләр: «Без ул шәһәрдә кемнәр барлыгын яхшы беләбез, әлбәттә, без Лутны вә аңа ияргән мөэминнәрне коткарачакбыз, мәгәр хатынын коткармабыз, чөнки ул газапта калучылар җөмләсеннән булды».** (Гәнкәбүт: 31 – 32)

Мәгънәсе: **«Әй Ибраһим! Лут кавеме хакында бәхәсләшүдән читләш, тәхкыйк, Раббыңнан аларга газап белән әмер килде, шиксез аларга газап килүче, инде ул килүче газап алардан һич тә кире китмәс».** (Һуд: 76)

Шуннан соң фәрештәләр бик тә чибәр ир-ат сурәтенә кереп Сәдүм шәһәренә килделәр һәм Лутның عليه السلام йортында туктадылар. Лут عليه السلام үзенең йорт әһелен кисәтеп, килгән кунаклар хакында беркемгә дә сөйләмәскә кушты. Ләкин, иман китермәгән хатыны чыгып кешеләргә хәбәр итте һәм Җәһәннәм әһелләреннән булды.

Бу хакта Аллаһ тәгалә болай диде (мәгънәсе): **«Аллаһ мисал итеп зекер итте, хакны инкяр итүче**

**кәферләргә Нух пәйгамбәрнең хатынын вә Лут пәйгамбәрнең хатынын. Бу ике хатын Безнең ике изге колларыбызның кул астында иделәр, бу ике хатын үзләренең ирләре булган пәйгамбәрләргә хыянәт иттеләр, ирләренә зарар итәргә теләделәр. Бу ике хатынның, ирләре булган бу ике пәйгамбәр, Аллаһ газабыннан һичнәрсәне җибәрә алмадылар, ягъни пәйгамбәр булсалар да, хыянәтче хатыннарын Аллаһ газабыннан коткара алмадылар. Вә ул хатыннарга утка керүчеләр белән бергә утка керегез, дип әйтелде».** (Тәхрим: 10)

Күп вакыт узмады, Лут галәйһиссәламнең ишеген шакыдылар һәм кавеме Лут галәйһиссәламнән кунакларын таләп иттеләр. Ул кавеме белән төрлечә сөйләшеп карады. Аларга: «Аллаһтан куркыгыз, мине кунакларым алдында рисвай итмәгез, сезнең арагызда акыллы ир юкмы әллә?», — дип кисәтте. Берничек тә аларны туктата алмагач, кәферләрдән сакланыр өчен, ул көч-куәт булуын теләде. Кунаклар аңа: «Әй Лут, хакыйкатьтә, без Раббыбызның илчеләребез, һич тә курыкма! Вә бу эшне безгә калдыр, без Аллаһның әмерен үтәрбез. Син иман китергән кешеләрне ал да, Аллаһның газабы төшкәнче бу җирдән чыгып кит», — диделәр.

Төн узып киткәч, Лут галәйһиссәлам башка иман китергән мөэминнәр белән, ул бозык-залим кешеләр җиреннән чыгып китте.


Иртә белән җир тетри башлады. Шәһәрнең астыөскә килде. Аллаһ Үзенең чиксез кодрәте белән таш яудырып, ул золымлык чыганагы булган урынны җир белән тигезләде.

Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Илче фәрештәләребез Лут хозурына килгәч, Лут фәрештәләр хакында кайгыра калды, чөнки фәрештәләр бик чибәр егетләр кыяфәтендә килделәр. Лут аларның фәрештә икәнлекләрен белмәде, хәтта алар хакында күкрәге кысылды, күңеле сынды вә әйтте: «Бу көн авыр көн, ни булыр инде?». Лутның явыз хатыны: «Лутка бик чибәр кунак егетләре килде, барып файдаланыгыз», — дип залимнәр арасына хәбәр таратты. Әлеге азган халык Лут өенә йөгерешеп килделәр, моннан элек тә алар яман эшләрне кылдылар. Аларның яман эшләре шул: яшь егетләрне кызлар итеп кулланырлар иде. Лутның кунаклары янына йөгерешеп килүләре дә шуның өчен иде. Лут аларга әйтте: «Әй кавемем, менә минем сезгә кызларым, никахлап алыгыз да, якынлык кылыгыз, алар сезне гөнаһтан пакьләр. Аллаһтан куркыгыз, хәләл бар чагында хәрамнан сакланыгыз, мине кунакларым алдында рисвай итмәгез! Әллә сезнең арагызда бу яман эшнең кабахәтлеген белүче бер ир дә юкмы? Әгәр арагызда акыллы ир булса, сезне бу эштән тыяр иде». Әйттеләр: «Әй Лут, үзең беләсең, синең кызларыңда безнең хаҗәтебез юк, дәхи безнең нәрсә теләгәнебезне дә беләсең ки, без синең кунакларыңны телибез». Лут әйтте: «Әгәр минем сезгә куәтем җитсә иде, яки бер куәтле җәмәгатькә мөрәҗәгать итәргә көчем булса иде, әлбәттә, мин сезне ни эшләтергә белер идем». Фәрештәләр әйттеләр: «Әй Лут, без Раббыңның илчеләребез, кавемең**


**сиңа һич зарар кыла алмас, син кичнең бер вакытында өй җәмәгатеңне алып чыгып кит, сездән һичберегез аерылып калмасын, мәгәр залимнәр ягына авышкан хатыныңны алып чыкма, тәхкыйк кәферләргә килә торган газап хатыныңа да ирешер. Дөреслектә, бу кәферләрнең газап кылынырга вәгъдәләре таң вакытыдыр, әллә таң якын түгелме?». Аларга газап белән әмеребез килгәч, шәһәрләрен астын өскә әйләндердек һәм алар өстенә таш яудырдык, ул ташлар кыздырылган булыр. Раббың хозурында «газап ташы» дип галәмәтләнмеш. Ул ташлар башка залимнәргә дә ерак түгел».** (Һуд: 77 – 83)

Шулай итеп, кадерле балалар, Аллаһ тәгалә Аңа иман китермичә кәфер булганнарны газап кылып юкка чыгарды, ә инде иман китереп, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелганнарны саклап алып калды.

Шушының белән, Лут галәйһиссәлам хакында кыйссабызны тәмамлыйбыз. Киләсе пәйгамбәрнең тормышында очрашканчыга кадәр, вәссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!




Лут ﷺ кавемен каты газап тоткан урын хәзерге көндә «Үле диңгез» дип атала. Кайбер галимнәр әйтүенчә, «Үле диңгез» Аллаһ тәгалә Лут г.с.нең кавемен һәлак кылганчы булмаган. Ул кавем яшәгән урында каты җир тетрәве булып, шәһәрнең асты-өскә әйләнә. Ошбу җир тетрәүдән соң ул урын диңгез тигезлегеннән якынча 392м. аска төшә. Хәзерге вакытта, Лут г.с. кавеме газап кылынган урын җир йөзендә иң түбән урын дип санала. Ул диңгездә балыклар, үсемлекләр кебек һичбер яшәү билгесе юк һәм шуңа да «Үле» дип атала. Аллаһу әгъләм.




يعتقد بعض الباحثين وأهالي الغور في الأردن بأن هذا المكان هو كهف النبي لوط عليه السلام

المؤلف في منتصف الطريق المؤدي إلى كهف لوط عليه السلام بدير عين عباطة في غور الصافي بالأردن

**Беренче:** Кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Сәдүм шәһәре Иорданиядәге «Үле диңгез» буенда урнашкан.

**2)** – Лут عليه السلام кавеменең әхлаклары бик тә кабахәт иде.

**3)** – Лут галәйһиссәлам кавеме белән бик тә рәхимле булды.

**4)** – Аллаһка итагать итү, бозыклыктан саклый.

**5)** – Фәхешлек вә бозыклыклардан ерагаю, җәмгыятьнең әхлагын саклый.

**6)** – Аллаһ тәгалә Лут кавемен, Аңа буйсынмыйча гөнаһлы эшләр эшләгәннәре өчен газап кылды.

**7)** – Лут галәйһиссәламнең хатыны, аларда кунак барлыгы хакында залимнәргә хәбәр итте.

**8)** – Лут галәйһиссәлам кавеменнән, аны кунаклары алдында рисвай кылмаска (оятка калдырмаска) дип үтенде.

**9)** – Аллаһ тәгалә залимнәрне золымлыклары вә җирдә бозыклык таратканнары өчен юкка чыгарды.

**10)** – Аллаһның вәгъдә иткән газабыннан һичбер кәфер котыла алмый.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Ни өчен Аллаһ тәгалә Лут галәйһиссәламне кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрде?

**2)** – Лут галәйһиссәламнең иманга чакырудагы ысулын аңлат.

**3)** – Лут عليه السلام кавемендә нинди бозыклык таралган иде?

**4)** – Лут галәйһиссәламнең хатыны иман китердеме?

**5)** – Лут عليه السلام кавеменең ахыргы нәтиҗәсе нинди булды?

Дөрес җөмлә артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата булган җөмлә артына ( Х ) ошбу билгене куй:

**1)** – Лутның عليه السلام хатыны иман китермәде (  )

**2)** – Лут عليه السلام кавеменең барысы да иман китерде (  )

**3)** – Аллаһ тәгалә ул кавемне көчле җил белән һәлак итте (  )

# Ягъкуп ﻋَﻠَﻴْﻪِ ﭐﻟﺴَّﻼَﻡُ

Ягъкупның әтисе — Исхак дөньяга килгәнче үк, Аллаһ тәгалә Ибраһим галәйһиссәлам белән Сараны оныклары Ягъкуп белән шатландырды.

Бу хакта Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Ибраһим галәйһиссәламнең хатыны да шунда аяк өстендә иде, хатыны Ибраһимның куркуыннан көлде, сөенеч хәбәр бирдек, ул хатынга Исхак исемле бала тудырмагы белән вә Исхактан Ягъкуп исемле бала булыр», — дип».** (Һуд: 71)

Ягъкуп галәйһиссәлам зур үскәнчегә кадәр, әтисе — Исхак галәйһиссәламдә тәрбияләнде. Соңыннан әтисе яныннан чыгып китеп, Фәләстыйндагы Хәрран дигән җиргә юнәлде. Юлда аны йокы басып, төшендә фәрештәләрнең шул урында төшеп-менгәннәрен күрде. Уянгач ул үз-үзенә: «Бу урын, хакыйкатьтә, мөбәрәк урын», — дип, анда Аллаһка гыйбадәт кылу йортына таш салды.

Ул урын хәзерге вакытта, Фәләстыйндагы Әл-Әкъса мәчете икәнлеге белән билгеле булды. Ул урыннарны менә ничә еллар инде яһүдләр басып алып, үзләренеке дип атыйлар. Әлбәттә, аларның бу җирләрне үзләренеке дип атаулары ялган, чөнки алар Әл-Әкъса мәчетен җимереп, үзләренең гыйбадәт кылу урыны дип атаган, Сөләймән һәйкәлен төземәкче бу-

лалар. Яһүдләр күпме генә мәкерлек кылсалар да, Аллаһ тәгалә җиңүне мөселманнарга бирәчәк. Чөнки, яһүдләр тәкәбберләнделәр һәм көферлектә батып Аллаһның ләгънәтен алдылар.


Кешеләр Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып, бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле булсыннар өчен, Ягъкуп галәйһиссәлам дә әтисе кебек үк аларны изгелеккә чакырып, бозыклыктан, гөнаһлы эшләрдән ераклашырга өндәде.

Ягъкуп галәйһиссәламнең, унике баласы бар иде. Алар арасында Яһүдә исемлесе булып, аның иярченнәре үзләрен яһүдләр дип атадылар. Әмма Ягъкуп галәйһиссәлам Исраил дип йөртелде һәм шуңа да аның иярченнәре «Бәнү Исраил» дип аталды. Бәнү Исраил яһүдләре Аллаһка иман китереп, Аңа итагать итеп, Ягъкуп галәйһиссәламне тыңлап яшәделәр. Шулай итеп көннәр узды... Әмма шәйтан үзенең эшен, вәсвәсәсен ташламады. Аларның әхлакларын бозды һәм алар бозыклыклар эшләп, җир өстендә тарата башладылар. Аллаһның әмереннән ераклашып гөнаһлы эшләргә баттылар. Хәтта, аларны хак юлга өндәүче, Аллаһның диненә чакыручы пәйгамбәрләрне дә үтерделәр һәм шуның белән Аллаһ тәгаләнең ачуын алдылар. Аллаһ Раббуль-Гыйззә аларны маймыллар вә дуңгызлар сурәтенә кертеп, Үзенең рәхмәтеннән сөрде. Шулай итеп, яһүдләр Аллаһның ләгънәтенә дучар булдылар. Ул кавем арасыннан бәгъзеләре иман китереп, Аллаһның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелдылар. Алары Раббыбызның рәхмәтенә ирештеләр.

Ягъкуп галәйһиссәламнең кыйссасы моның белән генә бетми әле, кадерле балалар. Без аны тагын Йосыф галәйһиссәлам кыйссасында искә алырбыз. Хәзергә газизләрем, Йосыф галәйһиссәлам кыйссасында очрашканга кадәр, вәссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!




Ягъкуп ﷺ Хәрран шәһәренә күченгәннән соң, күпмедер еллар узгач яңадан Хевронга кайтты. Улы Йосыфка, Аллаһ тәгаләдән пәйгамбәрлек вәхи булып, Мисырда табылгач, барча балалары белән шунда күченде һәм Мисырда вафат булды. Васыяте буенча Ягъкупне ﷺ Хевронга (Хәлил) алып кайтып җирләделәр. Аллаһу әгъләм.




Ягъкуп галәйһиссәламнең шәҗәрәсе

**Беренче:** Кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Ягъкуп галәйһиссәлам үзе дә, әтисе дә, бабасы да — пәйгамбәрләр иделәр.

**2)** – Аллаһ тәгалә, Ибраһимнең عليه السلام улы Исхак туганчы инде, аны оныгы Ягъкуп عليه السلام белән шатландырды.

**3)** – Яһүдләр әл-Әкъса мәчетен җимереп, аның урынына үзләренең гыйбадәт кылу урыны дип атаган «Сөләймән һәйкәлен» төземәкче булалар.

**4)** – Яһүдләрнең әл-Әкъсаны җимерү уйлары барып чыкмаячак.

**5)** – Ягъкуп عليه السلام әтисе кебек үк, кешеләрне изгелеккә өндәп, бозыклыктан вә гөнаһлы эшләрдән тыйды.

**6)** – Барча пәйгамбәрләр дә кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырдылар.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Ягъкуп عليه السلام кайда яшәде?

**2)** – Ягъкуп عليه السلام нинди дәгъват кылды?

**3)** – Ягъкуп عليه السلام кайсы җирләргә юнәлде?

**4)** – Яһүдләр нинди мәкерлек уйлыйлар?

**5)** – Яһүдләр әл-Әкъса мәчетен җимерә аламы?

**6)** – Ни өчен?

Дөрес җөмлә артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата булган җөмлә артына ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Ягъкупның عليه السلام әтисе Исмәгыйль عليه السلام иде (  )

**2)** – Ягъкуп عليه السلام Хәрран шәһәренә юнәлде (  )

**3)** – Ягъкупның عليه السلام Йосыф исемле малае булды (  )

**4)** – Ягъкупның عليه السلام әтисе пәйгамбәр булмады (  )

Буш урыннарга дөрес сүзләр куеп җөмләләрне тулыландыр:

**1)** – Ягъкупның عليه السلام кавеме .................. эшләр эшләү сәбәпле, аларга Аллаһ тәгаләнең ..................... төште.

**2)** – Аллаһ тәгалә аларны ...................... һәм ........................ әйләндерде.

# Йосыф ﷺ

Йосыфның әтисе — Ягъкуп, Ягъкупның әтисе — Исхак, Исхакның әтисе — Ибраһим галәйһиссәлам иде. Алар барсы да пәйгамбәрләр булдылар.

Йосыф галәйһиссәламне, әтисе Ягъкуп галәйһиссәлам барчасыннан да артыграк яратты. Ул бик чибәр вә сөйкемле бала иде.

Көннәрдән беркөнне, Йосыф галәйһиссәлам бик тә гаҗәеп төш күрде. Ул бик зур тәхеттә утыра икән һәм унбер йолдыз вә ай белән кояш аңа сәҗдә кылалар. Йосыф галәйһиссәлам бу төше хакында әтисенә сөйләде. Ягъкуп галәйһиссәлам моңа бик тә шатланды. Абыйлары бу хакта белеп, шәйтан вәсвәсәсенә бирелеп бер-бер начарлык кылмасыннар өчен, Йосыф галәйһиссәламгә бу төше хакында һичкемгә дә сөйләмәскә кушты. Ягъкупның عليه السلام Йосыфка карата булган мәхәббәте тагын да артты, чөнки киләчәктә Йосыфны зур сынаулар белән, бөек эшләр көткәнен сизә иде.

Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Йосыф атасына әйтте: «Әй атам, мин төшемдә күрдем — унбер йолдыз һәм ай белән кояш миңа сәҗдә кылдылар». Атасы әйтте: «Әй улым, син төшеңне абыйларыңа сөйләмә! Әгәр аларга сөйләсәң, хөседләнеп сине һәлак итәр**

**өчен хәйлә кылырлар, чөнки шәйтан адәмләргә ачык дошман, абыйларыңны хәйләгә котыртыр».** (Йосыф: 4 – 5)

Шулай итеп, көннәр узды. Шәйтан ләгънәт төшкере, Йосыфның абыйлары арасында фетнә уты кабызды һәм абыйлары Йосыфны үтерер өчен хәйлә кора башладылар. Бер-берсе белән киңәшләшеп, Йосыфны сахрага алып чыгып коега ташларга карар кылдылар. Бу урыннан узган кәрваннар Йосыфны коедан табып алып, аны башка ераграк җиргә алып китәрләр, дип уйладылар. Әтиләре каршында Йосыфка карата үзләренең мәхәббәтләрен күрсәтеп, аннан Йосыфны үзләре белән алып чыгарга рөхсәт алдылар. Ягъкуп галәйһиссәлам балаларының хыянәт иткәннәрен сизеп (мәгънәсе): **«Йосыфны алып китүегез мине кайгыга төшерә, аннары сез аны караусыз калдырган вакытта бүре ашавыннан куркам», — диде».** (Йосыф: 13)

Көн узгач, алар бер сарыкны чалып, шуның канына Йосыфның күлмәген буядылар. Аның үзен коега ташлап, әтиләре янына елаган кыяфәт белән кайттылар һәм: «Әй атабыз, без Йосыфны караусыз калдырган вакытта аны бүре ашаган, без аңардан гафил булганбыз», — диештеләр.

Ягъкуп галәйһиссәламгә ялган канга буялган күлмәкне алып килгәч, ул бу явыз эш Йосыф абыйларының хәйләсе икәнлеген сизеп алды. Чөнки Йосыфның күлмәге канга буялган булса да, ертылмаган иде (мәгънәсе): **«Йосыфның күлмәген ялган канга буяп аталарына китереп бирделәр. Аталары: «Юк, Йосыфны бүре ашамагандыр, бәлки**

**нәфсегез бер хәйләне сезгә яхшы итеп күрсәткән дә, сез аны кылгансыз, инде миңа күркәм сабырлык кирәк! Сезнең хәйләгезгә каршы Аллаһтан ярдәм сорыймын», — диде».** (Йосыф: 18)

Шулай Йосыф галәйһиссәлам коеда бер үзе күпмедер вакыт уздырганнан соң, кое янына суга дип туктаган кәрванчыларның чиләгенә ябышып чыкты. Абыйлары аны бик арзан бәягә генә кәрванчыларга сатып җибәрделәр. Йосыф кәрван белән Мисырга барып җитте. Анда инде аны кәрванчы, патшаның хәзинәчесенә сатып җибәрде.

Хәзинәче бик тә шатланды, чөнки аның хатыны бала таба алмаган иде. Алар Йосыфны үзләренә бала итеп алдылар һәм ул аларда яшәп үсте. Зурая төшкәч, аның чибәрлеге тагын да ныграк артты. Аның чибәрлеген күреп хәзинәче хатынының йөрәгендә Йосыфка карата мәхәббәт хисләре кабынды һәм Йосыфны үзенә, гөнаһлы эш эшләргә чакырды.

Ләкин, Йосыф галәйһиссәлам бик ихлас вә тәкъва иде. Ул Аллаһ тәгаләнең ачыктан-ачык һәм яшерен булган эшләрнең һәммәсен дә белүче икәнлеген яхшы белә иде. Шуңа да, ул хатын сораган гөнаһлы эшне катгый рәвештә кире какты. Вәзир хатыны иренә: «Йосыф мине рәнҗетмәкче булды, шуңа күрә ул зинданга ябылырга яки каты газапка тартылырга тиеш», — дип яла якты. Бу вакыйга хакындагы хәбәр бөтен шәһәргә таралып, хатын-кызлар бу хакта бик күп сүз сөйләделәр.

Коръәндә моның турында болай диелде (мәгънәсе): **«Йосыф үсеп бәләгатькә ирешкәч, Без аңа**

хикмәт вә белем бирдек, әнә шулай яхшы эшләрне эшләүчеләргә изге җәза бирәчәкбез. Вәзир хатыны, үз өендә Йосыфтан ялынып вә ялварып нәфесе теләгәнне үтәвен таләп итте вә барча ишекләрне бикләде. Йосыф әйтте: «Бу эштән Аллаһка сыгынамын, чынлыкта хуҗам миңа хөрмәт күрсәтте, торачак җиремне күркәм кылды, инде мин аңа ничек хыянәт итим?! Бу эшне кылсам — залимнәрдән булырмын бит, әлбәттә, залимнәр Аллаһ газабыннан котыла алмаслар». Дөреслектә, Йосыфны үзенә якынлык кылдырырга теләде ул хатын вә Йосыф та аны теләгән булыр иде, әгәр Раббысының галәмәтләрен күрмәгән булса, әнә шулай галәмәт күрсәттек, Йосыфтан яман вә фәхеш эшне җибәрмәк өчен, чөнки ул Безнең ихлас колларыбыздан. Икесе дә ишекләргә таба йөгерделәр. Йосыф аннан котылыр өчен йөгерде, ә вәзир хатыны Йосыфны чыгармас өчен артыннан йөгерде. Йосыфның күлмәген арттан тотып үзенә тартты, күлмәк ертылды, ишек алдында алар, ул хатынның ире булган вәзиргә каршы очрадылар. Вәзир хатыны үзенең иренә әйтте: «Синең хатыныңа яман эш кылган кешегә җәзасы нәрсә булыр? Әлбәттә, төрмәгә бикләү яки рәнҗетүче газап булыр». Йосыф әйтте: «Ул үзе теләде минем аңа якынлык кылуымны». Йосыфның сүзен дөресләп, вәзир хатыны кардәшләреннән бер шаһит шәһадәт бирде һәм әйтте: «Әгәр Йосыфның күлмәге ал яктан ертылган булса — хатыныңның сүзе дөрес булыр, Йосыф сүзе ялган булыр. Әгәр Йосыфның

күлмәге арт яктан ертылган булса — хатыныңның сүзе ялган булып, Йосыф сүзе дөрес булыр», — диде. Вәзир Йосыфның күлмәге арттан ертылганын күргәч, әйтте: «Бу эш, сез хатыннарның хәйләсе икән, әлбәттә, сезнең хәйләгез олуг. Әй Йосыф, бу эшне оныт, халыкка фаш итмә. Ә син, (хатынына) гөнаһың өчен гафу сора! Тәхкыйк син хаталанучылардан булгансың». Мисырда бер төрле хатыннар әйттеләр: «Вәзир хатыны үзенең колыннан якынлык кылуын үтенгән вә аңа мәхәббәте чиктән ашкан икән, без аны ачык азгынлыкта күрәбез». Вәзир хатыны аларның аны гәеплә̆п сөйләгәннәрен ишеткәч, ул хатыннарны кунакка чакырып кешеләр җибәрде вә алар өчен яхшы урыннар вә хуш ризыклар әзерләде, кунаклар килеп ашарга утыргач, һәрберсенә үткен пычаклар бирде вә: «Әй Йосыф, ул хатыннар янына чык», — диде. Хатыннар Йосыфны күргәч, бик олуг эш санадылар вә яннарына утыртырга теләделәр һәм Йосыфтан күзләрен ала алмыйча, ризык кисәбез дип, кулларын кискәләп бетерделәр вә: «СөбхәнАллаһ! Бу кеше түгел, бу һичкем түгел, мәгәр хөрмәтле фәрештәдер», — диделәр. Вәзир хатыны әйтте: «Мине шуның хакында гәеп вә шелтә кылган кол, шул колдыр, дөрес, мин аның белән якынлык кылырга өстәдем, ләкин ул теләмәде, сакланды. Әгәр, мин әмер кылганны эшләмәсә, ягъни якынлык кылмаса, әлбәттә, зинданга салдырырмын, хурлыкка төшкән кешеләрдән булыр». Йосыф әйтте: «Әй Раббым! Мине чакырган зинага караганда миңа зиндан ях-

**шырак, әгәр ул хатыннарның хәйләләрен миннән үзең бетермәсең, ул вакытта мин аларга авышырмын вә ярамаган эшне эшләп җәһилләрдән булырмын». Йосыфның догасын Раббысы кабул кылды һәм Йосыфтан ул хатыннарның хәйләсен җибәрде, дөреслектә, Ул сүзләрне ишетүче вә хәлләрне белүче. Йосыфның гәебе юклыгындагы дәлилләр барчаларына да ачыкланды, шулай булса да, азга гына Йосыфны зинданга салырга булдылар».** (Йосыф: 22 – 35)

Шулай итеп, Йосыф галәйһиссәламнең чибәрлеген күреп гаҗәпкә калган хатын-кызлар, үзләре дә сизмәстән ризык урынына кулларын кистеләр. Инде Йосыф галәйһиссәлам гөнаһлы эшкә караганда, миңа зиндан хәерлерәк дип сайлады һәм аны зинданга яптылар.

Уйлап карагыз, балалар, әгәр дә бер кешегә — бертөрле гөнаһны яки төрмәне сайларга кушсалар, ул бәлки: «Мин төрмәдә ничәмә еллар утырганчы, гөнаһ эшлим дә, аннары тәүбә кылып Аллаһтан ярлыкавын сорыйм, чөнки Аллаһ Гафу итүче», — дип уйлар.

Аллаһ тәгалә теләгән бәндәсен гафу итә, теләгәнен газап кыла, шуның өчен дә, безгә гөнаһлы эшләрдән ерак булырга кирәк. «Гөнаһ эш эшлә, югыйсә сине төрмәгә утыртабыз», — дип куркытсалар да, без гөнаһлардан сакланырга тиеш. Чөнки төрмә мөселман өчен дөнья авырлыгы гына, ә Аллаһ тәгалә яраткан бәндәсен авырлыклар белән сыный.

Инде балалар, Йосыф галәйһиссәламнең шушыннан соң булган вакыйгаларын карагыз.




Зинданда Йосыф галәйһиссәлам кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырды. Аллаһ ахирәт көнендә мөэминнәр белән кәферләрне аерачак һәм иман китергәннәрне Җәннәткә, ә кәферләрне Җәһәннәмгә кертәчәк, дип вәгазьләде. Ул, зинданда ябылган кешеләр арасында мәрхәмәтлелеге, йомшак холкы белән мәшһүр булды.

Зинданга аның белән бергә ике егет тә керде. Көннәрнең берендә, алар төш күреп, Йосыф галәйһиссәлам янына төшләрен юратырга килделәр.

Йосыф галәйһиссәламгә Аллаһ тәгалә төш юрау сәләтен биргән иде. Ул аларны башта вәгазьләде, аннары төшләрен юрап бирде.

Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Вә аның белән бергә ике егет тә зинданга керде. Берсе — хәмер ясаучы, икенчесе — икмәкче иде, алар төш күрделәр. Аларның берсе әйтте: «Мин төшемдә хәмер сыкканымны күрдем». Ә икенчесе әйтте: «Мин төшемдә икмәк күтәреп йөргәнемне күрдем, ул күтәргән икмәгемнән кошлар ашый имеш. Әй Йосыф! Ул төшнең тәгъбире нәрсә, безгә сөйләп бир? Тәхкыйк, без сине яхшы кеше дип беләбез». Йосыф әйтте: «Сезне ашата торган ризыкны, сезгә ашарга алып килмәс борын ук, мин ул төшләрегезне юрап бирермен, бу төшләрегезгә тәгъбир ясавым — Раббымның өйрәтүе беләндер, дөреслектә, мин Аллаһка һәм дә ахирәткә ышанмаган кешеләрне ташладым, алардан киселдем. Вә мин иярдем ата-бабаларым: Ибраһим, Исхак һәм Ягъкуплар диненә, Аллаһка берәр мәхлукны тиңдәш итү безнең өчен һич тә дөрес вә лаек түгел. Ошбу хак диндә булуыбыз, безгә вә башка кешеләргә Аллаһның рәхмәте, ләкин күп кешеләр моны зур нигъмәт дип белмиләр һәм Аллаһка шөкер итмиләр». Йосыф әлеге төш күрүче ике егетне башта вәгазьләргә теләде һәм аларга әйтте: «Әй зиндандагы ике иптәшем! Ясалма күп иләһләргә гыйбадәт кылу хәерлеме? Яки һич тиңдәше булмаган бөтен мәхлукның хуҗасы вә кодрәт иясе булган — бер генә Аллаһка гыйбадәт кылу хәерлеме? Әлбәттә, бер генә**

**Аллаһка гыйбадәт итү хәерле. Сез бер Аллаһтан тыш гыйбадәт кылган нәрсәләрегез, мәгәр үзегез вә аталарыгыз «иләһ» дип исем биргән һичнәрсәгә ярамый вә файда бирми торган потлар гына, ул сыннарга гыйбадәт кылуның дөреслеге өчен Аллаһ һич дәлил иңдергәне юк, бу хакта хөкем итмәк фәкать Аллаһка гына хас, башка затның хөкеме — хөкем түгел, Ул — Аллаһ Үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска әмер кылды, бу Ислам дине — хак дин, ләкин күп кешеләр белмиләр. Әй зиндандагы ике иптәшем! Инде күргән төшегезгә тәгъбир кылам: Әмма берегез зинданнан чыгып әүвәлге урынында хуҗасына хәмер ясаучы булыр, әмма икенчегезне асарлар вә башын кошлар ашар. Сез сораган эшнең булачагы билгеләнгән».** (Йосыф: 36 – 41)

Йосыф галәйһиссәлам егетләрнең котыла дип юраганына, зинданнан чыккач, аны хаксыз зинданга ябылганын искә төшереп, патшадан чыгаруын сорарга кушты. Әмма егет зинданнан чыккач Йосыф галәйһиссәламнең үтенечен онытты һәм Йосыф галәйһиссәлам зинданда тагын да бик күп еллар калды.

Көннәрнең берсендә патша бик серле төш күрде. Үзенең вәзирләрен вә хәкимнәрен чакырып төшен сөйләде һәм алардан ошбу төшне аңа юрап бирүләрен таләп итте. Вәзирләре аңа: «Без төш юрый белмибез, моңа безнең гыйлемебез юк», — дип җавап бирделәр.

Шул вакытта, төрмәдән чыккан егет Йосыф галәйһиссәламнең төш юрый белгәнен исенә төшерде

һәм патшага хәбәр итте. Патша егетне Йосыф галәйһиссәлам янына җибәрде. Йосыф галәйһиссәлам патшаның төшен юрап бирде.

Коръәндә бу хакта болай диелде (мәгънәсе): **«Егетләрнең берсенә котыла дип зан кылганына, ягъни хәмерчегә Йосыф әйтте: «Зинданнан чыккач, патшага минем хаксыз зинданда ятканымны сөйлә, мине чыгарсын». Егеткә Йосыф турында патшасына әйтергә шәйтан оныттырды, янә Йосыф ничә еллар зинданда калды. Бервакыт патша үзенең дусларына әйтте: «Мин төшемдә җиде симез сыер күрдем, аларны җиде арык сыерлар ашый, имеш, дәхи, җиде яшел башаклар вә җиде кипкән башаклар күрдем. Әй җәмәгать, әгәр төш юрый белсәгез, минем төшемне юрагыз!». Патшаның дуслары әйттеләр: «Бу төш саташу гына, без андый саташу төшләрнең тәгъбирен белмибез». Зинданнан чыккан хәмерче, аңардан патшага әйтергә үтенеп кылган Йосыфның сүзен күп еллардан соң исенә төшереп, патшага әйтте: «Мине зинданга җибәрегез, аннан кайтып бу төшнең тәгъбирен сезгә сөйләрмен», җибәрделәр, Йосыф янына барды. «Әй дөрес сөйләүче Йосыф! Син безгә җиде симез сыер хакында җавап бир? Шаять, мин Мисыр халкына кайтып җавап бирермен, ул симез сыерларны җиде арык сыерлар ашый, дәхи, җиде яшел башак вә җиде кипкән башак хакында җавабыңны сөйләрмен, шаять, алар да кадереңне белеп зинданнан чыгарырлар. Йосыф әйтте: «Җиде ел тоташтан иген чәчегез, җиде елда уңыш яхшы булыр, алган уңышны**

**сукмыйча башагы вә саламы белән кибәндә саклярсыз, мәгәр үзегез ашар хәтле генә сугып алырсыз. Моның соңында җиде ел ачлык еллары килер, уңышлы җиде елда җыйган игеннәрегез җиде ачлык елларында ашалып бетәр, мәгәр орлык өчен саклаган аз гына игеннәрегез калыр. Соңра ачлык еллардан соң бер ел килер, ул елда яңгырлар явар, кешеләргә игеннәр вә җимешләр үсәр, һәр җәһәттән иркен булыр, җимешләр сыгып шәрәбләр ясарлар».** (Йосыф: 42 – 49)

Патша Йосыф галәйһиссәламнең төшен юраганын белгәч, аны үзенә китерергә кушты. Әмма Йосыф галәйһиссәлам моны кире какты һәм патшага үзенең гаепсез зинданга утыртылганын ачыкларга сорады. Патша, Йосыфны күрүдән кулларын кискән хатыннарны җыеп: «Йосыф гаеплеме?», — дип сорагач, алар барысы да Йосыфны гаепсез диделәр. Шушында хәзинәченең хатыны үзенең гаепле икәнлеген белгертеп һәм Йосыфның гаепсезгә рәнҗетелгәнлеген ачып салды.

Бу хәлдән соң патша Йосыфны зинданнан чыгарып, үзенең хәзинә эшен башкаручы вәзир итеп куйды.

Йосыф галәйһиссәлам юраганча җиде ел муллыкта яшәү еллары узып, бар җиргә корылык килде һәм ачлык еллары башланды. Йосыф галәйһиссәлам үзенең гаделлеге вә зирәклеге белән кешеләрнең хаҗәтенә карап, узган муллык елларында туплагнан ашлыкны сатып бирә иде.

Мисырда ашлык барлыгын ишеткәч, Йосыфның абыйлары шунда юнәлде. Барып җиткәч алар ашлык

сорар өчен Йосыф галәйһиссәлам янына керделәр. Ул аларны таныды, әмма абыйлары Йосыфны танымады. Йосыфның абыйлары: «Без Ибраһим галәйһиссәлам нәселеннән Ягъкуп балаларыбыз, барчабыз унике идек, Йосыф исемле кечкенә кардәшебезне югалттык, Бинямин исемлесе атабыз янында калды, әти-әниебез белән ундүрт булабыз, безгә җитәрлек ризык бирерсеңме?», — диделәр. Йосыф галәйһиссәлам аларга: «Мин сезгә барыгызга да җитәрлек, тиешле ризыкны бирермен, ләкин сез Бинямин исемле кардәшегезне алып килегез, әгәр аны алып килмәсәгез, миндә сезнең өчен ашлык булмас», — дип җавап бирде.

Йосыфның абыйлары кайткач әтиләренә барча нәрсәне сөйләп бирделәр. Әтиләре Йосыф белән булган вакыйганы исенә төшереп: «Бу сезнең бер хәйләгезгенәдер», — диде. Алардан Аллаһ тәгалә исеме белән ант иттереп, Биняминны кире алып кайтырга вәгъдә алды. Шулай ук Мисырга җитсәләр барысыда бер капкадан кермичә, аларга аерым-аерым капкалардан керергә кушты.

Йосыфның туганнары Мисырга барып җитеп, әтиләре әйткәнчә, төрлесе төрле капкадан керделәр вә Йосыф галәйһиссәлам янына килделәр. Йосыф галәйһиссәлам башка туганнарына белдермичә генә Бинямингә үзен танытып, аның абыйсы икәнен әйтте. Энесе Бинямин моңа бик шатланды, ләкин Йосыф галәйһиссәлам аңа башкаларга белдертмәскә кушты.

Йосыф галәйһиссәлам абыйларына тиешле ризыкны биргәч, алар китер алдыннан, ул үзенең

эшчеләренә, Биняминнның йөгенә үлчәү савытын яшереп куярга кушты. Бераздан: «Үлчәү савыты югалды», — дип, игълан иттеләр. Йосыф галәйһиссәлам йөкләрнең барысын да тикшереп чыгарга кушты. Тикшерүчеләр үлчәү савытын Биняминнның йөгеннән табып алдылар вә Йосыф галәйһиссәламгә җиткерделәр. Йосыф галәйһиссәлам: «Билгеле булганча, әйбер урлаучы бездә хезмәтче булып кала, бу аның тиешле җәзасы», — диде. Бу хәлгә абыйлары елап җибәрделәр һәм Йосыфка: «Әй газиз, аның өйдә карт атасы бар, аның урынына безнең беребезне алып кал, аны җибәр», — диделәр. Йосыф кире какты. Абыйлары Биняминны кире үзләре белән алып кайтырга өметләрен өзгәч, үзләре генә кайтуга табан юнәлде. Аталары янына кайткач булган барча хәлләрне сөйләп бирделәр. Ягъкуп галәйһиссәлам бу сүзләргә бик кайгырды һәм: «Бәлки нәфсегез бер яман эшне яхшы итеп күрсәткәндер, ә сез ул эшне Бинямингa яккансыз, инде миңа күркәм сабырлык тиеш. Аларның барчасын да Аллаһ миңа кире китерер дип өмет итәмен», — диде.

Ягъкуп галәйһиссәлам улларына Мисырга барып, ике кардәшләре турында сорашырга вә Аллаһ тәгаләнең рәхмәтеннән өметләрен өзмәскә кушты.

Кардәшләре Мисырга барып, Йосыфка кереп: «Әй газиз! Безгә вә өй җәмагәтебезгә бик каты ачлык иреште, ярдәм итче вә безне гафу итеп кардәшебезне дә биреп җибәр, атабыз аның өчен бик хәсрәтләнеп елый-елый күзләре сукрайды», — диделәр. Йосыф галәйһиссәлам аларга: «Сез беләсезме, хәтерегездәме? Йосыфка вә аның кардәшенә

җәһиллек белән ниләр кылдыгыз?», — диде. Алар: «Син әллә Йосыфмы?», — дип сорадылар. Йосыф: «Мин Йосыфмын, ошбу минем кардәшем Бинямин», — диде.

Бу күренеш хакында Аллаһ Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Алар Мисырга барып, Йосыф янына кереп әйттеләр: «Әй газиз! Безгә вә өй җәмәгатьләребезгә бик каты ачлык иреште, менә сезгә аз гына әйберләр китердек, шуңа карата безгә ашлык үлчәп бир, мөмкин булса садака итеп тә бир һәм Биняминне дә биреп җибәр, атабыз аның өчен бик хәсрәтләнә! Әлбәттә, Аллаһ садака бирүчеләргә изге җәзалар бирер. Моннан соң Йосыфның күңеле йомшарды вә үзен танытырга һәм серләрне ачарга теләде. Әйтте: «Беләсезме, хәтерегездәме? Йосыфка вә аның кардәше Бинямингә җәһиллек белән ниләр кылдыгыз?». Алар: «Син әллә Йосыфмы?», — дип сорадылар. Йосыф әйтте: «Әлбәттә, мин Йосыфмын, ошбу минем кардәшем Бинямин, дөреслектә, Аллаһ безгә нигъмәт вә дәрәҗәләр бирде. Берәү Аллаһка тәкъвалык кылып башына килгән бәлаказаларга сабыр итсә, әлбәттә, Аллаһ яхшы эшләрнең әҗерен юкка чыгармый». Куркып калтырап әйттеләр: «Әй Йосыф, валлаһи сине Аллаһ безгә ихтыярлы вә баш кылды, шиксез, без хаталанучылардан булдык». Йосыф әйтте: «Бүген сезне гәепләп битәрләү юк, курыкмагыз, мин сезне хөкем итмим. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһ ярлыкасын, Ул бик шәфкатьле вә рәхимле! Минем ошбу күлмәгемне алып кайтып атамның**

**йөзенә ябыгыз, шуннан соң атамның күзләре ачылыр, күрә башлар, вә атамны һәм барча җәмәгатьләрегезне җыеп Мисырга минем хозурыма килегез!».** (Йосыф: 88 – 93)

Йосыфның кардәшләре Мисырдан кайтырга чыгып киткәч, аталары Ягъкуп: «Мин Йосыфның исен сизәмен», — диде. Янындагылар: «Син элеккечә Йосыф белән саташасың», — диделәр. Инде уллары кайтып җитеп, аталарының йөзенә Йосыфның күлмәген куйгач, Аллаһ тәгаләнең рәхмәте белән Ягъкуп галәйһиссәламнең күзләре яңадан ачылды. Ул күрә башлады. Шуннан соң барчасы җыелып Мисырга күченделәр. Йосыф галәйһиссәлам ата-анасын хөрмәтләп тәхеткә утыртты, аннары Йосыфны ихтирам итеп барчасы сәҗдә кылдылар.

Йосыф галәйһиссәлам ата-анасы вә кардәшләре белән бик тыныч тормыш итте. Ягъкуп галәйһиссәлам кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыруын дәвам итте. Вафат булыр алдыннан балаларын җыеп: «Нәрсәгә гыйбадәт кылырсыз», — дип сорады.

Бу хакта Коръәндә менә ничек диелде (мәгънәсе): **«Ягъкуп галәйһиссәлам үләр алдыннан сез аның янында идегезме? Шул вакытта әйткән сүзләрен дә ишеттегезме әллә? Үлем түшәгендә яткан чакта улларына мөрәҗәгать итеп: «Мин үлгәннән соң нәрсәгә гыйбадәт кылырсыз, үзегезгә нәрсәне иләһ итеп алырсыз?» – диде. Уллары аңа: «Син үлгәч синең вә аталарың – Ибраһим, Исмәгыйль, Исхакларның иләһенә — бердәнбер Аллаһ тә-**

**галәгә гыйбадәт кылырбыз һәм без Аңа буйсынучылардан булырбыз», — диделәр».** (Бәкара: 133)

Ягъкуп галәйһиссәлам вафат булгач, уллары бик кайгырды. Аталарыннан соң, Йосыф галәйһиссәлам дәгъват кылуны дәвам итте. Кешеләрне бер Аллаһка иманга, гыйбадәткә чакырды. Ошбу тәүһидкә чакыру эшен тиешлечә башкарып, Аллаһ әмере белән бу дөньядан китте.

Инде кадерле балалар, Йосыф галәйһиссәламнең кыйссасын шуның белән тәмамлыйбыз. Киләсе пәйгамбәрнең тарихында очрашуга кадәр, вәссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Үз-үзеңне барча нәрсәдән артык ярату, кешенең табигый гадәте, ул гадәттән арынырга кирәк.

**2)** – Шәйтанга иярү, бу дөньяда да, ахирәттә дә хәсрәткә илтә.

**3)** – Йосыфның кардәшләре аны үтерергә уйладылар.

**4)** – Ягъкуп галәйһиссәлам, килгән кайгы-хәсрәткә зур сабырлык күрсәтте.

**5)** – Йосыф галәйһиссәламне Мисыр вәзире сатып алды.

**6)** – Вәзирнең хатыны Йосыф галәйһиссәламне үзенә якынлык кылырга чакыргач, Йосыф галәйһиссәлам гөнаһлы эш эшләргә Аллаһтан куркам дип, бу кабахәт гамәлдән баш тартты һәм анны инкяр итте.

**7)** – Йосыф галәйһиссәлам тәкъвалардан иде.

**8)** – Йосыф галәйһиссәлам иманының куәте белән хатын-кыз мәкереннән котылып кала алды.

**9)** – Аллаһ тәгалә Йосыф галәйһиссәламгә төшләр юрау нигъмәтен бирде.

**10)** – Йосыф галәйһиссәламнең гаепсезлеге барча кешеләр алдында ачылды.

**11)** – Йосыф галәйһиссәлам җирдән чыккан уңышларга хәзинәче булды.

**12)** – Йосыф галәйһиссәлам кардәшләрен таныгач, аларга ихсанлык күрсәтте.

**13)** – Йосыф галәйһиссәлам кардәшләренә үзенең күлмәген биреп, аталарының битенә куйгач, Ягъкуп галәйһиссәламнең күзләре ачылды.

**14)** – Ягъкуп галәйһиссәламнең гаиләсе бик озак вакыт аерылып торганнан соң, Аллаһ тәгалә кодрәте белән яңадан бергә җыелды.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Йосыф галәйһиссәлам нинди төш күрде?

**2)** – Бертуган булган кардәшләре Йосыф галәйһиссәлам белән нәрсә эшләделәр?

**3)** – Йосыф галәйһиссәламне коедан кемнәр табып чыгарды?

**4)** – Аны Мисырда кем сатып алды?

**5)** – Хәзинәченең хатыны ни өчен Йосыфны теләде?

**6)** – Йосыф галәйһиссәламне дөрес гаепләделәрме?

**7)** – Йосыф галәйһиссәлам кардәшләре белән ничек очрашты?

**8)** – Ягъкуп галәйһиссәлам улларына, кардәшләре Йосыфны һәм Биняминны югалткач нәрсә дип җавап бирде?

**9)** – Ягъкуп галәйһиссәламнең күзе сукырайганнан соң, ничек күрә башлады?

Дөрес җөмлә артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата булган җөмлә артына ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Йосыфның әтисе дә, бабасы да, бабасының әтисе дә — пәйгамбәрләр иде (  )

**2)** – Йосыфның туган кардәшләре аны үтерергә уйладылар (  )

**3)** – Йосыфны Йәмән вәзире сатып алды (  )

**4)** – Йосыф галәйһиссәлам Биняминның йөгенә үлчәү савытын куярга кушмады (  )

**5)** – Ягъкуп галәйһиссәламнең сукыр күзләре айга карагач күрә башлады (  )

Дөрес сүзләр куеп җөмләләрне тулыландыр:

**1)** – Аллаһ тәгалә ( залимнәргә – сабырларга – байларга) әҗер-савапны хисапсыз бирә.

**2)** – Хатын-кызлар Йосыф галәйһиссәламне күргәч (һушларын югалтылар – кулларын кистеләр – аны куып чыгардылар).

**3)** – Йосыф галәйһиссәламнең гаепсезлеге беленде, чөнки (аны патша ярата иде – аның байлыгы күп иде – ул гаепсез рәнҗетелгән иде).


# Шөгайб عليه السلام

Шөгайб галәйһиссәламне Аллаһ тәгалә Мәдйән әһелләренә пәйгамбәр итеп җибәрде. Мәдйән әһелләре гарәпләрдән булып, Шәм тарафындагы Мәган җирләрендә яшиләр иделәр. Хәзерге урыннар белән чагыштырганда, аларның урыны төньяк Сәгуд Гарәбстанындагы Тәбүк шәһәренең төньяк-көнбатышына вә Иорданиянең көньягына туры килә.

Шөгайб галәйһиссәлам нәселе белән Ибраһим галәйһиссәламгә тоташа. Ул бик тә матур сөйләүчән булып, аны пәйгамбәрләр хатыйбы дип тә исемлиләр.

Шөгайб галәйһиссәлам пәйгамбәр итеп җибәрелгән кавем, золым вә бозыклык белән мәшһүр булдылар. Үз араларында да золымлык таратып, юлбасарлык кылып кешеләрнең малларын көч белән алалар иде. Әгәр дә сәүдә итә торган булсалар, үлчәүләрне бозып, алучыга көчләп тиешлесеннән азын бирәләр, ә үзләре сатып ала торган булсалар, тиешлесеннән артыгын көчләп, куркытып алалар иде. Белгән кешеләрне дә, белмәгәннәрен дә җәберләп, гаделсез рәвештә башкаларның хакларын ашау, алар өчен гадәти гамәлгә әйләнеп киткән иде. Болардан да түбәнрәк гамәлләре — алар үзләренең акыллары белән бер дә уйлап тормыйча, шәйтанга алданып “әл-әйкә” исемле зур вә куе бер агачка табыналар


иде. Шәйтан ләгънәт төшкере, аларга бу агачны шул тиклем “матурлаган” иде, хәтта аларны шул агач ризыкландыра вә дөньяда нәрсә сорасалар да — ул бирә дип, Аллаһ тәгаләдән ераклашып, шул мәхлук булган агачны гына зурлыйлар вә хөрмәтлиләр иде.





«Әйкә» дип кечкенә агачлар үскән яшеллекле урынга әйтеләдер. Берәүләр — Шөгайб ﷺ кавеме яшәгән урын Мәдйән янында булган дип әйтсә, икенчеләр — ул урын Тәбүк шәһәре булган, дигән фикерне әйтәләр. Аллаһу әгъләм.



Шөгайб галәйһиссәлам
Микил
Яшҗәр
Мәдйән
Ибраһим галәйһиссәлам
Шөгайб галәйһиссәламнең нәселе







Шөгайб пәйгамбәр кавеменнән, бүгенге көндә сакланып калган кайбер тарихи әсәрләр.



Шөгайб галәйһиссәлам беренче эш итеп үз кавемен иманга чакыра башлады. Барча нәрсәне юктан бар кылган Аллаһ тәгаләне исләренә төшерде. Алар табына торган агач, мәхлукатларның берсе булып, бернинди файда да, зыян да итә алмаганлыгын вә ул агачта кеше тормышына бәйле бер төрле сер дә юк икәнлеген аңлатты. Тәүбә итеп бер Аллаһка кайтырга һәм кешеләрне рәнҗетмичә, Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә чакырды.

Шөгайб галәйһиссәламгә бик аз кеше иман китерде. Күбесе тәкәбберлектә булып, көферлектә калдылар. Алар аңа: «Әгәр дә син кешеләрне ата-бабалары табынган әйберләргә табынудан тыюыңны туктатмасаң, без сине вә сиңа иман китереп ияргән барча кешеләрне үзебезнең җиребездән куып чыгарачакбыз һәм каты газап кылачакбыз», — дип яныйлар иде. Шөгайб галәйһиссәлам кавеменең рәнҗетүенә бик зур сабырлык күрсәтте. Йомшаклык вә хикмәт белән вәгазьләп, аларны иманга чакыруын дәвам итте. Әмма алар аңа һәрдаим явызлык белән җавап бирделәр.

Коръәндә бу хакта болай диелде (мәгънәсе): **«Әй Шөгайб, син сөйләгән сүзләрнең күбрәген аңламыйбыз һәм арабызда сине бик зәгыйфь күрәбез, әгәр синең нәсел туганнарың (кабиләң) булмаса иде, без сине ташлар белән бәреп үтерер идек вә син безгә алай бик кадерле — газиз кеше түгелсең», — диделәр».** (Һуд: 91)

Шөгайб галәйһиссәлам бу сүзләрне җиңеллек белән кабул итте, чөнки аларны адаштыручы — шәйтан, икәнлеген ул яхшы белә иде. Шуңа да сабырлык

белән дәгъватен дәвам итә бирде. Кабаттан-кабат аларны изгелекккә өндәп, гөнаһлы эшләрдән тыйды һәм: «Әй кавемем, минем нәсел туганнарымнан куркасыз, ә сезне һәм сез курыккан бәндәләрне юктан бар иткән, Аллаһтан курыкмыйсызмы?», — диде. Ләкин кавеме тәкәбберләнеп, аның сүзләрен инкяр итүләрен дәвам итә бирделәр.

Ниһаять, аларның беркайчан да тыңламаячакларына ышанып, Шөгайб галәйһиссәлам дога кылды (мәгънәсе): **«Әй Раббыбыз! Безнең белән кавемебез арасында булган хәлне хаклык белән хөкем ит! Син, әлбәттә, эшне ачыклаучыларның хәерлесе».** (Әгъраф: 89)

Аллаһ тәгалә Шөгайб галәйһиссәламнең догасын кабул итте. Пәйгамбәрне инкяр итеп, аннан көлгән кәферләргә вәгъдә ителгән газап килде. Ул газап, бик каты вә ачы газап булды. Куркыныч каты җир тетрәүдән кәферләрнең җаннары чыкты һәм алар йортларында үләксә кебек катып калдылар. Күктән таш яуды. Ул шәһәр тулысы белән җимерелеп, хәрәкәтсез мәет кебек булып калды. Аллаһ тәгалә Шөгайб галәйһиссәламне вә аның белән иман китергән мөэминнәрне Үзенең чиксез кодрәте белән саклап калды.

Аллаһ Сөбхәнәһү вә тәгалә Коръәндә Шөгайб галәйһиссәлам кыйссасы хакында болай диде (мәгънәсе): **«Вә Мәдйан шәһәренә кардәшләре Шөгайбне пәйгамбәр итеп җибәрдек. Кавеменә әйтте: «Әй кавемем, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз! Аллаһтан башка сезнең иләһегез юк. Дөреслектә, сезгә Аллаһтан ачык могҗизалар**

килде, үлчәүләрегездә тигезлек кылыгыз, кешеләргә нәрсә сатканда да ким үлчәмәгез вә Аллаһ расүлләр җибәреп, җир өстендә төзеклек кылганы соңында, сез анда бозыклыклар кылмагыз! Бу хөкемнәр сезнең өчен хәерле, әгәр хак сүзгә ышанучылардан булсагыз. Мөэминнәрне куркытып, Аллаһ юлыннан туктатыр өчен вә Аллаһка ышанган кешеләрне Аның юлыннан барырга ирек бирмәс өчен һәм Ислам динен үзгәртеп бозар өчен, һәрбер юл өстендә утырмагыз һәм Аллаһның сезгә биргән нигъмәтен, ярдәмен хәтерләгез! Бит әүвәлдә аз идегез, Аллаһ сезне күбәйтте вә игътибар илә карагыз! Аллаһка вә расүлгә карышып бозыклык кылучыларның ахыры ничек булды? Шөгайб әйтте: «Сезләрдән мин китергән Аллаһ хөкемнәренә ышанучы таифә вә ышанмаучы таифә булса, сез — ышанучылар, сабыр итеп түзегез, хәтта Аллаһ арабызда хөкем иткәнгәчә! Ул хәкимнәрнең иң хәерлесе». Шөгайб кавеменнән ышанмаучы тәкәбберләре әйтте: «Әй Шөгайб, үзеңне вә сиңа ияреп иман китергәннәрне шәһәребездән чыгарырбыз, яки безнең динебезгә кайтарылырсыз», — дип. Шөгайб әйтте: «Без сезнең динегезне яратмасак та батыл динегезгә безне көчләп кайтарырсызмы? Юк, кайтара алмассыз», — дип. Шөгайб әйтте: «Аллаһ, Үзенең рәхмәте белән безне сезнең батыл динегездән коткарганы соңында янә шул батыл дингә кайтыйкмы? Әгәр сезнең батыл динегезгә кире кайтсак, Аллаһка әллә ниләрне ифтира кылган булырбыз, безгә сезнең батыл динегезгә кайтмак

**һич тә дөрес булмас, мәгәр тәрбиячебез — Аллаһ теләсә генә, ләкин батыл дингә кайтуны Аллаһ, әлбәттә, теләми. Аллаһ тәгалә һәрнәрсәне белеме белән чорнап алды, без Аллаһка тәвәккәл кылдык, сездән курыкмыйбыз. Әй Раббыбыз! Безнең белән кавемебез арасында булган хәлне хаклык белән хөкем ит! Син, әлбәттә, эшне ачыклаучыларның хәерлесе». Шөгайб кавеменнән олуг кәферләре әйттеләр: «Әгәр Шөгайбка иярсәгез, шул сәгатьтә үк һәлак булырсыз». Ягъни, Ислам диненә керүдән үз кавемнәрен үлем җәзасы белән куркытып тыйдылар. Ул кәферләрнең астыннан җир тетрәде вә өйләреннән дә чыга алмыйча бөгелеп төшеп һәлак булдылар. Шөгайбны ялганчы диюче кәферләр шәһәрләрендә гүя тормаган да кебек булдылар, Шөгайбны ялганчы диюче кәферләр һәлак булучылар. Шөгайб алардан борылды һәм әйтте: «Әй кавемем! Мин сезгә Аллаһ хөкемнәрен ирештердем һәм сезне үгет-нәсыйхәт кылдым, инде мин Аллаһка ышанмаган вә миңа дошман булган кәферләрнең һәлак булулары өчен ничек кайгырыйм?».** (Әгъраф: 85 – 93)

Һәм «Һуд» сүрәсендә Лут галәйһиссәлам кыйссасыннан соң, Аллаһы тәгалә болай дип әйтте (мәгънәсе): **«Вә Мәдйән халкына пәйгамбәр итеп кардәшләре Шөгайбны җибәрдек. Ул әйтте: «Әй кавемем, Аллаһка гыйбадәт кылыгыз! Ул Аллаһтан башка сезнең иләһегез юк. Дәхи, бер нәрсәне үлчәп кешегә биргәндә киметеп үлчәмәгез! Дөреслектә, мин сезне бик байлыкта күрәмен һәм сезнең өчен куркамын Кыямәт көненең чолгап**

алучы газабыннан. Әй кавемем, үлчәүләрегезне гаделлек белән үлчәгез! Вә үлчәүләрдә кешеләр әйберләрен киметмәгез вә җир өстендә бозыклык кылып йөрмәгез! Әгәр хак мөэмин булсагыз, кәсепләрегездә һәм сәүдәләрегездә Аллаһ калдырган файда аз булса да, сезнең өчен хәерледер, әмма үлчәүне киметеп алган файда, хәерсез — хәрамдыр. Мин сезгә сакчы түгелмен һәр эшегезне күзәтеп бетерә алмам, үз эшегезне үзегез карагыз! Кәферләр әйттеләр: «Әй Шөгайб! Атларыбыз гыйбадәт кылган сынымнарыбызны ташларга һәм үзебезнең малларыбызда үзебез теләгәнчә эш кылуны ташларга синең намазың кушамы? Көлеп әйттеләр: «Әлбәттә, син шәфкатьле вә туры юлга күнүче бер кешесең». Әйтте: «Әй кавемем, уйлап карагыз, әгәр мин Раббымнан көчле дәлилләр белән килгән булсам һәм мине үзеннән яхшы ризык белән ризыкландырса вә мин сезне нәрсәләрдән тыйсам, ул нәрсәләрне үзем эшләргә теләмим, мин сезгә һичнәрсә теләмим, мәгәр көчем җиткән хәтле эшегезне хак юлга салырга телим, сезне ислах кылуда (төзәтүдә) миңа уңышка ирешмәк юк, инсаф белән Аңа кайтамын. Әй кавемем, миңа карышмагыз, миңа карышуыгыз Нух кавеменә, яки Һуд кавеменә, яки Салих кавеменә ирешкән газап кебек газап ирешүгә сәбәп булмасын! Бит Лут кавеменең һәлакәте сездән ерак түгел, сакланыгыз! Раббыгыздан ярлыкау өстәгез, соңра тәүбә итеп Аңа кайтыгыз! Дөреслектә, минем Раббым тәүбә итеп төзәлүчеләргә шәфкатьле вә аларны сөюче». Кавеме әйтте: «Әй Шөгайб,

**син сөйләгән сүзләрнең күбрәген аңламыйбыз һәм арабызда сине бик зәгыйфь күрәбез, әгәр синең нәсел туганнарың (кабиләң) булмаса иде, без сине ташлар белән бәреп үтерер идек, вә син безгә алай бик кадерле — газиз, көчең җитә торган кеше түгелсең». Шөгайб әйтте: «Әй кавемем, минем кабиләм сезгә Аллаһка караганда якынракмы әллә? Аның әмерләрен артыгызга куясыз. Дөреслектә, минем Раббым сез кылган эшләрне белүче вә чолгап алучы. Әй кавемем, сез урыныгызда үзегезнең бозык эшләрегезне кылыгыз! Әлбәттә, мин үз гамәлемне кылырмын вә кем ялганчы һәм кемгә рисвай кылучы газап килгәнен тиздән белерсез. Көтегез Аллаһ газабын! Мин дә сезнең белән бер рәттән сезгә килә торган газапны көтүчемен». Газап килергә әмеребез булгач, Шөгайбны вә аңа ияргән мөэминнәрне Үзебезнең рәхмәтебез белән газаптан коткардык. Әмма залим кәферләргә котычкыч куркыныч тавыш иреште һәм алар өйләре эчендә ябышып каттылар. Әйтерсең дә алар өйләрендә һич тормадылар. Сәмүд кавеменә Аллаһның рәхмәтеннән ераклык булган кебек, Мәдйән халкына да Аллаһның рәхмәтеннән ераклык булучы».** (Һуд: 84 – 95)

«Хиҗер» сүрәсендә (мәгънәсе): **«Дәхи Шөгайб галәйһиссәлам җибәрелгән Әйкә шәһәре халкы да залим булдылар. Вә аларга да газап иңдереп, үчебезне алдык, боларның да һәлак булган шәһәре юл өстендә күренеп тора».** (Хиҗер: 78 – 79)

«Шүгарә» сүрәсендә (мәгънәсе): **«Әйкә кавеме пәйгамбәрләрне ялганга тоттылар. Шөгайб**

пәйгамбәр аларга әйтте: «Әллә Аллаһтан курыкмыйсызмы, Аңардан башкага гыйбадәт кыласыз. Мин сезгә хак пәйгамбәрмен, миннән зарар вә хыянәт күрүдән иминсез. Аллаһтан куркыгыз, Аңа каршы барудан сакланыгыз вә минем әмерләремә итагать итегез! Ислам шәригатен өйрәткәнем өчен сездән хак сорамыйм, минем гамәлемнең әҗере — галәмнәрне тәрбияләүче Аллаһ хозурында. Алыш-биреш эшләрендә үлчәүләрегезне үлчәгәндә яхшылап үлчәп бетерегез, кеше зарарына ким үлчәүчеләрдән булмагыз. Үлчәгәндә тигез, дөрес үлчәүләр белән үлчәгез. Үлчәгәндә хыянәт итеп кеше хакына кермәгез вә фәсәд, золым эшләрен кылмагыз, явызлыкны җир өстенә таратмагыз. Сезне вә сездән әүвәлгеләрне халык кылучы Аллаһтан куркыгыз!». Мөшрикләр әйттеләр: «Син фәкать ничә кат сихерләнеп, саташкан кешеләрдәнсең. Син һичкем түгел, безнең кебек бер кешесең, без сине ялганчылардансың, — дип уйлыйбыз. Әгәр син хак пәйгамбәр булсаң, безгә күктән газап иңдер!». Шөгайб әйтте: «Аллаһ, сезнең Аңа каршы эшләгән эшләрегезне белә, тиешле җәзасын бирер». Һәм алар пәйгамбәрне ялганга тоттылар, Аллаһ аларга бик каты эсселек җибәрде, соңра алар өстенә бер болыт җибәрде, алар эсселектән качып болыт астына җыелдылар, аннары шул болыттан ут явып һәммәсен һәлак итте. Бу газап — олуг көннең газабы. Бу кавемнең һәлак булуында да гыйбрәт бар, аларның күбрәге ышанучы булмадылар. Дөреслектә, синең Раббың, дошманнарыннан га-

**зап белән үч алучы вә дусларына рәхмәт итүче».** (Шүгарә: 176 – 191)

Кадерле, газиз балалар! Шөгайб галәйһиссәламнең кыйссасын шушының белән тәмамлыйбыз. Сезгә Коръән Кәримнән бу кыйссага бәйле күп кенә аятьләрне искә алдык. Файдалы гыйлемнәр алып, вәгазьләнеп изге гамәлләр кылырга ашыгырсыз, дип ышанып калабыз. Киләсе пәйгамбәр тормышында очрашканга кадәр, вәссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Шөгайбнең عليه السلام кавеме үлчәүләрне киметеп кешеләрне алдыйлар иде.Бу хәрам эшләр зур гөнаһлардан саналып дөньяда да, ахирәттә дә каты газапка илтә.

**2)** – Шөгайб عليه السلام кавемен гаделлеккә чакырды.

**3)** – Шөгайб عليه السلام кавемен бик күп нәсыйхәт кылса да, алар кабул итмәделәр.

**4)** – Аллаһка буйсынмау, каты вә ачы газапка илтә.

**5)** – Без Аллаһ тәгаләнең пәйгамбәрләренә буйсынырга, шәригатьләрен үтәргә тиешбез.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Аллаһ тәгалә Шөгайбне кемнәргә пәйгамбәр итеп җибәрде?

**2)** – Шөгайб عليه السلام кавеме нинди җинаятьләр эшли иде?

**3)** – Шөгайб عليه السلام кавемен нәрсәгә өндәде?

Дөрес җөмләләр артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата җөмләләр артына ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Аллаһ тәгалә Шөгайбнең кавемен каты җир тетрәү белән һәлак итте (  )

**2)** – Шөгайбнең кавеме нәсыйхәтләрне кабул иттеләр (  )

**3)** – Шөгайб عليه السلام кавеме сәүдә эшләрен гаделлек белән үтиләр иде (  )

**4)** – Шөгайб عليه السلام кавемен иманга, Аллаһка гыйбадәт кылырга вә гаделлеккә чакырды (  )

# Әюп عليه السلام

Әюп галәйһиссәлам дә Шөгайб галәйһиссәлам кебек нәсел-нәсәбе белән Ибраһим галәйһиссәламгә тоташа. Тарих вә тәфсир белгечләре әйтүләренчә, Әюп галәйһиссәлам бик тә бай булып, балалары да күп иде. Аллаһ тәгалә биргән бу нигъмәтләргә ул бик шөкерле булып, Аның әмерләрен үтәп, тыйганнарыннан тыелып яши торган булды. Аллаһ Сөбханәһү вә тәгалә Әюп галәйһиссәламне бик зур сынаулар белән сынады һәм ул Раббысыннан булган сынауларны сабырлык белән уздырды.

Шушы сынауларның берсе: Бервакыт Әюп галәйһиссәлам бик каты авырып китте. Хәтта тәне бик каты зәгыйфьләнеп ябыкты. Шуның өстенә аңа бирелгән байлык-нигъмәтләр һәммәсе дә Раббысының теләге белән юкка чыкты. Кешеләр бу хәлне күреп аны мәсхәрә кылдылар һәм бер-берсенә: «Әюпнең Аллаһка гыйбадәт кылуы, хәзерге хәлендә файда бирерме икән?», — дип көлештеләр. Ләкин, алар иң зур авырлыклар пәйгамбәрләргә, аннары изгеләргә, аннары изгеләр кебекләргә килгәннәрен белмиләр иде. Кеше үзенең иманы, дине микъдарына карата сынала. Шуңа да пәйгамбәрләргә иң зур сынаулар, авырлыклар булды. Әюп عليه السلام бу авырлыкларга зур сабырлык күрсәтте. Кешеләр барысы да аның янын-

нан ераклаштылар, киселделәр, иллә-мәгәр хатыны гына аның белән булып ярдәм күрсәтте вә Аллаһка гыйбадәттә булды.

Бу хәлне, балалар, хәзерге тормышта да тасвирлый алабыз. Әгәр бер кеше баеса, яки бик зур түрә булса, мәсәлән: шәһәр башлыгы яки президент кебек, ул вакытта күп кенә кешеләр үзләренең бер тиенлек дөнья мәсьәләләрен хәл итәр өчен, аның янына якынрак булырга тырыша. Барысы да аны мактый, икейөзлелек күрсәтә, янында сыпырына, ялагайлана һәм башкалар. Ә инде шул кеше көннәрдән бер көнне фәкыйрьгә әйләнсә, ул вакытта, аның янында дөнья өчен булган кешеләр аңардан читләшә вә ерагая башлыйлар. Чөнки бу кешедән аларга бер хаҗәт тә калмый һәм икенче бай вә урынлы кешегә таба якыная башлыйлар. Аллаһ тәгалә кешегә байлык биреп, яки аны фәкыйрь кылып иманын сыный. Әмма зәгыйфь, сай фикер йөрткән кешеләр боларны аңламый вә үз мәслихәтләрен (файдаларын) генә уйлап, хәсрәткә калалар.


Әюп عليه السلام бу авырлыклардан төшенкелеккә бирелмәде. Көннәрдән бер көнне, ул Раббысына дога кылып ялварды (мәгънәсе): **«Вә Әюпне дә хәтерләгез, Ул Раббысына дога кылды: «Әй Раббым! Мине сырхау вә катылык тотты, Син рәхмәт итүчеләрнең иң рәхимлесе».** (Пәйгамбәрләр: 83)

Аллаһ тәгалә Әюп галәйһиссәламнең догасын кабул итте. Аңа сәламәтлеген вә барча булган байлыгын икеләтә арттырып бирде.

Бу Әюп галәйһиссәламнең сынауларыннан булган бер күренеш. Ул бу сынауларга бик озак еллар

сабырлык күрсәтте. Аллаһ аның хәлен җиңеләйткәч, ул Раббысына шөкераналар кылды һәм кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылып, Аңа ширек катудан ераклашырга чакырды. Аларны Җәннәт белән өметләндерде вә Җәһәннәм белән куркытты. Ахыргы көннәренә кадәр кешеләрне иманга чакырды.


Әюп галәйһиссәлам кыйссасы хакында Аллаһ тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте (мәгънәсе): **«Янә колыбыз Әюпне عليه السلام искә ал, Әюп Раббысына дога илә мөрәҗәгать итте: «Әй Раббым, мине шәйтан авырлык вә каты мәшәкать илә тотты, малымны вә балаларымны һәлак итте». Әюп күп еллар сырхау булды, һич нәрсәсе калмады, ул һаман сабыр итте, зикердән туктамады. «Әй Әюп, аягың илә җиргә тип», — дип әйтелде, типкәннән соң салкын чишмә, ә юынырга кайнар чишмә чыкты. Кайнар чишмәдә юынды вә салкын чишмәдән эчте, шунда ук сәламәтләнеп, әүвәлге куәтен тапты. Вә Без Әюпкә балаларын ике өлеш арттырып бирдек, Бездән аңа рәхмәт булсын өчен вә гакыллы кешеләргә вәгазь булсын өчен. Әй Әюп, бер уч салам алып хатыныңа сук, Аллаһ исеме илә әйткән антыңны үтәмичә гөнаһлы булып калма. (Сырхау вакытында үзен караучы хатыны хакында хаталык илә уйлады: «Валлаһи, терелсәм сиңа йөз мәртәбә сугармын», — дип ант иткән иде.Шуңа бер уч йөз салам илә сугу, йөз мәртәбә суккан хөкемендә булды). Без Әюпне бәла-казага вә сырхауга сабыр итүче итеп таптык. Ул Әюп ни хуш бәндә вә ул Аллаһка һәрдаим мөраҗәгать итүче».** (Сад: 41 – 44)







Әюп һәм Зүл-Кифель галәйһиссәламнәрнең нәселләре




Әт-Табари исемле галим, үзенең тарих китабында Әюп г.с.нең яшәгән урыны Дамаск шәһәренең көньягында урнашкан Әль-Бәсәния исемле җирдә булган, дигән фикерне әйтә. Кайбер башка тарихчылар әйтүе буенча — Әюп г.с. "Үле диңгез"нең көньяк өлешендә булган Әдүм исемле җирдә яшәгән. Аллаһу әгъләм.

Шуның белән, кечкенәләрем, Әюп ﷺ тормышына булган сәяхәтебезне тәмамлыйбыз. Аллаһ тәгалә безгә ошбу кыйссалар белән гыйбрәтләнеп, изге гамәлләр кылырга насыйп итсен. Әмин! Икенче пәйгамбәр тарихында очрашканчыга кадәр, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Әюп галәйһиссәлам бик бай иде.

**2)** – Әюп галәйһиссәлам бик каты авыру белән хасталанды.

**3)** – Күп кешеләр байларга вә дөньяви дәрәҗәле түрәләргә якынаерга тырышалар.

**4)** – Күп кешеләр сай фикер йөртүләре белән фәкыйрь вә мескеннәрдән читләшәләр.

**5)** – Әюп галәйһиссәлам Аллаһ тәгаләдән булган сынауга зур сабырлык күрсәтте.

**6)** – Аллаһ тәгалә Әюп галәйһиссәламне алдагы сәламәт вә бай хәленә кайтарды.

**7)** – Сабырлык уңышка ирешү ачкычы вә Җәннәткә керүнең сәбәбе.

**8)** – Аллаһ тәгалә сабырларга зур әҗерсавап бирә.

**9)** – Иманга чакыручы кеше барча авырлыкларга вә мәшәкатьләргә сабыр итәргә тиеш.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер.

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Әюп галәйһиссәлам авырлыкларга сабыр итмеме?

**2)** – Кешеләр ни өчен байларга якынаялар?

**3)** – «Кеше үзенең иманына, диненә карата сыналыр», — дигәнне аңлатып уз.

Бу очракларда ни эшләрсең?

**1)** – Фәкыйрь кеше синнән ярдәм сораса.

**2)** – Бай кеше синнән акча-мал сораса.

**3)** – Фәкыйрьләрдән көлүче кешене күрсәң.

**4)** – Дустың фәкыйрьләрдән читләшә торган булса.

**5)** – Берәр кеше байларга нәфрәтлек вә бозык көнчеллек белән караса.

**6)** – Бер кеше бай булганнан соң фәкыйрьгә әйләнсә.

# Зүл-Кифел عليه السلام

Зүл-Кифел пәйгамбәрләрдән булып, аның исеменең мәгънәсе хакында болай диелә. Ул үзенең кавемен гаделлек белән хөкем итеп, араларында золым кылуны тыйды вә Аллаһ тәгалә кушканнарын үтәргә боерды. Шушы эшләрне тәкәффүл кылганы (өстенә алганы) өчен, ул Зүл-Кифел дип аталды. Аллаһу әгъләм.

Коръән Кәримдә Зүл-Кифел галәйһиссәлам хакында бик сабырлардан булуы турында әйтелә. Аллаһ тәгаләгә гыйбадәт кылуда вә кешеләрне иманга чакыруда ул бик зур сабырлык күрсәтте. Аллаһ тәгалә сабырлар хакында болай диде (мәгънәсе): **«Хакыйкатьтә, сабырларга хисапсыз әҗерләр бирелер».** (Зүмәрә: 10)

Шуның өчен дә, балалар, Раббыбыз Кыямәт көнендә әҗер-савапларга ирештерсен өчен, без Аллаһка итагать итүдә, Аның динен таратуда, харамнардан ераклашуда бик зур сабырлык кылырга тиешбез.


Аллаһ тәгалә Зүл-Кифел хакында Коръәни Кәримдә болай диде (мәгънәсе): **«Вә Исмәгыйльне вә Идрисне вә Зүл-Кифелне хәтерләгез, боларның барчасы да сабыр итүчеләрдән иде. Без аларны рәхмәтебезгә керттек, чөнки алар чын изгеләрдән иделәр».** (Пәйгамбәрләр: 85 — 86)

Аллаһ тәгалә пәйгамбәрләрне сабырлык белән сыйфатлады һәм алар Раббылары әмер иткән эшне тиешлечә, сабырлык белән үтәделәр. Шулай ук, алар салих (изгелек) сыйфаты белән сыйфатландылар. Аларның салихлыгы сөйләшүләрендә дә, гамәлләрендә дә бар иде. Аллаһ тәгалә тарафыннан булган мактаулар, пәйгамбәрләрнең зур дәрәҗәләргә лаек икәнлеген билгели.

Коръән Кәримдә аларны сыйфатлап болай диелде (мәгънәсе): **«Янә Минем колларым Ибраһим, Исхак вә Ягъкупларны искә ал, алар гыйбадәттә куәт ияләре вә диндә басыйрәт ияләре иделәр. Дөреслектә, Без аларны гөнаһтан пакь эшләрдә ихлас кылдык, шул сәбәпле алар ахирәт савабына бик каты тырыштылар. Вә алар Безнең хозурыбызда яхшылыкка гына ихтыяр ителмешләр. Янә Исмәгыйль, Әлясәгъ вә Зүл-Кифелләрне зикер ит, аларның һәркайсы изгеләрдән иде».** (Сад: 45 – 48)

Зүл-Кифел Аллаһ каршында булган бурычларын үтәп, кешеләрне туры юлга вә иманга чакырды. Вафат булганчыга кадәр Аллаһ юлында дәгъват итеп, барча авырлыкларга да, мәшәкатьләргә дә сабыр итте.

Шушында, Зүл-Кифел хакында сүзебезне тәмамлыйбыз. Аллаһ тәгалә ниятләребезне ихлас кылып, гамәлләребезне кабул итсен. Әмин! Киләсе пәйгам-бәр тарихында очрашканга кадәр, вәссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!




Аллаһ тәгалә Зүл-Кифелне ﷺ Дамаск һәм аның янындагы кешеләргә пәйгамбәр итеп җибәрде.

**Беренче:** Кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Зүл-Кифел гаделлек белән хөкем итүне өстенә алган өчен шулай исемләнде.

**2)** – Кыямәт көнендә сабырларны зур савап көтә.

**3)** – Аллаһ тәгалә Зүл-Кифелне рәхмәтенә кертте һәм салихлардан кылды.

**4)** – Зүл-Кифел кавемен иманга чакыруда сабырлардан булды.

**5)** – Аллаһ каршында пәйгамбәрләрнең дәрәҗәләре зур.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Ни өчен Зүл-Кифел дип аталды?

**2)** – Ни өчен Аллаһ тәгалә Зүл-Кифелне Үзенең рәхмәтенә кертте?

**3)** – Аллаһ тәгалә сабырларга нәрсә вәгъдә итте?

**4)** – Аллаһ тәгалә пәйгамбәрләрне кемнәрдән сайлады?

Дөрес җөмләләр артына ( √ ) ошбу билгене, ә хата җөмләләр артына ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Аллаһ Зүл-Кифелне татарларга җибәрде ( )

**2)** – Аллаһ тәгалә пәйгамбәрләрне фәрештәләрдән сайлады ( )

**3)** – Пәйгамбәрләр иң хәерле кешеләр ( )

**4)** – Зүл-Кифел үзенә йөкләнгән пәйгамбәрлек бурычын тиешенчә үтәде ( )

# Муса عليه السلام

Мисыр җирендә бик тә залим явыз патша бар иде. Ул заманаларда патшаларны фиргавен дип атый торган булдылар. Дөресрәге, хәзерге вакытта дәүләт башлыгына президент дип әйтелсә, ул вакытларда Мисыр патшасына фиргавен дип әйтелә торган иде. Һәрвакыт фиргавен исеме искә алынса, аның белән золым вә үтерү, җинаять вә тәкәбберлек, рәнҗетү вә көчләү искә алына торган булды.

Бу кыйссабызда Муса галәйһиссәлам вакытында, Мисырда хәкимлек иткән Фиргавен искә алыныр. Ул бик тә залим вә тәкәббер булып, кешеләрне үтереп, хатыннарын көчләп ала торган булды. Хәтта, үзен «иләһ» итеп белгертеп, аңа табынырга куша иде.

Фиргавеннең Һәмән исемле вәзире бар иде. Бу вәзир Фиргавеннән золымлык, тәкәбберлек вә башка бозык сыйфатларны өйрәнеп, аның кебек үк кешеләрне җәберли һәм рәнҗетә торган булды. Кешеләр исә бу залимнардан арып-туйдылар. Аллаһ тәгаләдән җиңеллек килгәнчегә кадәр, ул үзенең явызлыгын, золымлыгын елдан-ел арттыра гына барды.

Фиргавен патшалыкны, идарә итүне, байлыкны бик тә ярата иде. Көннәрдән бер көнне шушы патшалыгы, байлыгы бер егет сәбәпле юкка чыгачагын һәм ул

егет кешеләрне хаклыкка өндәп Фиргавеннең «иләһ» булмыйча, ә гади бер кеше икәнлеген бәян кылачагын сизде. Шуңардан куркып, Фиргавен һәрбер туган ир-ат баланы үтереп, хатын-кызларны гына калдырырга боерды.

Бу вакытларда Муса галәйһиссәламнең әнисе аның белән йөкле иде. Муса галәйһиссәлам дөньяга килгәч әнисе аның өчен курка төште. Әмма Аллаһ тәгалә Үзенең булачак пәйгамбәрен ярдәмсез калдырмады: Муса галәйһиссәламнең әнисенә, курыкмыйча, аны сандыкка салып диңгезгә төшерергә кирәклеген белгертте. Һәм чыннан да, кадерле балалар, Мусаның әнисе Аллаһка тәвәккәл кылып, үзенең баласын сандыкка салып диңгезгә төшерде. Сандык Аллаһ тәгаләнең сагында, диңгез буйлап агып китте. Ләкин, ни гаҗәп, сандык, явыз Фиргавен сарае урнашкан яр буена килеп туктады.

Бу вакытта, яр буена суга дип төшкән Фиргавеннең хезмәтчеләре сандыкны күреп алдылар һәм Фиргавеннең хатынына алып кайтып бирделәр. Ачып карасалар, ни күзләре белән күрсеннәр, сандык эчендә бик тә сөйкемле, матур бала ята иде. Шушы арада Фиргавен үзе килеп керде вә баланы күреп калды. Хатыны аңа: «Әй Фиргавен, үтермә аны, калдыр, бәлки ул безгә киләчәктә ярдәмче терәк булыр», — дип ялваргач, Фиргавен риза булды.

Инде балалар, Аллаһ тәгалә шулай кылды ки, явыз вә залим Фиргавен үзенең дошманы дип санаган Муса галәйһиссәламне үзе дә сизмичә йортына кертеп тәрбиягә алды. Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә һәрнәрсә белән идарә кылучы вә һәрнәрсәгә көче җитүче.

Инде балалар, алга таба ни булганын карагыз.

Бераздан Муса галәйһиссәлам ачыгып елый башлады һәм анны ашатырга дип имезүче хатын эзли башладылар. Кем генә килмәсен — бала аларны кабул итмәде. Мусаның хәбәрләрен белешеп торучы апасы, бу очрактан файдаланып, Фиргавеннең хатынына: «Мин бу баланы имезүче хатынны таба алам», — диде. Фиргавен хатыны бик шатланып риза булды һәм ул имезүче хатынны алып килергә кушты. Инде имезүче хатын кем булырга мөмкин, дип беләсез, балалар? Әйе, ул Муса галәйһиссәламнең әнисе иде.

Муса галәйһиссәламнең әнисе килеп, аны кочагана алып ашата башлады. Аллаһ тәгалә ошбу сынауда, аның йөрәген ныклы кылып, сабырлык биргән өчен, ул ана бетмәс, иксез-чиксез шөкраналар кылды.

Бу күренеш хакында Коръәни Кәримнең әл-Касас сүрәсендә болай диелде (мәгънәсе): **«Та-Сиим-миим. Ошбу аятьләр дөреслек белән ялган арасын ачык аерып бәян итүче Коръән аятьләре. Без сиңа Муса белән Фиргавен хәбәрләреннән хаклык белән укыйбыз, иман китергән кавемнәр өчен. Дөреслектә, Фиргавен Мисыр җирендә олугланды, дәхи Мисыр халкын үзенең хезмәтендә төрле дәрәҗәләргә бүлде, алардан берәүләрен хурлар иде, кыз балаларын калдырып ир балаларын бугазлатыр иде, ул Фиргавен күп бозыклык кылучы фасикъларлардан булды. Фиргавен кулында кимсетелгәннәрне коткарып аларга рәхмәт итәргә һәм аларны имамнар һәм варислар итәргә теләдек. Янә Фиргавенгә, Һәмәнгә һәм аларның гаскәрләренә үзләре курыккан Мусаны күрсәтер-**

гә теләдек һәм аларга җирдә патшалык бирергә теләдек. «Фиргавен Ягъкуп балаларыннан куркып аларның ир балаларын үтертә барды, әмма үзенең башына җитәчәк Мусаны үзе тәрбияләп үстерде». Мусаның анасына вәхи кылдык: «Балаңны имез, әгәр үтерүләреннән курыксаң, Мусаны Нил дәрьясына сал, батар дип курыкма һәм кулыңнан китүенә кайгырма, Без аны сиңа кайтарачакбыз вә аны пәйгамбәрләрдән кылачакбыз». Фиргавен җәмәгате, таң аткач, Мусаны дәрьядан табып алдылар, Аллаһ бу эшне эшләде, Муса Фиргавенгә дошман һәм кайгы булсын өчен. Дөреслектә, Фиргавен һәм аның вәзире Һәмән вә аларның гаскәрләре хаталык кылдылар, гөнаһ эшләүчеләрдән булдылар. Фиргавен хатыны әйтте: «Бу бала минем дә, синең дә күз нурыбыз булыр, аны үтермәгез», чөнки шул вакытта аны үтерергә теләгәннәр иде. «Шаять, безгә файда итәр яки без аны үзебезгә бала итеп алырбыз». Ләкин алар бу эшнең ахырын белмәделәр. Мусаның Фиргавен кулына төшкәнен белгәч, анасының күңеле кайгыдан бушанды. Хәтта Муса үзенең улы икәнлеген белдерергә якын булды, әгәр дә иманлы булып калуында Без аның йөрәген ныгытмаган булсак, әлбәттә, алданыр иде. Мусаның анасы Мусаның туган апасына әйтте: «Муса артыннан бар, бәлки берәр хәбәр алып кайтырсың». Апасы Мусаның сандыгы кая китүен ерактан күрде, әмма Фиргавен җәмәгате берсе дә бу эшне белми иделәр. Вә Без анасыннан кала, башка имезүче хатыннарны имүдән Мусаны тый-

**дык, күп хатыннар килделәр Мусаны имезергә, ләкин берсен дә ул кабул итмәде. Мусаның апасы Фиргавеннәргә әйтте: «Әллә мин сезгә бер өйнең җәмәгатен күрсәтимме, ул хатын сезнең өчен баланы имезеп тәрбияләр һәм ул җәмәгать балага яхшы нәсыйхәт бирүчеләрдән», — дип. Анасын чакырып китерделәр, Муса анасының сөтен имде. Мусаны анасына кайтардык, баласын күреп күзе шатлансын һәм көенмәсен һәм дә Аллаһның вәгъдәсе хак икәнне белсен өчен, ләкин күп кешеләр Аллаһның эше вә вәгъдәсе хак икәнне белмиләр».** (1 – 13)

Фиргавеннең хатыны кечкенә Мусаны عليه السلام яратты, шуңа да ире Фиргавеннән, Мусаны имезүче әнисен алар белән торуын сорады. Фиргавен каршы килмәде. Шулай итеп балалар, Муса галәйһиссәлам Фиргавеннең йортында тәрбияләнеп үсте. Зураеп бәлигъ чоры җитеп көчле егет булгач, Аллаһ тәгалә аны пәйгамбәрләрдән кылып вәхи иңдерде.

Көннәрдән бер көнне, Муса галәйһиссәлам патша сараеннан чыгып, шәһәр урамнарында йөргәндә ике сугышкан кешене күреп алды. Аларның берсе Мусаның, ягъни Бәнү Исраил кавеменнән, икенчесе кыбтый (Фиргавен) ягыннан иде. Бәнү Исраил кавеменнән булганы аннан ярдәм сорады. Аллаһ тәгалә Муса галәйһиссәламне көч-куәт белән нигъмәтләндергән иде. Ул үз кавеменнән булган кешене яклап кыбтыйга кулы белән сугуга, теге җиргә егылып җан-тәслим кылды. Муса галәйһиссәлам бу хәлгә аптырап калды. Чөнки ул аңа җиңелчә генә

итеп суккан иде. Һәм моңа бик тә үкенеп вә тәүбә итеп Раббысының ярлыкавын сорады.

Бу хакта Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Муса Фиргавен шәһәре — Мисырга керде, Мисыр халкы Мусаның шәһәргә керүеннән гафләттә иделәр, анда сугыша торган ике ирне күрде, берсе Ягъкуп балаларыннан (бәнү Исраил кавеменнән), икенчесе — дошманы булган кыбтыйлардан иде. Ягъкуп балаларыннан булган ир, дошманына каршы Мусадан ярдәм сорады. Муса кулын йодрыклап кыбтыйга сукты һәм кыбтый үлде. Муса әйтте: «Кеше үтерү шәйтан эше, ул шәйтан кешеләрне аздыручы ачык дошман. Әй Раббым, мин үземә золым иттем, мине ярлыка!» Аллаһ аны ярлыкады, хакыйкатьтә, Ул — Ярлыкаучы, Рәхимле».** (әл-Касас: 15 – 16)

Бу вакыйгадан соң Муса галәйһиссәлам шәһәрдә куркып йөри башлады. Һәм шул хәлдә йөргән арада, икенче көнне, ул тагын шул ук, Бәнү Исраил кешесенең икенче кыбтый кешесе белән сугышканын күрде. Кичә Мусадан ярдәм сораган кеше, янә аңардан ярдәм сорады. Ул ярдәм итәм дип кыбтыйга каршы барганда, кыбтый кавеменнән булган кеше әйтте (мәгънәсе): **«Әй Муса! Кичә үтергән кешене үтергән кебек, син мине дә үтермәкче буласыңмы?».** (әл-Касас: 19). Шунда кешеләр, узган көндәге кыбтыйның Муса галәйһиссәлам үтергәнен, белеп алдылар. Аны кулга алырга дип, Фиргавен гаскәрен җибәрде. Мусаның иптәшләреннән булган берәү бу хәбәрне белеп аңа ирештерде һәм Муса галәйһиссәламне үтерүләреннән куркып, аның бу җирләрдән тизрәк

китүен сорады. Муса ﷺ Мисыр җиреннән тиз рәвештә чыгып китте һәм Шөгайб галәйһиссәлам яшәгән Мәдйән җирләренә барып җитте. Шәһәргә кергәч, ул кешеләрнең коедан су алып хайваннарын эчергәннәрен күрде. Алар янында, үзләренең хайваннарын су эчертә алмый читтә басып торган ике кызны күреп алды һәм алар янына барып хайваннарына су эчертергә ярдәм итте. Аннары агач күләгәсенә кереп, Аллаһка ялварды. Ул шулай утырганда кызларның берсе бик оялып кына Муса галәйһиссәлам янына килеп: «Безнең сарыкларыбызны эчерткәнең өчен, әтиебез сиңа хакын бирмәкче», — диде.

Муса ﷺ кызларның әтиләре янына юнәлде. Күрешеп танышкач, аңа Мисыр җирендә Фиргавен белән булган хәлне сөйләде. Кызларның әтисе Мусага: «Әй Муса! Курыкма. Аллаһ сине залим кавемнән коткарды. Син монда тынычлык табарсың. Минем янымда 8 ел калырга риза булсаң, үземнең бер кызыма өйләндерермен», — диде.

Муса галәйһиссәламнең бу вакыйгаларын сурәтләп Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Муса үсеп, куәткә җитеп, гакылы, буе тигезләнгәч, аңа шәригать хөкемнәрен һәм белем бирдек, әнә шулай Безгә итагать иткәннәргә изге җәза бирәбез. Муса Фиргавен шәһәре – Мисырга керде, Мисыр халкы Мусаның шәһәргә керүеннән гафләттә иделәр, анда сугыша торган ике ирне күрде, берсе Ягъкуп балаларыннан (Бәнү Исраил кавеменнән), икенчесе дошманы булган кыбтыйлардан иде. Ягъкуп балаларыннан булган ир, дошманына каршы Мусадан ярдәм сорады,**

Муса кулын йодрыклап кыбтыйга сукты һәм кыбтый үлде, Муса әйтте: «Кеше үтерү шәйтан эше, ул шәйтан кешеләрне аздыручы ачык дошман». Үкенеп әйтте: «Йә Раббым, кеше үтерү сәбәпле үземә золым иттем, мине ярлыка!». Аллаһ аны ярлыкады, хакыйкатьтә, Ул Ярлыкаучы, Рәхимле». Янә әйтте: «Йә Раббым, мине ярлыкаганың өчен, мин беркайчан да кәферләргә ярдәмче булмамын». Соңра, Муса Мисыр шәһәрендә курыккан хәлдә, миңа ни була инде, дип хөкем көтеп калды. Кичә кыбтый белән сугышканда Мусадан ярдәм сораган кеше, бүген дә бер кыбтый белән сугышып, янә Мусадан ярдәм сорады. Муса ярдәм сораучыга әйтте: «Син ачык бер азгын кеше». Мусага да вә Мусадан ярдәм сораучыга да дошман булган кыбтыйны, Муса тотарга теләгәч, кыбтый әйтте: «Әй Муса, мине үтерергә телисеңме, бит кичә бер кешене үтергән идең, син Мисыр җирендә кеше үтереп залим булырга телисең, әмма төзәтүчеләрдән булырга теләмисең». Бер ир шәһәр читеннән бик ашыгып Муса янына килде һәм әйтте: «Әй Муса, аксөякләр сине үтерергә киңәшләшәләр, син бу шәһәрдә торма, чык, мин сиңа яхшы киңәш бирүчеләрдәнмен». Артымнан куа чыгарлар, дип, курка-курка Муса шәһәрдән чыкты: «Йә Раббым, мине залим кавемнән коткар», — диде. Муса Мәдйән шәһәренә юнәлде, ләкин юлны белми иде, әйтте: «Шаять Раббым мине туры юлга күндерер», — дип. Мәдйәннең кое суына җиткәндә, ул кое янында хайваннарны эчерүче бер җәмәгатьне күрде, дәхи аларның

артында ике хатынны күрде, алар хайваннарына су эчерми аларны куалыйлар иделәр, Муса әйтте: «Ни булды сезгә хайваннарыгызга су эчермисез?». Ул ике кыз әйттеләр: «Алдыбыздагы көтүчеләр хайваннарын эчереп китмичә без эчермибез һәм безнең атабыз бик карт кеше, шул сәбәпле хайваннарны эчерергә чыга алмый», — диделәр. Кызлар коедан су ала алмыйлар иде, фәкать башка көтүләрдән калган суны эчерәләр иде. Муса коедан су чыгарып кызларның куйларына су эчерде, соңра китеп күләгәгә утырды һәм әйтте: «Йә Раббым, Син биргән барча нигъмәткә мин мохтаҗмын», — дип. Кызлар кайтып аталарына Муса хакында сөйләделәр, аталары бер кызын Мусаны чакырырга җибәрде. Ул ике кызның берсе оялып кына Муса янына килде: «Атам сине чакыра, безнең куйларны эчерүеңнең хакын бирмәк өчен», — диде. Муса кызларның атасы, Шөгайб пәйгамбәр янына килгәч, башыннан кичкән вакыйгаларны сөйләде. Шөгайб: «Муса, курыкма, залим кавемнән котылдың», —диде. Ике кызның берсе әйтте: «Әй атам, бу кешене хакын түләп көтүчелеккә ал, тәхкыйк ул, син хак түләп алган кешеләрнең хәерлесе-куәтлесе һәм әманәтле булганыдыр». Аның куәтле вә әманәтле булганлыгы, авыр чиләкне коедан бер үзе тартып чыгарып хайваннарны су эчерүеннән (чөнки кое чиләге авыр булу сәбәпле, аны берничә кеше тартып чыгара иде) һәм чакырырга баргач, ят хатын-кызга күзе төшмәсен өчен, үзе алдан барып, кызлар аның артыннан баруында чагыл-

**ды. Шөгайб әйтте: «Куйларымны сигез ел көтүең бәрабәренә мин ошбу ике кызның берсен сиңа никахламакны телим. Әгәр ун елга тутырасың икән, ансы синең изгелегеңдәдер, ун ел хезмәт ит дип, сине мәшәкатьләргә теләмим, вәгъдәдә торуда һәм йомшаклык кылуда, Аллаһ теләсә мине изгеләрдән табарсың». Муса әйтте: «Ошбу шарт синең белән минем арабызда, ике мөддәтнең кайсын гына үтәсәм дә, мине золым итү булмасын, ошбу сөйләшүләребезгә Аллаһ шаһиттер».** (әл-Касас: 14 – 28)

Шөгайб галәйһиссәлам янында вәгъдә кылган сигез ел урынына, ун ел вакытын тутыргач, Муса галәйһиссәлам хатыны вә балалары белән Мәдйәннән чыгып, Мисыр җиренә юнәлде. Юлда ул Синай җирендәге Тур тавы янында ут күреп алды һәм гаиләсенә: «Мин килгәнче монда торып торыгыз», — дип, ут яктысына таба юнәлде. Аңа якыная төшкәч, ул тавыш ишетте (мәгъәнәсе): **«Ут янына килгән заманда Аллаһ тарафыннан: «Әй Муса! Мин синең Раббың, башмакларыңны сал, син Тува исемле изге үзәнлектәсең. Мин сине пәйгамбәрлеккә ихтыяр кылдым, сиңа вәхи ителмеш сүзләрне ишет! Дөреслектә, Мин — Аллаһ, Миннән башка илаһ юк, бары тик Мин генә. Миңа гына гыйбадәт кыл вә Мине зикер итәр өчен намаз укы! Дөреслектә, Кыямәт көне киләчәк, аның кайчан булачагын яшерүне телим, соңра, вакыт җиткәч һәрбер кеше үзенең гамәле өчен җәзасын алсын өчен. Берәүнең Кыямәт көненә ышанмавы һәм нәфесенә ияреп явыз эшләрне эшләве, сине Кыямәт көненең бу-**

**лачагына ышанудан тыймасын, ул вакытта син һәлак булырсың».** (Таһа: 11 – 16)

Шуннан соң, Аллаһ сорап әйтте (мәгънәсе): **«Аллаһ тәгалә Мусадан сорады: «Әй Муса, синең уң кулыңда нәрсә бар?». Муса әйтте: «Бу минем таягым, шул таягыма таянып йөрим вә ул таягым белән куйларыма агач яфракларын сугып төшерәмен һәм ул таяктан миңа башка файдалар да бар». Аллаһ әйтте: «Әй Муса, таягыңны җиргә ташла». Муса таякны җиргә ыргытты. Ул таяк, тиз шуышып йөрүче еланга әверелде. Аллаһ әйтте: «Әй Муса, бу еланны тотып ал, курыкма, Без аны әүвәлге халәтенә кайтарырбыз». Ягъни елан Муса кулында янә таяк булды. Инде уң кулың белән сул култык астына сук: уң кулыңны култыгыңнан чыгар, күзне чагылдыра торган ак һәм зарарсыз булыр — бу синең пәйгамбәрлегеңә икенче галәмәт булыр. Бу эшне кылдык, синең пәйгамбәрлегеңә дәлил булып, кешеләргә күрсәтү өчен».** (Таһа: 17 – 23)

Кадерле балалар! Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә һәрнәрсәне белүче, Аның Мусадан соравы, Мусаның йөрәген тынычландыру хикмәте иде. Чөнки Муса таягын җиргә ташлагач, ул таяк Аллаһ тәгалә теләге белән еланга әверелә иде. Шулай ук, Мусага бирелгән тагын бер могҗиза ул — кулын кесәсенә тыгып чыгаргач, аның кулы Аллаһ тәгаләнең теләге белән бернинди зарарсыз, якты нур чәчеп торыр булды. Бу могҗизалар, Муса галәйһиссәлам Бәнү Исраил кавемен бер Аллаһка гыйбадәт кылырга чакырганда һәм Фиргавеннән курыкмаска ярдәм вә терәк иде. Ошбу

ярдәмнәрнең Аллаһ тәгаләдән икәнлеген белгәч, Муса галәйһиссәламнең йөрәге тынычланды. Ул шулай ук, Раббысыннан, аның белән бергә дәгъват кылыр өчен, туган кардәшләреннән булган Һарунны җибәрүен сорады.

Бу күренешне Аллаһ тәгалә Корьәндә болай тасвирлый (мәгънәсе): **«Фиргавен янына барып, аны хак дингә өндә, ул чиктән тыш азды, хәтта: «Мин — илаһ», — дия башлады. Муса әйтте: «Йә Раббым, күкерәгемне киң кыл залимнәрнең каршылыгына сабыр итәргә. Вә эшләремне миңа җиңел кыл. Вә телемнән төенне чиш, сөйләшүдә тотлыгуымны бетер. Тыңлаган кешеләр сүземне аңласыннар өчен. Миңа үз әһелемнән бер ярдәмче бир, кардәшем Һарунны. Аның белән минем куәтемне арттыр. Вә миңа аны пәйгамбәрлек эшемдә ярдәмче иптәш кыл. Сиңа күп тәсбих әйтер өчен. Вә Сине күп зикер итер өчен. Тәхкыйк, Син безнең хәлләрне күреп беләсең. Аллаһ әйтте: «Әй Муса! Тәхкыйк сиңа сораган нәрсәләрең бирелде».** (Taha: 24 – 36)

Шулай итеп, газиз балалар, Муса үзенең кардәше Һарун белән җир йөзендә бозыклык таратучы, залим Фиргавенне бер Аллаһка гыйбадәт кылырга вә ширек, золымнан читләшүгә чакырырга дип, Мисыр җиренә юнәлде.

Алар Фиргавенгә кергәч, ул Муса галәйһиссәламне танып алды. Алар Раббыларының әмерен искә алып, Фиргавенне йомшаклык белән бер Аллаһка чакыра башладылар.

Коръәндә бу хакта менә ничек әйтелде (мәгънәсе): **«Әй Муса, үзең вә кардәшең Һарун, Мин биргән могҗизалар белән Фиргавенне вә аның кавемен хак дингә өндәргә барыгыз вә Мине зикер итүдә иренмәгез! Вәгазьләр өчен, икегез Фиргавенгә барыгыз, чөнки ул чиктән тыш азды. Аңа йомшак яхшы сүзләр сөйләгез, шаять вәгазьләнер яки Аллаһ газабыннан куркыр. Әйттеләр: «Әй Раббыбыз, без куркабыз Фиргавен ашыгып безгә газап бирер яки явыз эшне эшләвен арттырыр, дип». Аллаһ әйтте: «Әй Муса, курыкмагыз, әлбәттә, Мин сезнең белән, Фиргавенгә сөйләгән сүзләрегезне ишетәмен һәм күрәмен. Барыгыз ул Фиргавенгә вә әйтегез: «Без икебез дә сине хак дингә өндәү өчен җибәрелгән Раббыңның пәйгамбәрләребез. Бәнү Исраилне безнең белән җибәр, аларны төрлечә газаплама. Без сиңа Раббыбыз тарафыннан күндерелгән расүлләр могҗизалар белән килдек, Аллаһның сәламе без күрсәткән хак юлга кергән кешеләргә. Дөреслектә, Аллаһ газабы, пәйгамбәрләрне ялганга тотып, хаклыктан баш тарткан кешеләргә, дип безгә Аллаһтан вәхи килде. Фиргавен әйтте: «Әй Муса! Сезнең Раббыгыз кем?» Муса әйтте: «Безнең Раббыбыз — Үзе халык кылган мәхлукларына һәрнәрсәне бирде, соңра Үзе биргән нәрсәләрдән файдаланырга кешеләргә юл күрсәтте, Ислам диненә юл күрсәтте». Фиргавен әйтте: «Элек үлгән кешеләрнең хәлләре ничек?». Муса әйтте: «Аларның хәлләрен белмәк Аллаһ хозурында, Ләүхүл-Мәхфузда язылмыш. Минем Раббым һич хаталанмый һәм һичнәрсәне**

онытмас. Ул Аллаһ җирне сезгә түшәк кылды, җир өстендә сезгә юллар кылды вә сезгә күктән яңгыр иңдерде. Аллаһ әйтте: «Яңгыр белән сезгә җирдән күп төрле үсемлекләр чыгардык. Без чыгарган ризыклардан яхшыларын ашагыз вә хайваннарыгызны көтегез!». Аллаһның бу эшләрендә гакыл ияләренә гыйбрәтләр бар. Без сезне җирдән яраттык һәм үтереп янә җиргә кайтарабыз, Кыямәт булганда икенче мәртәбә сезне җирдән чыгарабыз». Тәхкыйк, Фиргавенгә могҗизаларыбызның барчасын күрсәттек, Фиргавен аны ялганга чыгарды вә аңа иман китерүдән баш тартты. Фиргавен әйтте: «Әй Муса, сихереӊ белән безне Мисыр җиреннән чыгарырга килдеңме? Әлбәттә, без дә синең сихерең кебек сихер белән килербез, сихерләребезне күрсәтү өчен бер урынга килергә безнең белән синең араңда вәгъдә кыл, вәгъдә ителгән урын һәм вакыт ике якка да тигез булыр, вәгъдәбезгә без дә, сез дә хыйлафлык кылмыйк». Муса әйтте: «Җыелачак көн сезнең бәйрәм көнегез булсын, Мисыр халкы ул урынга төшкә хәтле җыелсыннар». Фиргавен кавеменә кайтты вә хәйләләрен кылды һәм сихерчеләрен җыйды, соңра сихерчеләре белән вәгъдә ителгән урынга килде. Муса әйтте: «Сезгә һәлакәтлек вә газап лязем, Аллаһка ялганны яла якмагыз, Аллаһ сезне Үзенең газабы илә һәлак итәр. Аллаһка ялганны яла ягучы, шиксез, һәлак булды». Фиргавеннең сихерчеләре Мусаның сүзләрен ишеткәч, үзара низаглаштылар һәм сүзләрен яшерделәр. Сихерчеләр әйттеләр: «Ошбу ике ир — сихер-

че: алар сихерләре белән сезне җирегездән чыгарырга һәм сезнең хак динегезне артка калдырып, үзләренең динен өскә чыгаруны телиләр». Фиргавен әйтте: «Муса белән Һарунга каршы хәйләләрегезне вә сихерләрегезне җыегыз, соңра, сафка тезелеп килегез. Бүген җиңгән кеше өскә чыгар». Сихерчеләр әйттеләр: «Әй Муса, син әүвәл ташлыйсыңмы таягыңны яки әүвәл без ташлыйкмы?». Муса әйтте: «Бәлки сез әүвәл ташлагыз!». Сихерчеләр җепләрен вә таякларын җиргә салгач, елан булып йөри башладылар, бу еланнар Мусага йөрүче тере еланнар булып хыял ителде, Муса шул вакытта күңелендә курку тойды. Әйттек: «Әй Муса, курыкма, син алардан өстенсең, алар җиңелер. Таягыңны җиргә ташла, аларның сихер белән елан итеп күрсәткән җепләрен вә таякларын ул ашар, аларның ясаган еланнары сихерченең хәйләседер, сихерче кайда барса да, котылмас». Соңра Муса таягын җиргә ташлады һәм Мусаның таягы сихерчеләрнең бөтен нәрсәләрен ашап бетерде. Мусаның таягы сихерчеләрнең бөтен нәрсәләрен ашап бетергәч, сихерчеләр, иман китерделәр, тәүбә итеп сәҗдәгә егылдылар һәм: «Һарун белән Мусаның Раббысына иман китердек», — диделәр. Фиргавен сихерчеләргә әйтте: «Минем рөхсәтемнән башка Һарун вә Мусаның Раббысына иман китердегезме? Муса сезнең олыгыздыр ки, сезгә сихер белемен өйрәткән, әлбәттә, мин сезнең уң кулыгызны вә сул аякларыгызны кисәрмен вә сезне хөрмә ботакларына асармын, шул вакытта бе-

**лерсез минме яки Мусаның Раббысымы катырак газап итүче вә кайсыбызның газабы даими булыр?!». Иман китергән сихерчеләр әйттеләр: «Әй Фиргавен! Мусаның пәйгамбәрлегенә көчле дәлил булган могҗизаны һәм дә безне яратучы Аллаһны синҗа алыштырмыйбыз, Аллаһка да вә Аның могҗизасына да нык ышандык. Син безгә хөкем ит, нәрсә хөкем итә торгансыңдыр, син тәкәбберләнеп бу дөньяда гына хөкем итә алырсың, әмма ахирәттә хөкем итә алмассың. Тәхкыйк, без Раббыбызга иман китердек, хаталарыбызны гафу итсен өчен, дәхи, Мусага каршы синең тарафтан көчләнеп кылган сихеребезне гафу итсен өчен, бит Аллаһ савап бирүдә хәерле вә газап кылуда даимрәк». Берәү Кыямәт көнне Раббысы хозурына имансыз яки көферлек гөнаһы белән килсә, әлбәттә, аңа Җәһәннәм булыр, ул анда үлмәс һәм аңа файдалы тереклек тә булмас. Берәү Раббысына изге гамәлләр кылганы хәлдә камил иман белән барса, андый мөэминнәргә ахирәттә бөек дәрәҗәләр булыр. Аларга Гаден исемле Җәннәтнең агачлары астыннан елгалар агар, алар анда мәңге калырлар. Ошбу әҗерләр үзен көфердән вә башка гөнаһлардан пакьләгән кешеләргә».** (Таһа: 42 – 76)

Муса, Һарун һәм Фиргавен арасындагы сөйләшү шулай булды. Фиргавеннең бик нык ачуы килде. Барчасы да аны «илаһ» дип уйлыйлар иде. Һәм ул үзенең гади кеше икәнлеген белгертергә теләми иде. Муса галәйһиссәлам кешеләргә әйтмәсен дип, ул аны үзенең сараенда тәрбияләп үстергәнен, аңа

яхшылык күрсәткәнен искә төшерә башлады. Ләкин Муса галәйһиссәлам Раббысы тарафыннан үзенә йөкләнгән дәгъватне ташламый дәвам итәчәген белдерде.

Бу хакта, кадерле балалар, Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Фиргавен әйтте: «Әй Муса, син сабый чагында бездә тәрбияләндең түгелме? Вә гомереңнең күп елларын бездә тормадыңмы? Һәм кыласы эшеңне кылдың, ягъни бер кыбтыйны үтердең, син минем биргән нигъмәтемне инкяр итүчесең». Муса әйтте: «Ул эшне мин эшләдем, ләкин шәригатьне белмәвем сәбәпле мин адашкан идем. Сездән куркып качтым вә Раббым миңа шәригать хөкемнәрен бирде вә мине расүлләрдән кылды. Син миңа миннәт иткән нигъмәт, ул шундый нигъмәттер, Бәнү Исраил балаларын үзеңә кол ясавың». Фиргавен әйтте: «Галәмнәрне тәрбия итүче ул нинди зат?». Муса әйтте: «Ул җирне, күкләрне һәм алар арасында булган нәрсәләрне тәрбия итүче, әгәр бу хак сүзгә ышансаң». Фиргавен Мусаның сүзенә ышанмаган хәлдә үзенең тирәсендәге дусларына: «Әллә ишетмисезме Мусаның сүзләрен?», — дип әйтте. Муса әйтте: «Ул — Аллаһ, сезнең Раббыгыз вә әүвәлге ataларыгызның Раббысы». Фиргавен әйтте: «Сезгә расүл итеп җибәрелгән Муса, әлбәттә, мәҗнүн». Муса әйтте: «Ул — Аллаһ, мәшрыйк-мәгърибнең һәм алар арасындагы нәрсәләрнең Раббысы, әгәр акыл йөртсәгез». Фиргавен әйтте: «Әгәр син миннән башканы «иләһ» тотсаң, мин сине төрмәгә бикләүчеләрдән булырмын». Муса**

**әйтте: «Әгәр пәйгамбәрлегемә ачык дәлилләр китерсәм дә ул эшне эшләрсеңме?». Фиргавен әйтте: «Әгәр дөрес пәйгамбәр булсаң, дәлилеңне китер». Муса таягын җиргә ташлады, шуннан соң ул еланга әверелде. Вә кулын кесәсеннән чыгарды, карауچыларга күзне чагылдырырлык ак булып чыкты. Фиргавен аксөякләренә: «Бу Муса, барыгыздан да остарак сихерче. Үзенең сихере белән сезне Мисыр җиреннән чыгарырга тели. Миңа нинди әмер бирәсез, шуны кылырмын», — диде. Аксөякләре әйтте: «Мусаны вә кардәше Һарунны бикләп куй вә сихерчеләрне чакырырга кешеләр җибәр. Алар сиңа Мусадан да остарак сихерчеләрне алып килсеннәр». Билгеләнгән вакытка сихерчеләр җыелдылар. Кешеләргә әйтелде: «Җыелдыгызмы ике якның кылган эшләрен карарга? Әгәр сихерчеләр Мусаны җиңсәләр, шаять, сихерчеләргә иярербез».** (Шүгарә: 18 – 40)

Шулай итеп, Фиргавен Муса галәйһиссәламне кешеләр алдында мәсхәрә итмәкче булып, аңа могҗиза күрсәтергә кушты. Муса галәйһиссәлам таягын җиргә ташлады һәм таяк Аллаһ кодрәте белән еланга әверелде һәм сихерчеләрнең кеше күзенә елан булып тоелган таякларын ашап бетерде. Кешеләр бу хәлне күреп куркып калдылар, ә Фиргавен курыкканын сиздермәс өчен, Мусага тизрәк тагын берәр могҗиза күрсәтергә кушты. Чөнки, кадерле балалар, әгәр дә кешеләр Фиргавеннең курыкканын сизеп калсалар, аның «иләһ» түгеллеген, бәлки шарлатан вә залим икәнен белерләр иде. Муса галәйһиссәлам

икенче могҗиза итеп кулын кесәсенә тыкты. Аннан чыгаруга, аның кулы якты булып нур сибә иде. Кешеләр Муса галәйһиссәламнең пәйгамбәр икәнлегенә инандылар, әмма Фиргавен аларга: «Муса сихерче», — дип, үзенең көферлеген белдерде. Фиргавеннең Мусага каршы җыйган сихерчеләре иман китереп сәҗдә кылдылар. Чөнки бу могҗизалардан соң, Муса галәйһиссәламнең Аллаһ тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр икәнлегенә аларда һичбер шик калмады.

Фиргавен үзенең гаскәренә Муса галәйһиссәламне һәм аңа ияргән барысын да каты газапларга дип, әмер бирде. Мусаны үтерергә әмер бирелгәч, үзенең мөэмин икәнлеген яшергән әли-Фиргавен кавеменнән бер кеше: «Сез кешене, минем Раббым — Аллаһ дигәне өчен үтерәсезме?», — дип каршы чыкты.


Бу хакта Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Фиргавен кавеменә: «Мусаны үтерергә миңа комачауламагыз, котылырга дип Раббысына дога кылсын, чөнки мин куркамын сезнең динегезне бетереп, үзенең диненә алыштыруыннан, яки бозыклык кылуыннан куркамын», — дип әйтте. Муса әйтте: «Кыямәт көненә ышанмаган һәр тәкәбберләнүче явызлыгыннан, минем һәм сезнең Раббыгыз булган Аллаһка сыгынамын». Фиргавен ыруыннан булган иманын яшерүче бер мөэмин ир әйтте: «Сез кешене, «Минем Раббым — Аллаһ», — дигәне өчен үтерәсезме? Ул Муса сезгә Раббыгыздан ачык аңлатмалар илә килде, әгәр ялган сөйләсә зарары үзенә булыр, әгәр сөйләгән сүзләре хак булса, сезгә вәгъдә иткән дөнья газабы, әлбәттә, ирешер. Әлбәттә, Аллаһ хакны инкяр**

**итүче чиктән үткән фасикъны туры юлга салмас».** (Гафир: 26 – 28)

Фиргавеннең мәкерлеге турында Аллаһ тәгалә Муса галәйһиссәламгә белгертте һәм иман китергән барча кешеләрне ияртеп, аңа Фәләстыйн (Палестина) җиренә юнәлергә боерды. Муса عليه السلام Бәнү Исраил кавеменнән аңа иман китергән барча кешеләрне җыеп, Мисырдан чыгып, Фәләстыйн җиренә юнәлде. Аларның артларыннан Фиргавен гаскәре белән куа чыкты. Алар шулай Фиргавеннән качып барган рәвештә, каршыларына диңгез очрады. Инде нишләргә? Алда диңгез, ә артта,үзенең гаскәре белән Фиргавен куып килә?

Шул вакыт, Муса галәйһиссәлам ярдәм сорап Раббысына ялварды. Аллаһ Муса галәйһиссәламгә таягы белән диңгезгә сугарга кушты. Ул Раббысының әмеренә буйсынып, таягы белән диңгезгә сукты. Ни күрсеннәр! Диңгез, Аллаһ тәгаләнең кодрәте белән икегә аерылып, коры юл пәйда булды. Муса галәйһиссәлам үзенә ияргән Бәнү Исраил кавеме белән диңгезнең икенче ягына чыкты. Артларыннан Фиргавен гаскәре белән куа кергәч, Аллаһ тәгалә аларның өсләренә диңгезне каплады һәм алар барчасыда су астында калып батып үлделәр.


Газиз балалар! Менә шулай Аллаһ тәгалә Аңа вә расүленә буйсынмаган залим кәферләрне җәза кыла. Ә Аллаһка һәм Аның расүленә итагать иткән мөэминнәргә, Ул Сөбханәһү вә тәгалә җиңеллек бирә вә бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирештерә.




Бу харита да кара ук белән күрсәтелгәне Муса г.с.нең Мәдйәнгә барып кире Мисырга кайткан юлы. Кызыл ук белән күрсәтелгәне Муса г.с.нең кавеме белән бергә Мисырдан Фәләстыйндагы Җәлгадка барган юлы билгеләнгән. Су икегә аерылып Фиргавеннән качкан күл — ул «Әче Күл». Хәзерге көндә бу күл аша Сүәеш (Суэц) каналы уза. Аллаһу әгъләм


Муса һәм Хозырның күрешүе
Ике диңгез кушылган җир.
Муса галәйһиссәлам үзенең егетенә әйтте: «Әлбәттә, туктамыйча китәрмен ике диңгезнең кушылган җиренә барып җиткәнче, яки туктамыйча озын заман китәрмен» Кәһеф 60.
Испания
Әндәлус
Гибралтар бугазы
Рабат
Марокко
Алжир
Алжир
Тунис
Италия
Триполи
Урта диңгез
Искәндәрия
Каһирә
Синай чүле
Әйләт
Мәдйән
Мисыр
Кызыл диңгез
Ливия
Нил елгасы
Сахара
Судан
Хартум
Зәңгәр Нил

Без Муса илә Һарунга хак белән батыл арасын аеручы китап вә белем бирдек, һәм Аллаһудан куркучы тәкъваләргә ул китапны вәгазь итеп бирдек. Алар Аллаһны күрмичә күргән кебек Аннан куркалар, вә алар кыяматтән дә тетрәп куркучылардыр.




Муса һәм Һарун галәйһиссәламнәрнең нәсәбе

Муса галәйһиссәлам турындагы кыйссабыз менә шулай тәмам булды. Аллаһ тәгалә безгә бу кыйссадан ике дөньяда да файда китерүче гыйбрәтләр алырга насыйп итсен.

Икенче пәйгамбәр тарихында очрашканга кадәр, балалар, сау булыгыз! Әссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Кыйссадан алырга мөмкин булган файдалар:

**1)** – Фиргавен Мисыр җирендә кешеләр өстеннән золымлык вә тәкәбберлек белән патшлалык итте һәм үзен «иләһ» дип кешеләрне җәберли иде.

**2)** – Муса галәйһиссәлам Фиргавеннең сараенда тәрбияләнде.

**3)** – Аллаһ тәгалә кечкенә Муса галәйһиссәламне яңадан әнисенә кайтарды.

**4)** – Фиргавеннең хатыны кечкенә Мусаны яратты һәм аны йортта калдыру өчен, ире Фиргавен белән киңәшләште.

**5)** – Изге хатын — изге гамәлләрдә ярдәмче вә киңәшче.

**6)** – Сабырлык вә канәгатьлек җиңеллеккә вә яхшы нәтиҗәләргә китерә.

**7)** – Муса галәйһиссәлам залим Фиргавеннән качып Мисыр җиреннән чыгып китте.

**8)** – Муса галәйһиссәлам Шөгайб кызларының малларына су эчереп, хәерле эш күрсәтте.

**9)** – Муса галәйһиссәлам Шөгайбнең кызына өйләнеп вәгъдә ителгән вакытны уздыргач, Фиргавенне Аллаһка гыйбадәт кылыр өчен дәгъват итәргә дип, Мисырга юнәлде.

**10)** – Аллаһ тәгалә Муса галәйһиссәлам белән Тур тавында сөйләште.

**11)** – Фиргавен Муса галәйһиссәламнең иманга чакыру дәгъватен кире какты.

**12)** – Аллаһ тәгалә Муса галәйһиссәламне бик күп могҗизалар белән нигъмәтләде.

**13)** – Аллаһ тәгалә диңгезне икегә аерып, Муса галәйһиссәлам һәм аңа иман китергән Бәнү Исраил кавемен коткарды, ә Фиргавен вә аның гаскәрен суга батырып һәлак итте.

**14)** – Муса галәйһиссәламгә биргән могҗизалар сәбәбендә, Аллаһ тәгаләнең кодрәтен күреп, Фиргавеннең сихерчеләре иман китерделәр.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Муса галәйһиссәлам кайда тәрбияләнеп үсте?

**2)** – Муса галәйһиссәламне елгадан кем табып алды?

**3)** – Мусаның табылуына кем шатланды?

**4)** – Муса галәйһиссәламнең әнисе баласын үлемнән ничек коткарды?

**5)** – Фиргавен ни өчен барча ир балаларны үтерә иде?

Буш урыннарга тиешле сүзләрне куй:

Аллаһ тәгалә .................... галәйһиссәламне көч-куәт белән нигъмәтләде. Ул .............. кавеменнән булган бер кешене .......................... Фиргавен ..................... булган кешегә ............ күтәрде. Шул сәбәпле ................ чыгып ............... юнәлде. Муса анда ............ кызына өйләнде һәм аңарда ............. ел уздырды.

Дөрес җөмләләргә ( √ ) ошбу билгене, ә хаталы җөмләләргә ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Аллаһның ярдәме белән Муса галәйһиссәлам Фиргавеннең явызлыгыннан котылды ( )

**2)** – Муса галәйһиссәламнең Фиргавен сараенда тәрбияләнеп үсүе, аны йомшак вә әдәпле итте ( )

**3)** – Муса галәйһиссәламнең әнисе баласын бик нык яратканлыктан һәм аны югалтудан куркып, елгага ыргытты ( )

**4)** – Муса галәйһиссәламне тәрбияче хатыннар имезеп үстергәнлектән, ул бик таза вә көчле булып үсте ( )

Дөрес җавапны күрсәт:

**1)** – Муса галәйһиссәламнең таягы еланга әйләнгәч, сихерчеләр иман китерделәр:

а) еланнан курыкканга.

б) Фиргавенгә нәфрәтләре көчле булганга.

в) бу хәлнең сихер булмыйча, Аллаһ тарафыннан Муса галәйһиссәламгә бирелгән могҗиза икәнлеген белгәнгә.

**2)** – Муса галәйһиссәлам кавеме белән Мисырдан качып чыгып киткәч:

а) Фиргавен аларның һәммасен дә куып тотып үтерде.

б) Муса галәйһиссәламнән башкалар барчасы да суга батып үлде.

в) Аллаһның кодрәте белән диңгез икегә аерылды һәм алар икенче якка чыгып котылдылар.

**3)** – Аллаһ тәгалә Муса галәйһиссәлам белән:

а) Мәккәдә сөйләште.

б) Тур тавында сөйләште.

в) Мәдйән җирендә сөйләште.

г) Мисыр җирендә сөйләште.

# Һарун ﷺ

Әйтеп узганча, газиз балалар, Аллаһ тәгалә Муса галәйһиссәлам белән Синай җирендәге Тур тавында сөйләшкәч һәм аның пәйгамбәр икәнлеген белгертеп, Мисыр җиренә залим, тәкәббер, бозыклык таратучы Фиргавенгә барып, аны бер Аллаһка гыйбадәт кылырга чакырырга кушкач, Муса галәйһиссәлам Раббысыннан, үзе белән бергә Һарун галәйһиссәламне дә җибәрүен сорады. Аллаһ тәгалә Һарун галәйһиссәламне Муса галәйһиссәлам белән Фиргавенгә пәйгамбәр итеп җибәрде.

Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Кардәшем Һарун миннән яхшырак сөйли, аны миңа ярдәмче вә куәтләндерүче итеп җибәр, югыйсә мин аларның мине ялганга тотуларыннан куркамын». Аллаһ әйтте: «Әлбәттә, кардәшең белән сине куәтләрбез һәм сезне өстен кылырбыз, алар сезгә ирешә алмаслар. Сез икегез һәм сезгә ияргән мөэминнәр могҗизаларыбыз илә аларны җиңәчәксез».** (Касас: 34 – 35)

Һарун галәйһиссәлам бик күркәм сөйләп кешеләрнең йөрәкләрен, күңелләрен җәлеп итә иде. Ул Фиргавен белән дә бик йомшак итеп сөйләште һәм аны бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырды. Әмма Фиргавен Һарун галәйһиссәламнең сүзләрен кире

какты. Һәм гаскәре белән Фәләстыйнга (Палестина) юнәлгән Муса һәм Һарун галәйһиссәламнәрне вә аларга иман китереп ияргән Бәнү Исраил кавеменнән булган барча кешеләрне үтерергә дип, артларыннан куа чыкты. Аллаһ тәгалә Фиргавенне гаскәре белән суга батырды. Муса һәм Һарун галәйһиссәламнәргә иман китергән Бәнү Исраил кавеменнән булган кешеләрне коткарды.

Менә шулай, газиз балалар! Җир йөзендә бозыклык таратучыларны бу дөньяда да, ахирәттә дә каты газап көтә.

Муса галәйһиссәлам Тур тавына киткәч, Һарун галәйһиссәламне Бәнү Исраил кавеменә нәсыйхәтче итеп калдырды. Бу хакта Коръәндә болай әйтелде (мәгънәсе) : **«Мусаны Тур тавында утыз кич вә утыз көн тотмак белән вәгъдә кылдык вә ул утыз көнне янә ун көн кушып тәмам иттек, Раббысының вәгъдәсе кырык кичтә тәмам булды. Муса Тур тавына киткәндә кардәше Һарунга әйтте: «Кавемем арасында минем урынымда кал һәм аларның эшләрен төзек кыл вә бозыклык кылучылар юлына кермә!».** (Әгъраф: 142)

Шулай итеп, балалар, Муса галәйһиссәлам Тур тавына китте. Аның урынына калган Һарун галәйһиссәлам кешеләрне иманга, Аллаһка гыйбадәт кылырга һәм ширектән ерак булырга нәсыйхәт кыла иде. Ләкин, ул Бәнү Исраил кавеме Һарун галәйһиссәламнән ераклашып, башка юл белән адашып китте. Сәмирий ясаган алтын бозауга табына башлап, бик каты адашты.

Муса галәйһиссәлам кире кайткач, гөнаһларын танып Аллаһка сыгындылар. Муса галәйһиссәлам үзенә вә Һарунга гафу сорап, Раббысына ялварды һәм башкаларны да Үзенең рәхмәтенә алуын сорады. Бу күренешне Аллаһ тәгалә Коръәндә болай тасвирлый (мәгънәсе): **«Муса тауга киткәч, кавеме алтын-көмештән бозау ясадылар, ул бозауның тавышы бар иде, бозау шулай ясалган иде — аңа җил кереп, эченнән тавыш чыга иде. Әйе, алар күрмиләрме, бозау алар белән сөйләшми һәм аларны туры юлга күндерергә дә көче җитми. Гаҗәп, һичнәрсәгә ярамаган нәрсәне «иләһ» тоттылар һәм шуның өчен залим булдылар. Алар эшләгәннәре өчен үкенеп һәм шиксез адашканлыкларын белгәч, әйттеләр: «Әгәр безгә Раббыбыз рәхмәт кылмаса һәм гөнаһларыбызны ярлыкамаса, әлбәттә, һәлак булучылардан булырбыз!». Муса кавеме янына ачу вә кайгы белән кайткач әйтте: «Мин киткәч нинди кабахәт эш эшләгәнсез! Раббыгызның эшендә ашыктыгызмы? Аллаһ вәгъдә кылган кырык көнне көтәргә күпсендегезме?». Вә ачуыннан кулындагы Тәүрат такталарын ташлады һәм кардәше Һарун галәйһиссәламнең сакалыннан тотып үзенә тартты. Һарун әйтте: «Әй анам улы кардәшем! Тәхкыйк, бу кавем мине зәгыйфькә санады һәм бозау ясауларыннан тыйганым өчен мине үтерә башладылар, минем өчен дошманнарны шатландырма вә мине залим кавемнәр җөмләсеннән санама!». Муса әйтте: «Йә Раббым! Мине вә кардәшем Һарунны ярлыка вә безне рәхмәтеңә кергез! Син рәхим кылучыларның иң**

**рәхимлесесең!». Бозауны «иләһ» урынына тотучыларга дөньяда Аллаһның ачуы вә хурлыгы иреште. Әнә шулай җәза кылачакбыз Аллаһның тиңдәше бар, дип, ифтира кылучыларны. Бозык эшләрне эшләүчеләр, тәүбә итеп гамәл кылу нияте белән Коръәнгә иман китерсәләр, шуның соңында Раббың, әлбәттә, ярлыкаучы, рәхимле».** (Әгъраф: 148 – 153)

Һарун галәйһиссәлам вафат булганчыга кадәр бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыруын дәвам итте. Ул бу изгелектә, Муса галәйһиссәлам белән бергә булды.

Менә шулай итеп, газиз балалар, Һарун галәйһиссәлам хакындагы хикәябез тәмам. Аллаһ тәгалә бу кыйссадан файдалы гыйбрәтләр алырга насыйп итсен. Хакыйкатьтә, Ул кодрәт иясе. Киләсе пәйгамбәр тормышында очрашканга кадәр, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Кыйссадан алырга мөмкин булган файдалар:

**1)** – Һарун عليه السلام пәйгамбәрләрдән иде. Аны Аллаһ тәгалә Муса галәйһиссәлам белән бергә Фиргавенне бер Аллаһка гыйбадәт кылырга чакырыр өчен җибәрде.

**2)** – Һарун عليه السلام күңелләргә үтеп керәрлек бик матур, сөйкемле әдәби тел белән сөйләшә торган иде.

**3)** – Залим Фиргавен Һарун галәйһиссәламнең бер Аллаһка гыйбадәт кылуга чакыруын кире какты.

**4)** – Муса галәйһиссәлам Тур тавына киткәндә, Һарун галәйһиссәламне Бәнү Исраил кавеменә нәсыйхәтче итеп калдырды.

**5)** – Һарун галәйһиссәламнең кавеме бик каты адашып бозауга табына башлады.

**6)** – Һарунның عليه السلام кавеме зур гөнаһ эшләгәннәре өчен бик нык үкенделәр.

**7)** – Алар үзләренең хаталарын танығач, Муса عليه السلام аларга ярлыкау сорап, Раббысына ялварды.

**8)** – Пәйгамбәрләргә итагать итү — бу дөньяда да, ахирәттә дә уңышка илтә.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Муса عليه السلام белән бергә Фиргавенгә дәгъват кылырга кем барды?

**2)** – Һарун عليه السلام нәрсә белән мәшһүр иде?

**3)** – Һарунның عليه السلام кавеме нәрсәгә табындылар?

**4)** – Муса عليه السلام кайткач Һарунның عليه السلام кавеме ни эшләде?

**5)** – Мусаның عليه السلام ул кавемгә ярлыкау сорап Раббысына ялваруы нәрсәне аңлата?

Дөрес җөмләләргә ( √ ) ошбу билгене, ә хаталы җөмләләргә ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Һарун عليه السلام Нух عليه السلام белән бергә Фиргавенгә җибәрелде (  )

**2)** – Муса عليه السلام киткәч ул кавем Һарунга буйсынды һәм бозауга табынмадылар (  )

**3)** – Муса عليه السلام Тур тавында 99 көн калды (  )

**4)** – Ихлас тәүбә иткәннәрнең тәүбәсен Аллаһ кабул итә (  )

**5)** – Мөселман кеше пәйгамбәрләргә иярә һәм аларга итагать итә (  )

# Давыд عليه السلام

Бәнү Исраил кавеме җир йөзендә бозыклык таратуларын дәвам итүдән хәзерге көнгә кадәр туктамады.

Алар кылган бозыклыклар шул кадәр чикне узды ки, хәтта Аллаһ тәгалә аларга һидәять юлын күрсәтергә җибәргән пәйгамбәрләрне дә үтерә торган булдылар. Аларның шундый көферлек кылганнары өчен, Муса белән Һарун галәйһиссәламнәр вафат булгач, Аллаһ тәгалә Бәнү Исраил кавемен бик каты золымлык белән җәберли торган патшалар булдырды.

Бәнү Исраил кавеменең дошманнары, аларны үтерер өчен барча форсаттан файдаланалар иде. Һәм шулай сугышларның берсендә Бәнү Исраил кавеме бик зур җиңелүгә дучар булды. Балалары үтерелеп, башка бик күп әйберләре белән бергә Муса галәйһиссәламгә вәхи булып иңгән Тәүратның язмаларын саклый торган табутны да югалттылар.

Аларны кайгы артыннан кайгы көтеп кенә торды. Бигрәк тә табутны югалтулары Бәнү Исраилне бөтенләй төшенкелеккә һәм кайгыга салды. Чөнки алар моның белән үзләренең тормышларын дөрес юлдан алып баручы хөкемчене югалттылар һәм диңгез төбендәге кебек караңгылыкта калдылар. Ә ул диңгез катлам-катлам дулкын сулар белән капланып, нур яктысы керерлек түгел иде.

Шушы авырлыклардан чыгу юлын эзләп, алар пәйгамбәрләрнең берсенә мөраҗәгать иттеләр. Аңа: «Әгәр дә безгә Аллаһ юлында сугышыр өчен берәр патша билгеләсәң, без аңа ияреп сугышыр идек», — диделәр. Аллаһ тәгалә аларның соравына Талут исемле берәүне патша кылуы хакында хәбәр бирде. Бер төркем байлар Талутның фәкыйрьләрдән икәнен белгәч, үзләре сугышта безгә җитәкче кирәк дип сораган булсаларда, без аннан хаклырак дип, аның алар өстеннән җитәкчелеген инкяр иттеләр.

Бу хакта Аллаһ тәгалә «Бәкара» сүрәсендә болай диде (мәгънәсе): **«Муса пәйгамбәрдән соң Бәнү Исраилдән бер җәмәгатьнең хәлен белдеңме? Алар үзләренең пәйгамбәренә әйттеләр: «Безгә патша билгелә, без аңа буйсынып Аллаһ юлында кәферләр белән сугышыр идек», — дип. Ул әйтте: «Әгәр сезгә сугыш фарыз ителсә, ихтимал сугышмассыз, карышырсыз». Алар әйттеләр: «Безгә ни булган Аллаһ юлында сугышмаска? Чөнки без шул кәферләр тарафыннан йортларыбыздан чыгарылдык һәм балаларыбыздан аерылдык, әлбәттә, алар белән сугышабыз». Ә инде кайчан аларга кәферләр белән сугышу фарыз ителде, алар сугыштан баш тарттылар, мәгәр бик азлары баш тартмады, гайрәт белән сугыштылар. Аллаһ сугыштан баш тарткан залимнәрне белә. Пәйгамбәрләре әйтте: «Аллаһ сезгә Талутны патша кылды». Алар пәйгамбәргә әйттеләр: «Кайда инде ул Талутка безнең өстән патша булу, патша булу өчен без хаклырак, чөнки Талутка малдан байлык бирелмәгән» (Ләкин Талут ярлы**

**булса да акыллы һәм көчле иде). Пәйгамбәрләре әйтте: «Аллаһ сезгә Талутны патшалыкка ихтыяр кылды, дәхи аны белемдә һәм көчтә сездән артык кылды. Аллаһ үзенең байлыгын теләгән бәндәсенә бирер, Аллаһ киңлек һәм белем иясе». Пәйгамбәрләре әйтте: «Талутның Аллаһтан билгеләнгән патша икәнлегенә дәлил булып бер сандык килер, аның эчендә күңелләрегез тынычлык табардай нәрсәләр булыр һәм Муса белән Һарунның гаиләләре калдырган башка нәрсәләр булыр, ул сандыкны фәрештәләр алып килер. Аллаһтан сезгә бу сандыкның килүендә шиксез Талутның патша икәнлегенә галәмәт бар, әгәр бу галәмәтнең Аллаһтан булуына ышансагыз».** (Бәкара: 246 – 248)

Бәнү Исраил кавеме Талут белән риза булгач, Аллаһ тәгалә аларга көч-куәт бирде һәм алар табутны кире кайтардылар. Бу менә ничек булды, кадерле балалар:

Ул сугышта дошманнарның көче шактый зур иде. Алар белән Җәлут исемле тәкәббер, кәфер патша җитәкчелек итте. Талут үзенең гаскәре белән дошманнарга каршы чыкты. Юлда аның сугышчылары бик сусадылар һәм бу хакта җитәкчеләренә хәбәр иттеләр. Талут аларга: «Аллаһ тәгалә сезне елга белән сынаячак, кем дә кем аннан эчсә, ул минем белән булмас, ә кем инде аннан эчмәсә яки учы белән эз генә алса, алар минем белән булыр», — диде.

Шулай итеп алар елга буена җиткәч, сугышчыларның күбесе сусауга түзә алмыйча елгадан су эчтеләр вә шуның белән Талутның гаскәреннән төшеп кал-

дылар. Бик азы гына сабырлык күрсәтеп су эчмичә, яки учлары белән әз генә алып эчеп, җитәкчеләренә итагать белгерттеләр һәм Талутка тугры булып калдылар.

Инде, балалар, Талут гаскәре Җәлут гаскәре белән сугыш мәйданы буенда очраштылар. Белгәнебезчә Талут гаскәре мөселманнардан булып, сугышчлыр саны да бик аз иде. Ә Җәлут гаскәре кәферләрдән булып, аның сугышчылары да искиткеч күп иделәр. Кәферләрнең күплеген күреп Талут гаскәрендәге кайберәүләр: «Безнең бүген Җәлутка вә аның гаскәренә көчебез җитмәячәк, чөнки алар шактый күп, ә без бик аз», — дип төшенкелеккә төштеләр. Шул вакыт аларга иманнары көчле булганнары: «Күпме кечкенә төркем Аллаһның теләге белән зур төркемнәрне җиңде, Аллаһ сабыр итүчеләр белән», — диделәр.

Талут гаскәрендә пәйгамбәрләрдән булган Давыд галәйһиссәлам дә бар иде. Ләкин, ул бу вакытта яшь иде һәм пәйгамбәрлек вазыйфасы белән йөкләнмәгән иде әле.

Талут белән Җәлут гаскәрләре сугыш мәйданы буенда туктап калдылар. Җәлут гәүдәгә бик көчле булып үзенең көчен күрсәтер өчен, сугыш алдыннан бергә-бер көрәшкә дип Талут гаскәреннән берәрсенең аңа каршы чыгуын сорады. Җәлутның шундый таза, көчле икәнлеген күреп барысы да куркып калдылар. Аңа каршы Давыд عليه السلام чыкты. Әйтүебезчә, Давыд галәйһиссәлам ул вакытта яшь һәм пәйгамбәрлеге билгеле түгел иде.

Шулай итеп, кадерле балалар, Давыд عليه السلام үзенең яшьлегенә карамыйча, залим Җәлутка каршы бергәбер көрәшкә чыкты. Җәлут аның кечкенә вә яшь булуыннан көлеп: «Бар кире кайт, син кечкенә, зәгыйфь, шуңа күрә мин синең белән көрәшергә, сине үтерергә теләмим», — диде.

Балалар! Давыд галәйһиссәлам кечкенә булса да, аның иманы көчле иде һәм ул Җәлутка: «Мин кирегә чигенмим һәм сине Аллаһ ярдәме белән үтерәчәкмен», — дип җавап бирде. Һәм коралы белән Җәлутка шундый итеп elәктерде ки, Җәлут шунда ук җан-тәслим кылып җиргә ауды.

Бу күренеш хакында Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Талут гаскәр белән шәһәрдән чыгып сәфәргә киткәндә, гаскәргә әйтте: «Аллаһ сезне бер елга белән сыный, мин әйткәнчә эш кылыгыз, шул елгадан су эчкән кеше миндә түгел, миннән аерылып калыр, фәкать су эчмәгән кеше генә минем белән сугышка барыр, яки учы белән алып бер мәртәбә генә эчкән кеше миңа юлдаш булыр». Әмма күбесе елгадан туйганчы эчтеләр, мәгәр бик азлары гына эчмәде. Талут һәм аның белән бергә су эчмичә калган мөэминнәр шул елганы үтеп киткәч, мөэминнәр арасыннан кайберләре әйтте: «Кәфер гаскәренә безнең көчебез җитмәс, Җәлутка һәм аның гаскәренә каршы тора алмабыз, чөнки аларның саны бик күп, әмма безнең санының бик аз». Ахирәттә Аллаһка юлыгачакларын белгән галим мөэминнәр әйттеләр: «Күп вакытта, аз санда булган мөэминнәр, Аллаһ ярдәме белән, күп санда булган кәферләрне җиңделәр**

**түгелме? Шулай булгач, без дә күп санда булган кәферләрдән курыкмыйча, Аллаһ ярдәменә таянып сугышыйк. Аллаһ тәгалә сугышларда батырлык күрсәткән сабыр мөэминнәр белән бергә». Мөэминнәр Җәлутка һәм аның гаскәренә якын килгәч әйттеләр: «Әй Раббыбыз, безгә сабырлык, батырлык бир һәм аякларыбызны ныклы кыл һәм кәфер кавемен җиңәргә ярдәм бир». Аллаһ ярдәме белән аз санда булган мөэминнәр гаскәре, күп санда булган кәфер гаскәрен җиңделәр һәм Давыд, кәферләрнең башлыгы — Җәлутны үтерде. Аллаһ Давыдка байлык һәм пәйгамбәрлек бирде һәм аңа Үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтте. Әгәр Аллаһ кешеләрне якламаса иде, әлбәттә, җирдәге кешеләр һәммәсе һәлак булыр иделәр. Ләкин Аллаһ барча галәмнәр мәхлугына рәхмәт иясе. Бу сөйләнгән кыйссалар Аллаһның аятьләре. Әй Мөхәммәд галәйһиссәлам! Аны сиңа хаклык белән укыйбыз, әлбәттә, син расүлләрдән».** (Бәкара: 249 – 252)

Давыд галәйһиссәлам Җәлутны үтергәч, аны башкалар шатланып каршыладылар. Беркадәр вакыттан соң Давыд عليه السلام Бәнү Исраил кавеменә патша булып, гаделлек белән хөкем итә башлады. Аллаһ тәгалә аны пәйгамбәрләрдән кылып, Зәбур китабын иңдерде. Бу хакта Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Һәм Без Давыдка Зәбурны бирдек».** (Нисә: 163)

Шулай ук, Аллаһ тәгаләнең Давыдка عليه السلام биргән нигъмәтләреннән — ул Раббысын бөекләп, пакьләп тәсбих кылса, аңа кушылып таулар һәм кошлар тәсбих әйтә торган булды.

Бу хакта Коръәндә болай диелде (мәгънәсе): **«Әй Мөхәммәд ﷺ, аларның үз зарарларына сөйләгән сүзләренә сабыр ит! Безнең колыбыз Давыд-ны сөйлә, ул гыйбадәттә куәт иясе иде, көн аша ураза тотып, гыйбадәт кылыр иде вә һәр мәкруһ эшләрдән тәүбә итеп, Аллаһка кайтучы. Без Давыд пәйгамбәргә зикердә тауларны иярттек, аның илә бергә иртә вә кич тәсбих әйтерләр иде. Вә кошларны да зикердә аңа иярттек, һәммәсе аның янына җыелып тәсбих әйтерләр иде. Без аның хакимиятен гаскәр вә сакчылар илә куәтләдек вә шәригать хөкемнәрен бирдек һәм сүздә ачык сөйләүне, ягъни батылдан аралап, хак сүзне сөйләүне бирдек».** (Сад: 17 – 20)

Давыд галәйһиссәлам Раббысына шөкер итүче һәм күп гыйбадәт кылучы булды. Аллаһ аңа, шулай ук, тимерчелек һөнәрен белгертте һәм ул тимердән сугышта саклану кораллары вә җиһазлары ясый торган иде. Аллаһ үзе яраткан бәндәсенә нәрсәне булса да буйсындырырга теләсә, буйсындыра. Чөнки Ул — һәрнәрсәгә кодрәте җитүче. Аллаһ Коръәндә болай дип әйтте (мәгънәсе): **«Вә Давыдка сезнең өчен сугыш киемнәрен ясарга өйрәттек, ул киемнәр белән сезне кылыч зарарыннан сакламак өчен. Ә сез шуның өчен шөкер итәсезме?».** (Пәйгамбәрләр: 80)

Әйтүебезчә, Давыд галәйһиссәлам Аллаһ биргән нигъмәтләргә, көч-куәткә карамастан, кешеләргә карата золымлык күрсәтмәде, тәкәбберләнмәде, киресенчә тагын да күбрәк шөкерана-гыйбадәт кылып, араларны гаделлек белән хөкем итте. Әгәр

хөкем итүдә ялгышканлыгын сизсә, шул ук вакытта Раббысыннан ярлыкау сорый торган булды. Аның шундый икәнлегенә, газиз балалар, бер мисал китереп узарга мөмкин.

Көннәрдән бер көнне, ул үзенең гыйбадәт йортына гыйбадәт кылырга дип кергәч, аның янына көтмәгәндә ике кеше килеп керде. Давыд галәйһиссәлам аларны көтмәгән булганлыктан сискәнеп, куркып калды. Алар аңа: «Курыкма, без синең яныңа гадел хөкем итүеңне эстәп килдек», — диделәр. Һәм берсе дәвам итеп: «Әй Давыд, бу минем туганым, аның 99 сарыгы бар һәм ул минем бердәнбер сарыгымны золым кылып алды да, үзенекен 100гә тутырды», — диде. Давыд галәйһиссәлам икенчесен тыңлап та тормыйча, беренчесенә: «Ул синең сарыгыңны алып, сиңа золым кылган», — дип араларын хөкем итте.

Алар киткәч, Давыд галәйһиссәлам, Раббысы аны сынаганын вә кисәткәнен аңлады һәм тиз арада Раббысына ялварып гафу сорады, тәүбә итте. Аллаһ тәгалә аны гафу итте.


Давыд галәйһиссәлам белән булган бу күренешне Аллаһ тәгалә Коръәндә болай тасвирлый (мәгънәсе): **«Әй Мөхәммәд галәйһиссәлам, сиңа ике дәгъвачының Давыд янына хөкем иттерергә килгән хәбәрләре ирештеме? Алар килеп гыйбадәт йортының эченә рөхсәтсез үттеләр. Алар Давыд янына кергәч, Давыд عليه السلام бу кешеләр кайдан керделәр дип, куркып калды, алар әйттеләр: «Син бездән курыкма, без ике дәгъвачы, беребез икенчебезгә золым итмештер, арабызны хаклык илә хөкем ит, безгә золым итмә һәм бу эшебездә**


**безне туры юлга сал! Аларның берсе әйтте: «Менә бу иптәшем, диндә минем кардәшемдер, аның туксан тугыз сарыгы бар, минем исә бер генә сарыгым бар, шул бер сарыгыңны миңа бир, дип, минем илә низаг кылды вә сүзендә мине җиңде, минем ни әйтергә дә хәлем калмады». Давыд әйтте: «Туксан тугыз сарыгы була торып синең бер сарыгыңны сорап, сиңа золым иткән. Уртаклык илә эш кылучылар, әлбәттә, бер-берсенә золым итәрләр, мәгәр иман китереп, изге гамәлләр кылган мөэминнәр золым итмәсләр, ләкин андый кешеләр аздыр». Давыд эшне аңлады, бу икәүнең аны сынар өчен һәм тәнбиһ итәр өчен килгәннәрен белде, Раббысыннан гафу сорады вә сәҗдәгә китте һәм тәүбә итте. Ярлыканырга теләгән хатасын гафу иттек вә Кыямәт көнендә Безгә якын булыр һәм аңа күркәм урын бар. Әй Давыд! Без сине җир өстендә хәлифә кылдык, кешеләр арасында хаклык илә хөкем ит, нәфес һавасынә иярмә, әгәр иярсәң, ул нәфес сине Аллаһ юлыннан адаштырыр. Бит Кыямәт көнне булачак хисапны онытып, Аллаһ тәгаләә юлыннан адашканнарга — каты газап».** (Сад: 21 – 26)

Давыд галәйһиссәламнең бик яраткан, Сөләймән исемле улы бар иде. Ул аны намазга, уразага һәм Зәбурда күрсәтелгән башка төрле гыйбадәтләргә өйрәтеп, тәрбияләп үстерде.

Шулай Давыд галәйһиссәлам кешеләр арасында гаделлек таратып, аларны бер Аллаһка гыйбадәт кылырга, яхшылыкка өндәргә вә начарлыктан тыелырга чакырды. Күпмедер еллар узып, үзенең өстенә

йөкләнгән пәйгамбәрлек вазыйфасын тиешлечә үтәп вафат булганнан соң, бу вазыйфаны Аллаһ тәгалә Сөләймән галәйһиссәламгә йөкләде.




Сөләйман галәйһиссәлам
Рахабгам
Давыд галәйһиссәлам
Ишә
Гөбәйд
Бугаз
Сәлмүн
Хашун
Гаминә Дәб
Ирам
Хасрун
Фәрис
Яһүзә
Исхак галәйһиссәлам
Ибраһим галәйһиссәлам
Дауд һәм Сөләйман галәйһиссәламнәрнең нәсәбе

Менә шушында инде, балалар, Давыд галәйһиссәлам белән бәйле кыйссабызны тәмамлыйбыз. Сез бу кыйссадан бик күп файдалар алгансыздыр дип өмет итеп, киләсе пәйгамбәрнең тормыш юлына сәяхәт башлаганчыга кадәр саубуллашабыз. Вәссәламу галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Бәнү Исраил кавеме хәзерге көннәргә кадәр җир йөзендә фәсәд, бозыклык тараталар.

**2)** – Бәнү Исраил кавеме пәйгамбәрләрне үтерүләре белән билгеле булдылар.

**3)** – Талут Бәнү Исраилгә патша булып, аларны сугышларга җитәкләде.

**4)** – Давыд عليه السلام Җәлутны үтергәннән соң, Бәнү Исраилгә патша булды һәм Аллаһ тарафыннан аларга пәйгамбәр итеп җибәрелде.

**5)** – Давыд عليه السلام Раббысын пакьләп тәсбих кылганда, Аллаһ тәгалә аның тәсбихына тауларны һәм кошларны да кушылдырта иде.

**6)** – Аллаһ тәгалә Давыд галәйһиссәламгә күпме генә нигъмәт бирсә дә, ул тәкәбберләнмичә Раббысына тиешлечә гыйбадәт вә шөкер кыла иде.

**7)** – Давыд галәйһиссәлам үзенең улы Сөләйманне иман тәрбиясе белән тәрбияләп үстерде.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Җәлутны кем үтерде?

**2)** – Давыд галәйһиссәламгә кадәр Бәнү Исраил кавеменең хәле ничек иде?

**3)** – Аллаһ тәгалә Давыд галәйһиссәламгә нинди нигъмәтләр бирде?

**4)** – Аллаһ тәгалә Давыт галәйһиссәламне нинди вазыйфа белән йөкләде? Һәм нәрсәгә өндәргә әмер итте?

Дөрес җөмләләргә ( √ ) ошбу билгене, ә хата җөмләләргә ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Бәнү Исраил кавеме хәзерге көнгә кадәр җир йөзендә фәсәд һәм бозыклык кылалар ( )

**2)** – Бәнү Исраил кавеме пәйгамбәрләрне үтерү белән мәшһүр булды ( )

**3)** – Талут Җәлутны сөңге белән кадап үтерде ( )

**4)** – Сөләймән عليه السلام Талут йортында тәрбияләнеп үсте ( )

# Сөләймән عليه السلام

Сөләймән عليه السلام Давыдның عليه السلام улы иде. Аллаһ тәгалә аны пәйгамбәрләрдән кылып, Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылуга чакыру белән йөкләде. Раббул-Гыйззә аңа кошлар һәм барча хайваннар телен белгертте һәм шулай ук җеннәрне аңа буйсындырып, аларны аның гаскәре вә хезмәтчеләреннән кылды.

Аллаһ тәгалә аңа шундый көч-кодрәт биргәнлеген белеп, кешеләр дә, җеннәр дә Сөләймән галәйһиссәламгә буйсыналар иде. Раббысы тарафыннан шундый нигъмәтләр бирелүенә карамастан, ул тәкәбберләнмичә, берәүне дә золым кылмыйча, бер Аллаһка гына гыйбадәткә чакыра бирде.

Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Давыдка вә улы Сөләйманга хикмәтле белем бирдек вә алар әйттеләр: «Безне дәрәҗәдә мөэминнәрнең күбрәгеннән артык кылучы Аллаһка — мактау хас». Сөләймән атасы Давыдка пәйгамбәрлектә һәм патшалыкта варис булды вә әйтте: «Әй кешеләр, мин кошлар белән сөйләшергә өйрәтелдем һәм пәйгамбәрлеккә вә патшалыкка бирелә торган нәрсәләр, бар да миңа бирелде, бу нәрсәләр, әлбәттә, башкаларга бирелгәннән ачык артык. Сөләймән гаскәренә җыелырга әмер бирде, кешеләр, җеннәр вә кош-**

**лардан булган гаскәре җыелдылар һәм барысы да туктап калдылар».** (Нәмел: 15 – 17)

Сөләймән галәйһиссәлам Раббысыннан ярлыкау сорады һәм Аңардан, үзе вафат булганнан соң, башка һичкемдә дә булмаслык, зур патшалык бирүен теләде. Аллаһ тәгалә Сөләйманнең догасына җавап итеп, аңа искиткеч зур мөлкәт, патшалык бирде. Аңа җеннәр генә түгел, хәтта җилләр дә буйсынып теләгән үти торган булдылар. Болар һәммәсе дә, кадерле балалар, бер Аллаһның кодрәтендә, чөнки Ул берәр нәрсәнең булуын теләсә: «Бул!», — ди, һәм ул нәрсә шунда ук була. Раббыбыз Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Аллаһ бер нәрсәнең бар булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать, «Бар бул!», — дип, әйтер һәм ул нәрсә бар булыр. Барча нәрсәгә хуҗалык Аның кулында булган Аллаһ һәр кимчелектән пакь вә Аңа кайтарылырсыз».** (Йәсин: 82 — 83)

Кадерле нәниләрем! Без Аллаһка хак иман белән ышанырга һәм Аның безгә биргән нигъмәтләренә шөкарана итәргә тиешбез. Шул вакытта, Ул безгә тагын да арттырып бирә, чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә әйтте (мәгънәсе): **«Дәхи Раббыгыз сезгә белдерде: «Әгәр дә сез шөкарана итсәгез, Мин сезгә арттырып бирермен, әгәр дә көферлек кылсагыз, Минем газабым бик каты булачак».** (Ибраһим: 7)

Кем дә кем Аллаһның нигъмәтләренә шөкер итсә, Ул аңа арттырып бирә, ә кем канәгатьсезлек белдерсә, ул нигъмәтләргә көферлек кылса, аны Аллаһ тәгаләнең каты вә ачы газабы көтә.

Балалар! Сөләймән галәйһиссәламнең шөкерана кылучылардан булганлыгына түбәндәге мисалны әйтеп узырга мөмкин. Көннәрдән бер көнне, ул үзенең гаскәре белән барганда бер кырмысканы очратты. Ул кырмыска башка кырмыскалар өчен борчылып: «Әй кырмыскалар! Йортларыгызга кереп качыгыз, югыйсә Сөләймән үзенең гаскәре белән сезне күрмичә таптап-сытып китәчәк, чөнки без алар каршында кечкенәләрбез», — дип калганнарны кисәтте. Сөләймән галәйһиссәлам моны ишетеп елмайды һәм: «Әй Раббым, үземә һәм ата-анама биргән нигъмәтләреңә шөкерана кылмакка миңа илһам бир», — диде.

Әйе, балалар, Сөләймән галәйһиссәлам Раббысы риза булырлык изге гамәлләр кылыр өчен Аннан ярдәм, көч-куәт сорады. Аны изге бәндәләрдән кылып Үзенең рәхмәтенә алуын теләде. Бу күренеш хакында Аллаһ тәгалә Коръәндә менә ничек әйтә, газизләрем (мәгънәсе): **«Сәфәрләрендә бер кырмыска чокырына җиткәндә, кырмыскаларның патшасы Сөләймән гаскәрен күреп әйтте: «Әй кырмаскалар, Сөләймән гаскәре белән килә, тапталырсыз, алар сезнең тапталганыгызны сизмәсләр, өйләрегезгә кереп качыгыз», – дип. Сөләймән кырмысканың сүзеннән елмаеп көлде һәм әйтте: «Әй Раббым, үземә вә атаанама биргән нигъмәтләреңә шөкер итмәккә миңа илһам бир, дәхи Син риза була торган изге гамәлләр кылырга ярдәм бир, һәм рәхмәтең белән мине изге бәндәләрең арасына керт!».** (Нәмел: 18 – 19)

Сөләймән галәйһиссәлам үзенең патшалыгында булган һәркем, һәрнәрсә өчен борчыла иде. Чөнки ул барча пәйгамбәрләр кебек үк аңа Раббысы йөкләгән һәрнәрсәгә җаваплы иде.

Газизләрем! Күп кенә патшалар, түрәләр үзләренең карамагында булган кешеләр һәм башкалар өчен борчылмыйча фәкать корсакларын, кесәләрен, нәфселәрен генә кайгырта торган булсалар, пәйгамбәрләр һәм Аллаһның изге бәндәләре башкалар хакында борчыла торган булдылар. Әгәр дә кемнедер җәберләсәләр яки ашарына-эчәренә булмаса, тизрәк ул кешегәме, җәнлек-хайвангамы, кош-корткамы ярдәм кулы сузырга ашыктылар.

Көннәрдән бер көнне, Сөләймән галәйһиссәлам үзенең патшалыгында һүдһүд кошын югалтты. Һүдһүднең кайдалыгына җавап ишетмәгәч, ачуланды һәм: «Әгәр дә кайткач ни сәбәпле югалып торганын аңлата алмаса, мин аны каты җәзага тарттырырмын», — диде.

Һүдһүд кайткач Сөләймән аннан: «Син кайда булдың?», — дип сорады. Һүдһүд аңа: «Мин син белми торган Йәмән җирендә, Сәбә шәһәрендә булдым, анда Бәлкыйс исемле хатын-кыз патшалык итә, ул үзе дә вә аның патшалыгы карамагында булганнар да Бер Аллаһка гыйбадәт кылмыйча, кояшка табыналар һәм аның алтын, якут вә мәрҗәннәрдән бизәлгән бик матур тәхете бар», — диде. Сөләймән галәйһиссәлам: «Мин аңа хат җибәрермен һәм синең шунда дөресме, әллә ялганмы сөйләгәнеңне белермен», — диде.

Бу күренешне Аллаһ тәгалә Коръәндә болай сурәтли, кадерлеләрем (мәгънәсе): **«Сөләймән шул арада һүдһүд кошын югалтты һәм әйтте: «Миңа ни булды, һүдһүд кошын күрмимен, яки ул югалып киттеме?». Сөләймән һүдһүдкә ачуланды: «Сорамый киткәне өчен, мин аны, әлбәттә, бик каты газап кылырмын, яки бугазлармын, китүенә гозер күрсәтмәсә», — диде. Аз гына вакыт үткәч, һүдһүд Сөләймән янына килде вә әйтте: «Әй патшам, мин ерак җиргә барып син белмәгәнне белдем вә Сәбә шәһәреннән сиңа хак булган яңа хәбәр белән килдем. Мин Бәлкыйс исемле бер хатын патшаны таптым вә ул хатынга патшаларга бирелә торган һәрнәрсә бирелгән, дәхи аның зиннәтләнгән бер зур тәхете бар. Вә ул хатынны һәм кавемен Аллаһтан башка кояшка сәҗдә кылучылардан таптым, шәйтан аларга кояшка табынуларын яхшы эш итеп күрсәткән, шәйтан аларны хак дингә керүдән тыйды, инде алар хак юлга күнелмәсләр». Янә һүдһүд: «Җиргә яңгырны кушып төрле ризыклар чыгаручы Аллаһка гыйбадәт кылмаска нәрсә булган? Янә Ул — Аллаһ, күңелләрегездәге яшерен уйларыгызны һәм телләрегез сөйләгән сүзләрегезне белә. Ул Аллаһтан башка илаһ юк, мәгәр Ул гына вә Ул олуг Гәрешнең Раббысы», — дип әйтте. Сөләймән әйтте: «Әй һүдһүд, карарбыз, китергән хәбәрең дөресме яки ялганчылардан булдыңмы?». (Сөләймән Бәлкыйскә хат язып һүдһүдкә бирде). «Минә бу хатымны алып барып алларына сал, соңра читкәрәк китеп карап тор, ничек җавап бирерләр».** (Нәмел: 20 – 28)

Сөләймән галәйһиссәлам хат язып һүдһүд аша Бәлкыйскә җибәргәч, Бәлкыйс киңәшләшер өчен вәзирләрен җыйды һәм: «Миңа ни эшләргә икән?», — дип, вәзирләреннән сорады. Вәзирләре: «Әгәр син Сөләймән белән сугышырга телисең икән, без әзер, безнең көчебез җитәрлек, ләкин үзең карар кыл», — дип җавап бирделәр. Бәлкыйс аларга: «Без аның ни кадәр көчкуәтле булганнын белмибез. Солтаннар бер урынга сугыш белән керсәләр, җиңелгәннәрнең патшаларын, түрәләрен түбәнсетәләр, кимсетәләр, шуңа да мин аның көч-куәтен белер өчен сезне Сөләймәнгә бүләкләр белән җибәрәм һәм сез анда аның патшалыгының куәтен белеп кайтырсыз», — диде.

Бәлкыйснең илчеләре бүләкләр белән Сөләймән галәйһиссәламгә килгәч, аның патшалыгының никадәр зур вә көчле икәнлеген күреп аптырадылар. Сөләймән галәйһиссәлам аларга: «Барыгыз, бүләкләрегезне алып кире китегез, сезнең шатлана торган бүләкләрегезгә караганда Аллаһ тәгаләнең миңа биргән нигъмәте һичшиксез хәерлерәк. Әллә мин шуларны алып, сезнең көферлектә калуыгызга риза булырмын дип уйлыйсызмы? Юк, сез бик нык ялгышасыз. Кайтып барчасына да җиткерегез, әгәр дә сез миңа мөселман булып килмәсәгез, мин сезгә шундый гаскәр белән килермен, сез аңа каршы тора алмассыз һәм сезнең барыгызны да түбәнсетеп, хур итеп, ул җирдән чыгарырлар», — диде.

Бу вакыйга турында, кечкенәләрем, Коръәндә менә ничек әйтелде (мәгънәсе): **«Бәлкыйс хатны алгач әйтте: «Әй җәмәгать, миңа бер яхшы**

хат ташланмыш булды. Ул хат Сөләйманнән вә ул хатта: «Рахмән, рәхимле булган Аллаһ исеме белән әйтәмен. Миңа тәкәбберлек итмәгез, итагать иткәнегез хәлдә миңа килегез», — дип язылган диде. Бәлкыйс янә үзенең якындагыларына әйтте: «Әй җәмәгать, ошбу эш хосусында нинди киңәшегез вә хәйләгез бар миңа әйтегез, мин бер эш хакында да карар чыгармыйм, илләмәгәр сезнең белән бергә киңәшләшкәч кенә карар чыгарамын». Бәлкыйснең ярдәмчеләре әйттеләр: «Без куәт ияләребез вә сугышта каты батырлык ияләребез, шулай булса да эш сиңа тапшырылмыш, уйлап кара — сугышыргамы яки килешергәме, ни әйтсәң, без әзербез, сүзеңнән чыкмыйбыз». Бәлкыйс әйтте: «Әгәр патшалар бер шәһәргә һөҗүм белән керсәләр, ул шәһәрне җимерәләр һәм хөрмәтле олуг кешеләрен иң түбән вә хур итеп калдыралар, патшалар әнә шулай кылырлар. Мин Сөләйманга бүләкләр белән илчеләр җибәрәмен, соңра карармын, илчеләр нәрсә белән кайтырлар, минем бүләгемне кабул итеп алырлармы, юкмы?». Илчеләр бүләкләре белән Сөләйман хозурына килгәч, Сөләйман әйтте: «Миңа мал белән ярдәм итәсезме? Аллаһның миңа биргәне сезгә биргән малдан хәерлерәк, бәлки сез ошбу бүләкләрегез белән үзегез мактанырсыз». Бүләкләр алып килгән илчегә Сөләйман әйтте: «Бар, бүләкләреңне алып кайтып Бәлкыйскә тапшыр, без әлбәттә, аларга гаскәр белән барабыз, безнең гаскәребезгә каршы торырга аларның көче булмас, без аларны Сәбә шәһәреннән хур итеп

**чыгарырбыз һәм алар түбәнсенгән хәлдә булырлар». Илче Сөләймән әйткән сүзләрне Бәлкыйскә кайтып ирештерде».** (Нәмел: 29 – 37)

Сөләймән галәйһиссәлам Бәлкыйснең вә кавеменең аның янына итагать итеп килүен белгәч, аңа буйсынган һәрнәрсә Аллаһ тәгаләнең кодрәте белән икәнлеген Бәлкыйскә аңлатыр өчен, ул үзенең янындагы җеннәргә вә кешеләргә: «Кайсыгыз Бәлкыйс үзе килгәнче миңа аның тәхетен алып килеп куя?», — диде. Җеннәрдән бер көчлесе: «Син урыныңнан торганчы мин аны алып киләм», — дип белгертте. Ә Аллаһ китабын яхшы белгән икенче бер зат: «Син күз ачып йомганчы, мин ул тәхетне китереп куя алам», — диде. Һәм шул мизгел эчендә Бәлкыйснең тәхете Сөләймән галәйһиссәламнең күз алдына китереп куелды.

Кадерле вә газиз нәниләрем! Аллаһ тәгаләнең кодрәтенә бу гаҗәп түгел, чөнки Раббыбызның кодрәтенең иге-чиге юк, нәрсә теләсә шул була. Сөләймән галәйһиссәлам Бәлкыйскә шуны бәян итәргә һәм мөэминнәргә Аның рәхмәте булачагын аңлатырга теләде.

Бәлкыйснең тәхете Сөләймән галәйһиссәламнең күз алдында пәйда булгач, ул Аллаһның чиксез булган нигъмәтенә шөкерана йөзеннән сәҗдә кылды.

Бәлкыйстән: «Бу синең тәхетеңме?», — дип сорады. Бәлкыйс үзенең Йәмәндә калган тәхете ничек Фәләстыйнга шул арада килүенә гаҗәпләнеп: «Әйе, бу минем тәхетем булса кирәк», — дип ышаныр-ышанмас җавап бирде.

Тагын бер гаҗәеп хәл Бәлкыйсне көтә иде, балалар. Сөләймән галәйһиссәлам сарайның идәннәрен пыяладан ясатып, астыннан су ага торган итәргә боерды. Бәлкыйс сарайга кергәч суга басам дип күлмәген күтәрә төшкәч, Сөләймән галәйһиссәлам: «Курыкма! Син пыяла идәннән барасың, киемең юешләнмәс, су аның астында», — дип тынычландырды. Бәлкыйс: «Әй Раббым, хакыйкатьтә, мин үземә золым кылганмын, инде Сөләймән белән бергә галәмнәрнең Раббысы Аллаһка иман китердем», — дип, мөэмин-мөселман булды. Шунда Сөләймән галәйһиссәламнең, Бәлкыйсне вә аның кавемен иманга китерергә теләгән уе, хакыйкатькә чыкты.

Балалар! Инде бу хакта Коръәндә ничек әйтелгәнен тыңлыйк (мәгънәсе): **«Сөләймән әйтте: «Әй җәмәгать, Бәлкыйснең тәхетен миңа кем китерә, алар минем яныма мөселман булып килгәннәренә чаклы? Чөнки кәфер хәлләрендә аларның нәрсәсен алырга дөрес, әмма мөселман булгач алырга дөрес булмый. Җен таифәсеннән көчле вә куәтле булганы әйтте: «Син утырган урыныңнан торганчы мин ул тәхетне алып килермен, ул тәхетне сәламәт хәлендә алып килергә мин, әлбәттә, кадирмын». Аллаһ китабын яхшы белгән бер зат: «Син күз ачып йомганчы мин аны сиңа алып килермен», — диде. Сөләймән тәхетне алдында күргәч, әйтте: «Бу тәхетнең шулай тиз килүе Раббымның фазылыннандыр, шөкер итәрме яки көферлек кылырмы дип, мине сынар өчендер. Берәү шөкер итсә — үзе өчен шөкер итә вә берәү нигъмәткә көферлек итсә, тәхкыйк, Раббым бай-**

**дыр, аның шөкер итүенә мохтаҗ түгел». Сөләймән әйтте: «Тәхетнең тышкы күренешен үзгәртегез, карарбыз, Бәлкыйс үзенең тәхетен танырмы яки танымаучылардан булырмы?». Бәлкыйс Сөләймән янына килгәч, аңа әйтелде: «Бу синең тәхетеңме? Бәлкыйс әйтте: «Бу тәхет минем тәхеткә ошаган, минем тәхетем булса кирәк», — диде. Сөләймән Бәлкыйстән гаҗәпсенеп һәм Аллаһка шөкерана кылып әйтте: «Ошбу хәлдән элек безгә һидәять, гакыл бирелеп, без иман китереп мөселман булган идек». Сөләймән Бәлкыйсне Аллаһтан башка кояшка гыйбадәт кылудан тыйды, чөнки Бәлкыйс элек кәферләр кавеменнән иде. Бәлкыйскә Сөләймән тарафыннан пыяла сарайга кер, дип әйтелде. Бәлкыйс сарайга кергәндә пыяланы сизмәде, суга керәм дип уйлады һәм күлмәген күтәрә төште. Аннары Сөләймән әйтте: «Син уйлаганча су түгел, бәлки су өстендә ялтыравыклы пыяладан ясалган идән». Бәлкыйс: «Әй Раббым, кояшка табынып үземә золым иттем, инде барча галәмне тәрбия итүче Аллаһка Сөләймән белән бергә иман китереп мөселман булдым», — диде».** (Нәмел: 38 – 44)

Сөләймән галәйһиссәлам бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыруын ахыргы көненә кадәр дәвам итте. Шулай ук, җеннәрнең яшерен гыйлемне белмәүләре хакында кешеләргә бәян итәр өчен көннәрнең берендә Раббысыннан үзенең үлемен җеннәрдән яшерүне теләп, дога кылды. Аллаһ тәгалә аның догасын кабул итте һәм Сөләймән галәйһиссәлам таягына таянып баскан килеш ва-


фат булды. Ул шулай басып торгач аның үлүен җеннәр белмәделәр. Күпмедер вакытлар узгач Аллаһ Сөләймән галәйһиссәламнең үлүе турында кешеләргә вә җеннәргә белгертергә теләде һәм агач кортын җибәрде. Ул агач корты Сөләймән галәйһиссәлам таянып торган таякны ашап сындырды һәм Сөләймән галәйһиссәлам җиргә ауды. Менә шул вакытта гына аның үлгәнлеге башкаларга билгеле булды. Бу хәл кешеләргә җеннәрнең яшерен гыйлемне белмәгәннәрен бәян кылды. Шулай ук, яшерен гыйлемне бары тик Бер Аллаһ тәгалә Үзе генә белүче икәнен исбат итте.

Әйдәгез әле матурларым, бу күренеш хакында Коръән аятьләрендә ни әйтелгәнен карыйк (мәгънәсе): **«Без Давыд пәйгамбәргә үз юмартлыгыбыздан башка кешеләргә караганда артыклыкны бирдек, Аллаһ әйтте: «Әй таулар һәм кошлар, Давыд белән бергә тәсбихләр әйтегез». Без аның кулында тимерне йомшак кылдык. «Әй Давыд, Ислам гаскәрләренә тимердән сугыш киемнәрен яса вә ул киемнәрне һәрбер ирнең тәненә яраклаштырып яса һәм һәммәләрегез дә изге гамәлләр кылыгыз вә яхшы эшләрне эшләгез! Әлбәттә, Мин сезнең кылган эшләрегезне күрүчемен». Вә Без Сөләйманга җилне буйсындырдык, ул җил белән көннең әүвәленнән зәвалгә кадәр бер айлык юлны вә зәвалдән соң көннең ахырына кадәр бер айлык юлны китәр иде вә Без аңа эрегән бакыр чишмәсен буйсындырдык вә җеннәр Раббыларының әмере буенча Сөләйманга хезмәт итәр булдылар. Әгәр ул җеннәрдән бер-**

**се, Без әйткәнчә Сөләйманга итагать итмәсә, Без аңа ут газабын татытырбыз. Ул җеннәр Сөләйман теләгәнчә бөек-бөек өйләр ясый иделәр вә сурәтләр ясар иделәр, дәхи өй зурлыгында табак, тас һәм аяклы казаннар ясый иделәр. Әй Давыд балалары! Аллаһның нигъмәтләренә шөкер итеп Аңа итагать итегез! Биргән нигъмәтләргә, чынлап шөкер итүче кешеләр, бәндәләребездән аздыр. Сөләйманнең Без билгеләгән гомере беткәч, басып торганы хәлдә җанын алдык, аның үлгәнен Аллаһ җеннәргә дә, кешеләргә дә белдермәде, мәгәр үлгән хәлдә таянып торган таягын кортлар ашап өзгәч, ул җиргә егылды, шул вакытта, аның үлгәнен кешеләр дә, җеннәр дә белделәр, әгәр җеннәр яшерен нәрсәне белә торган булсалар, әлбәттә, Сөләйманнең үлгәнен белер иделәр һәм аның үлгәнен белгән булсалар, әлбәттә, авыр эштә бер ел буена эшләп ятмаслар иде. (Чөнки Сөләйман үлгәч таягына таянып бер ел торды, җеннәр: «Сөләйман безгә карап тора», — дип, һаман эшләделәр, егылгач кына: «Котылдык», — дип, качтылар)».** (Сәбә: 10 – 14)

Аллаһ Сөбханәһү вә тәгалә ошбу кыйссадан да файдалы гыйлемнәр алып тормышыбызда кулланырга, Раббыбызга изге гамәлләребез белән якынаерга насыйп итсен. Әмин!

Газизләрем! Сөләйманнең عليه السلام тормышына кагылган хикәябезне шушында тәмамларбыз, киләсе пәйгамбәрнең тормыш сахифәләренә сәяхәт иткәнче, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!



Литани елгасы
Димәшкъ
Тир
Урта диңгез
Хәүрән
Хайфа
Тиверия
Иордан елгасы
Фалыстын
Яффә
Амман
Гәскалан
Әл-Кудс
(Иерусалим)
Газа
Үле диңгез
Әл-Хәлил
(Хеврон)
Бир-әс-Сәбг
Сәдүм
Негев чүле
Сөләйман
галәйһиссәлам
Кече Азия
Бәлкыйсның юлы
Урта
диңгез
Кудус
(Иерусалим)
Гарәп ярымутравы
Фарсылар
Мисыр
Сәбә
Судан
Йәмән

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Сөләймән عليه السلام изге, салих бәндәләрдән иде һәм Аллаһ тәгалә аны әтисе Давыд галәйһиссәламнән соң пәйгамбәрлек вазыйфасы белән йөкләде.

**2)** – Аллаһ тәгалә Сөләйманга عليه السلام кош-корт, хайваннар телен белгертте вә аңа җеннәрне буйсындырды.

**3)** – Сөләймән عليه السلام Раббысыннан ярлыкау вә үзеннән соң беркемдә дә булмаслык патшалык, мөлкәт сорады.

**4)** – Сөләймән عليه السلام Раббысының биргән нигъмәтенә шөкерана итеп, тагын да күбрәк гыйбадәттә булды.

**5)** – Иман — дөньяда булган барча байлыклардан да хәерлерәк.

**6)** – Сөләймән عليه السلام Раббысы биргән нигъмәтләргә изге гамәлләр кылып шөкерана кылыр өчен, Аннан көч-куәт сорады.

**7)** – Хәзерге вакытта, үзләре һәм үзләренең балалары хакында гына кайгырган бик күп патшаларга караганда, Сөләймән عليه السلام үзенең патшалыгында булган һәр җан иясе өчен борчыла иде.

**8)** – Бәлкыйс һәм аның кавеме Сөләйманнең عليه السلام һүдһүд аша җибәргән хаты сәбәпле Исламны кабул итте.

**9)** – Аллаһ тәгалә Сөләйманнең عليه السلام үлүен җеннәрдән яшерү хикмәте — кешеләргә, җеннәрнең яшерен гыйлемне белмәүләрен тагы бер кат исбатлау иде.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Давыд галәйһиссәламнән соң пәйгамбәр булып кем килде?

**2)** – Сөләймән عليه السلام Раббысыннан нәрсә сорады?

**3)** – Пәйгамбәрләр нәрсәгә чакырдылар?

**4)** – Кырмыска Сөләйманнең عليه السلام гаскәрен күргәч, башка кырмыскаларга нәрсә әйтте?

**5)** – Сөләймән галәйһиссәлам үзенең патшалыгыннан нинди кошны югалтты?

**6)** – Ул кош кайткач, үзенең югалып тору сәбәбен ничек аңлатты?

**7)** – Сөләймән галәйһиссәлам һүдһүдкә нәрсә дип җавап бирде?

**8)** – Сөләймән عليه السلام Раббысы биргән нигъмәтне инкяр иттеме?

**9)** – Бәлкыйс ни сәбәпле иман китерде?

**10)** – Җеннәр яшерен гыйлемне беләме? Моны ничек аңлатасың?

Дөрес җөмләләргә ( √ ) ошбу билгене, ә хаталы җөмләләргә ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Сөләймән عليه السلام Нухтан соң пәйгамбәр булып килде ( )

**2)** – Аллаһ тәгалә Мусага барча нәрсәләрне буйсындырды ( )

**3)** – Барча пәйгамбәрләр дә бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырдылар ( )

**4)** – Сөләйманнең عليه السلام әтисе Гыйсә галәйһиссәлам иде ( )

**5)** – Һүдһүд Сөләйманнән булган хатны Бәлкыйскә илтте ( )

**6)** – Кырмыска Сөләймән عليه السلام гаскәреннән курыкмады ( )

**7)** – Аллаһ тәгалә кодрәтенең иге-чиге юк ( )

**8)** – Җеннәр вә кешеләр Аллаһ тәгаләнең мәхлуклары ( )

# Юныс ﻋﻠﻴﻪ ﺍﻟﺴﻼﻡ

Юныс галәйһиссәлам пәйгамбәр итеп җибәрелгән кавем Гыйрак җирендәге Мусал янындагы Найнава шәһәрендә яши торган иде. Ул кавем дә башка кавемнәр кебек үк агачтан вә таштан потлар ясап табына торган булдылар. Чөнки алар: «Безгә бу потлар ярдәм итә, авырсак шифа бирә», — дип уйлыйлар иде.

Белгәнегезчә, балалар, бу һәммәсе дә шәйтан вәсвәсәсе генә. Һәм без беләбез ки, ризыкны да, шифаны да Бер Аллаһ кына бирә вә Ул гына һәрнәрсәгә кадир, ни теләсә шул була.

Менә шул кавем, нәниләр, Аллаһтан ераклашып үзләре ясаган курчакларга, һәйкәлләргә табына башлаулары белән бик куркыныч адашуга, җәһилияткә чумдылар.

Аллаһның Адәм баласына булган чиксез рәхмәтеннән, Ул аларга туры юлны күрсәтүче итеп Юныс галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрде.

Юныс галәйһиссәлам кавеменә туры-хак юлны аңлатып, Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыра башлады. Аларның ясаган потлары зыян да, файда да китерә аламганлыгын һәм эшләгән гамәлләре Җәһәннәмгә керүгә сәбәп икәнлеген аңлатты. Әмма аның кавеме бу үгет-нәсыйхәтләргә колак салмады.

Шулай ук Юныс галәйһиссәлам аларга әүвәлге — Нух, Һуд, Салих кавемнәренең ничек һәлак булганнарын исләренә төшереп, аларны шул хәлгә төшүләре белән кисәтте.

Юныс галәйһиссәлам кавеменә ничек кенә аңлатырга тырышмасын, алар аны кире генә кактылар. Шәйтан шул тиклем аларны адаштырды ки, хәтта Юныс галәйһиссәлам аларга: «Әгәр дә сез иманга килмәсәгез, Аллаһ сезгә каты газап җибәрер», — дип кисәткәч, алар аңа: «Без сиңа ышанмыйбыз һәм ата-бабаларыбыз гыйбадәт кылган әйберләрне ташламыйбыз, әгәр син безгә газап килә дип куркытасың икән, әйдә җибәр ул газапны, газапла безне!», — дип, көфер сүзләре белән җавап бирделәр.

Юныс галәйһиссәлам аларга төрле юллар белән аңлатырга тырышты. Әмма ул кавем ата-бабаларының гыйбадәтен ташлауга караганда, Аллаһ тәгаләнең газабы безгә җиңелерәк дип уйладылар.

Кавеменең иман китермәгәннәренә Юныс галәйһиссәлам бик тә кайгырды һәм ул минем дәгъватем беткәндер инде дип уйлап, Раббысының әмереннән тыш, икенче җиргә дәгъват кылырга дип, Найнавадан чыгып китте.

Шәһәрдән чыгып күпмедер узгач, Аллаһ тәгалә Найнава халкына газап җибәрде. Шул вакытта алар Юныс галәйһиссәламнең сүзләре дөрес икәнлегенә ышанып, Аллаһ тәгаләдән ярлыкау сорый башладылар. Аллаһ тәгаләдән газапны туктатуын сорап дога кылсын дип, Юныс галәйһиссәламне күпме генә эзләсәләр дә, таба алмадылар. Күпмедер вакыттан

соң Аллаһ тәгаләаларга җибәргән газапны туктатты һәм алар, Юныс галәйһиссәлам кайтып аларга динне, туры юлны аңлатыр дигән өметтә калдылар.


Ләкин, Юныс галәйһиссәлам шәһәрдән чыгып байтак кына узгач, диңгез буена җитеп көймәгә утырып китте. Көймә диңгез уртасына җиткәч көчле дулкыннар күтәрелеп көймәне чайкый башлады. Кешеләр, әгәр дә көймәнең авырлыгын җиңеләйтмәсәк, ягъни көймәдән кемнедер суга ташламасак, барыбыз да батып үләчәкбез дип, шобага салдылар. Суга ташларга тиешле булып Юныс галәйһиссәлам чыкты. Кешеләр аның һәрдаим зикердә булып Аллаһ тәгаләне зурлаучы бәндә икәнен күргәннәр иде инде, шуңа да Юнысны суга ату ярамас дип, икенче тапкыр шобага салдылар. Әмма икенчесендә дә, өченчесендә дә аңарга чыкты. Һәм ничек кенә кылсалар да, аны суга ташламыйча чаралары калмады.

Шулай итеп, балалар, Юныс галәйһиссәламне диңгез уртасында суга аттылар. Тирә-якта һичкем, һичнинди ярдәмче юк иде аңа.

Шунда, нәниләр, галәмнәр Раббысының кодрәте чагылды. Аллаһ тәгалә зур балык җибәреп, ул балык Юныс галәйһиссәламне йотты. Балыкның карыны киң булып, Юныс галәйһиссәлам анда Раббысын зурлап сәҗдәләр-шөкераналар кылды. Кавеменә киләсе газапны искә алып һәм аларны тагын да иманга чакырырга кирәклеген уйлап, Аллаһтан аны кире кайтаруын сорады.

Газизләрем! Беләбез ки, Аллаһ тәгалә догаларны кабул итүче. Юныс галәйһиссәламнең дә догасын

Аллаһ тәгалә кабул кылды һәм балык карынынннан аны диңгез буена чыгарды. Аңа ял итәргә вә даваланырга дип яр буенда киң яфраклы агачны булдыртты.



Күпмедер вакыт узганнан соң, Юныс галәйһиссәлам кавеме янына юнәлде. Кавеме аны шатланып каршы алды вә алар үзләренең Аллаһ тәгаләгә иман китергәннәрен хәбәр иттеләр. Бу хәбәрне ишеткәч, Юныс галәйһиссәлам әйтеп бетергесез нык сөенде.

Инде кадерле балалар, Юныс галәйһиссәлам хакында Коръәндә ни әйтелгәнлеген тыңлап карыйк (мәгънәсе): **«Юныс галәйһиссәлам кавеменнән башка һичбер кавемнең дә, газапны күргәч кенә китергән иманнары файда бирмәде. Чөнки Юныс кавеме иман китергәч, алардан дөнья газабын бетердек вә әҗәлләре җиткәнче файдаландырдык».** (Юныс: 98)

Мәгънәсе: **«Юнысны да хәтерләгез, ачуланып кавеменнән аерылып китте, ул кавемен ташлап киткән өчен Безнең аңа хөкем булмас дип уйлады. Ул караңгыда яки балык эчендә дога кылып әйтте: «Йә Аллаһ, Синнән башка һич илаһ юк, мәгәр Син генә, Сине һәр кимчелектән пакь дип беләмен, хакыйкатьтә, мин үземә золым итүчеләрдән булдым». Аның догасын кабул иттек вә анны кайгысыннан коткардык, әнә шулай мөэминнәрне коткарабыз».** (Пәйгамбәрләр: 87 – 88)

Мәгънәсе: **«Вә хакыйкатьтә, Юныс та Безнең җибәргән пәйгамбәрләребездән. Ул иман китермәгән кавемен ташлап, кешеләр белән тулган зур көймәгә керде. Көймә авырлыктан батыр дип, шуңа кемне дә булса суга ташлап көймәне җиңеләйтергә кирәк дип, шобага салдылар. Шобага Юныска чыгып, аны диңгезгә ташладылар. Аны дәрхәл бер зур балык йотты вә ул үзен-үзе**

**шелтәләде. Әгәр Юныс күп гыйбадәт, тәсбих кылучылардан булмаган булса һәм: «Һич иләһ юктыр, мәгәр Син генә, йә Раббым, мин Сине һәр кимчелектән пакьсең дип беләм, мин, әлбәттә, үземә золым итүчеләрдән булдым», — дип әйтмәсә иде. Әлбәттә, ул балык карынында кешеләр терелеп каберләреннән кубарылган көнгә чаклы торыр иде. Без аны, берникадәр вакыт балык карынында торганнан соң, сырхау булганы хәлдә, коры вә һичнәрсә үсми торган җиргә чыгарып ташладык, ягъни Аллаһ әмере белән балык Юнысны су читенә чыгарып куйды. Вә аның янында киң яфраклы агач үстердек, ул агач аңа кояштан күләгә булды һәм ул агач янына чебен, черки, кигәвен кебекләр килмәделәр, (аның тәне җәрәхәтләнгән иде). Ул шул урында берничә көн торып, Аллаһның рәхмәте белән бик тиз сәламәтләнде. Без аны йөз меңле яки йөз меңнән артыграк кешеле шәһәргә пәйгамбәр итеп җибәрдек. Һәм бу юлы һәммәсе иман китерделәр вә Без дә аларны билгеләнгән әҗәлләренә чаклы малларыннан файдаландырдык, тыныч яшәттек».** (Саффәт: 139 – 148)

Мәгънәсе: **«Чыда Раббыңның хөкеменә һәм кәферләрнең каршылык күрсәтүләренә, балык юлдашы Юныс кебек булма. Ул Юныс балык эчендә тарлыкта Раббысына мөрәҗәгать итте, ялварды эченә кайгы тулган хәлдә. Әгәр, ул Юныска балык эчендә Раббысыннан нигъмәт ирешмәгән булса иде, әлбәттә, балык эченнән чыгарылып агачсыз вә үләнсез булган кызу сахрага хур ите-**

**леп ташланыр иде. Ул Юнысны Раббысы ихтыяр кылды, яңадан вәхи иңдереп пәйгамбәрлеген дәвам иттерде, дәхи аны изгеләрдән кылды».** (Каләм: 48 – 50)

Юныс галәйһиссәлам хакындагы кыйссабыз менә шушылай тәмам инде, нәниләрем. Бу кыйссадан алган файдалар беләи Аллаһ тәгалә безгә изге гамәлләр кылып, Аңа якынаерга насыйп итсен. Әмин!

Киләсе пәйгамбәр тормышында очрашканга кадәр, матурларым, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Бер Аллаһ тәгалә генә һәрнәрсәгә кадир, Ул гына ризыкландыручы, шифа бирүче.

**2)** – Аллаһтан башкага булган барча гыйбадәтләрне без инкяр итәргә тиешбез.

**3)** – Юныс ﷺ Гыйрактагы Мусал шәһәре янындагы Найнава да яшәде.

**4)** – Найнава халкы потлар ясап табына торган иделәр.

**5)** – Аллаһ тәгаләгә иман — йөрәкләрне вә акылларны нурландыра.

**6)** – Юныс галәйһиссәлам кавемен тәүхидкә чакырды.

**7)** – Юныс галәйһиссәламнең кавеме иманга килүне инкяр иткәч, ул аларга әүвәлге кавемнәрнең ничек һәлак булганлыгын исләренә төшерде.

**8)** – Аллаһ газап җибәргәч, Юнысның кавеме, үзләренең хаталанганнарын аңлап тәүбә кылдылар.

**9)** – Кеше Раббысын җиңеллектә дә, авырлыкта искә алырга тиеш.

**10)** – Юныс галәйһиссәлам Раббысын, балык эчендә дә зикер итүдән туктамады.

**11)** – Кешегә һәрвакыт тәүбә ишекләре ачык.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Юныс عليه السلام кавемен нәрсәгә өндәде?

**2)** – Юныс عليه السلام кавеме нәрсәләргә табына иде?

**3)** – Юныс عليه السلام ни өчен кавемен ташлап китте?

Буш урыннарга тиешле сүзләрне куй:

**1)** – Аллаһ тәгалә Юныс галәйһиссәламне Гыйрактагы ...................... шәһәре янындагы ...................... халкына ...................... итеп җибәрде.

**2)** – Юныс галәйһиссәлам .................... эчендә дә ........................... зикер итүдән туктамады.

**3)** – ................... عليه السلام кавемен .................. чакырды.

Түбәндәге күренешләрне күрсәң нәрсә эшләрсең?

**1)** – Иптәшеңнең гөнаһлы эш эшләгәнен күрсәң.

**2)** – Берәүнең гөнаһ эшләячәген күрдең, ләкин ул кеше аның гөнаһ икәнен белми.

**3)** – Берәү көферлектән чыгып исламны кабул итсә, әмма кешеләр аның көферлектә кылган гамәлләрен искә алып аны сүгәләр.

**4)** – Иптәшләреңнең берсе мәчеткә йөрергә тели, әмма башкалардан кыенсына.

# Ильяс عليه السلام

Ильяс галәйһиссәламне Аллаһ тәгалә хәзерге Ливандагы Бәгләбәк исемле җирдә яшәүче халыкка пәйгамбәр итеп җибәрде. Ул кавем үзләренә агачтан яки таштан потлар ясап, шуңа табыналар иде. Менә сез, кадерле балалар, уйлап карагыз әле — әгәр дә берәү агачтан яки таштан курчак ясап, шуны үзенең алдына куеп, аңа сәҗдә кылса, аннан ашарга яки эчәргә, бәла-казалардан саклавын сораса, ул кешене акыллы дип әйтеп булырмы?

Юк, әлбәттә. Без ул кеше «мәҗнүн» яки «дивана» дип уйлар идек. Чөнки ничек инде бер агач, яки таш кисәге сиңа ярдәм итсен? Син аны теләсәң яндырасың, телисең икән ватасың яки суга атасың, шулай бит, нәниләр!

Әгәр дә ул кеше уйлап, акыл йөртеп караса, әлбәттә файда да, зыян да итә алмаган агач-ташка табынмас иде. Менә шулай, кадерлеләрем! Потларга табынган ул кавемнәр акыл йөртмиләр иде. Чөнки уйлап карасалар, Аллаһка гыйбадәттән читләшеп, үз куллары белән ясаган нәрсәләргә сәҗдә, гыйбадәт итмәсләр иде.

Аллаһның кешегә булган зур рәхмәте, Ул шушы ялгышкан кавемнәргә туры юлны күрсәтүче пәйгамбәрләр җибәрә. Хәтта ул пәйгамбәрләр барча галәмне

юктан бар кылучы, хак гыйбадәткә лаек булган Бер Аллаһка чакырсыннар өчен.

Ильяс галәйһиссәлам дә, башка пәйгамбәрләр кебек үк шул адашкан кавемне һидәяткә чакыра башлады. Ул кавемнең иң мәшһүр, билгеле булган потларының исеме "Бәгел" дип атала торган иде. Ильяс галәйһиссәлам аларга: «Сез шул "Бәгел"гә табынып, барча мәхлукларны бар кылган, яшерен вә ачык нигъмәтләр белән нигъмәтләгән бер Раббыгызга гыйбадәт кылуны ташлыйсызмы? Ул Аллаһ сезнең вә ата-бабаларыгызның Раббысы. Сез Аңа чын ышану белән иман китереп миңа иярсәгез, Җәннәткә керерсез, ә инде иман китермичә, Аның кушканнарын үтәмәсәгез вә мине ялганга тотсагыз Җәһәннәмгә керерсез», — дип кисәтте.

Башка пәйгамбәрләр белән булган кебек үк, Ильяс галәйһиссәламне дә кавеме ялганга чыгардылар. Һәм үзләренең куллары белән ясаган потларга табынуны дәвам итеп, бер Аллаһка гына гыйбадәт кылудан баш тарттылар. Ильяс галәйһиссәлам аларны Аллаһның каты газабы киләчәге белән кисәтсә дә, алар аны тыңламадылар. Аллаһ тәгалә Ильяс галәйһиссәламнең кавеменнән иман китермәгәннәргә корылык җибәрде. Яңгырсызлыктан үләннәр корып бетте, хайваннар үлде, кешеләр ачлыктан интекте.

Алар потларыннан ярдәм сорап файдасын тапмагач, Ильяс галәйһиссәлам янына килеп: «Әй Ильяс! Раббыңнан безгә яңгыр сора әле», — дип ялындылар. Ильяс галәйһиссәлам Аллаһтан ярдәм сорады. Шуннан соң бәрәкәтле яңгыр ява башлады, уңышлар


унды, үләннәр калыкты һәм кешеләр яңадан нигъмәткә кайттылар.


Әмма, кадереле нәниләрем! Белүебезчә адәм баласы үзенең Раббысы биргән нигъмәтләргә тиешлечә шөкерана кылмый. Ильяс галәйһиссәламнең кавеме дә Раббыларын онытып көферлектә калдылар. Аллаһ тәгалә аларны бу гамәлләре өчен каты газапка тарттырып һәлак итте.

Коръәндә Ильяс галәйһиссәлам хакында болай диелде (мәгънәсе): **«Вә хакыйкатьтә, Ильяс та Аллаһ тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәрләрдән. Ул кавеменә: «Аллаһтан курыкмыйсызмы, Аңа гыйбадәт кылмыйсыз? Сезне вә һәрнәрсәне күркәм сурәттә халык кылучы Аллаһны куеп, "Бәгел" исемле сынга табынасызмы? Ул — Аллаһ, сезнең Раббыгыз вә әүвәлге бабаларыгызның Раббысы». Алар Ильясны ялганга тоттылар, шуңа Кыямәт көнендә газапта булырлар. Мәгәр Аллаһның ихласлы коллары утка кермәсләр. Без Ильяска, соңыннан килгәннәрнең телләрендә яхшы сүз калдырдык. Ул сүз Ильяска сәлам булсын димәкләредер. Гөнаһтан сакланып, изге гамәлләр кылучыларга, әнә шулай изгелек итәбез. Дөреслектә, Ильяс Безнең хак мөэмин колларыбыздан иде».** (Саффәт: 123 – 132)

Ильяс галәйһиссәлам бер Аллаһка чакырып, Аңа тиешенчә гыйбадәт иткән пәйгамбәрләрдән иде.

Менә шушында балалар, без бу кыска гына кыйссабызны тәмамларбыз. Киләсе пәйгамбәр тарихында очрашканга кадәр, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!


Ильяс галәйһиссәлам
Шам(Сурия) чүле
Шам илләре
Димәшкъ
Бәгләбәк
Җөлгад
Амман
Триполи
Литани елгасы
Тиверия
Хайфа
Үле диңгез
Әл-Кудс (Иерусалим)
Бир-әс-Сәбг
Газа
Мәдйән
Гакаба култыгы
Синай
Тур тавы
Кызыл диңгез
Сүәеш (Суэц) култыгы
Урта диңгез
Мисыр
Искәндәрия




Ильяс галәйһиссәләм-
нең нәсәбе

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Потларга табынган Бәгләбәк әһеленә туры юлны күрсәтүче итеп, Аллаһ тәгалә Ильясне пәйгамбәр итеп җибәрде.

**2)** – Кем дә кем потларга табына икән, ул кеше акылсыздыр, чөнки потлар файда да, зыян да китерә алмыйлар.

**3)** – Бер Аллаһ тәгалә генә гыйбадәт кылуга лаек.

**4)** – Кем Аллаһка иман китереп Аның кушканнарын үтәсә вә пәйгамбәрләр юлы белән барса, Аллаһ тәгалә аны Җәннәткә кертә.

**5)** – Кыямәт көне һичшиксез булыр һәм кешеләр ул көнне хисап кылыныр өчен Аллаһ каршына басырлар.

**6)** – Ильяснең عليه السلام кавеме иман китермәгәч, Аллаһ тәгалә аларга корылык җибәреп малларын вә үсемлекләрен һәлак итте һәм кешеләр ачлык белән газапланды.

**7)** – Аллаһ тәгалә Ильяс галәйһиссәламне мактап Коръәндә искә алды.

**8)** – Пәйгамбәрләргә итагать итү — ул Аллаһка итагать итү, ә аларга карышу — Аллаһка карышу.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Аллаһ тәгалә Ильясне عليه السلام кемнәргә пәйгамбәр итеп җибәрде?

**2)** – Ильяснең عليه السلام кавеме табынган мәшһүр пот ничек атала?

**3)** – Ильяс галәйһиссәлам ул кавемне нәрсәгә чакырды?

**4)** – Ильяс галәйһиссәламнең кавеме потлардан нәрсә сорады?

**5)** – Ул потлар Ильяс галәйһиссәламнең кавеменә ярдәм иттеләрме?

**6)** – Ни өчен потлар ярдәм итә алмыйлар?

**7)** – Барча гыйбадәткә кем лаеклы һәм ни өчен?

Ильяс галәйһиссәлам турында кыскача гына ун юл яз.

# Әльясәгъ عليه السلام

Әльясәгъ галәйһиссәлам Аллаһ тәгаләнең Бәнү Исраил кавеменә Ильястән соң җибәрелгән пәйгамбәрләреннән иде. Ул Ильястән соң пәйгамбәр булып килсә дә, ләкин аның (Ильяснең) сүзләрен тыңлап, бергә Аллаһка гыйбадәт кылып, бер чорда яшәде.

Ильяс галәйһиссәлам вафат булгач, Әльясәгъ галәйһиссәлам кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга өндәп, алар арасында гаделлек урнаштыра башлады. Халык аны ярата һәм хөрмәт итә иде. Әльясәгъ галәйһиссәламнең күркәм сыйфатларыннан, ул көндезе белән ураза тотып, кичләрен гыйбадәттә булды.

Аллаһ тәгалә Коръәндә Әльясәгъ галәйһиссәламнең югары дәрәҗәләрдә булуын зикер итеп болай диде (мәгънәсе): **«Дәхи Исмәгыйльне, Әльясәгъне, Юнысны вә Лутны һидәяткә салдык, үз заманаларында бөтен дөнья кешеләреннән аларны дәрәҗәдә артык кылдык».** (Әнгам: 86)

Шулай ук, Аллаһ тәгалә Әльясәгъ галәйһиссәламнең башка кешеләргә караганда, Үзенең сайланган изге бәндәләреннән икәнлеген Коръәндә әйтеп узды (мәгънәсе): **«Янә Исмәгыйль, Әльясәгъ вә Зүл-**

**Кифелләрне искә ал, аларның һәркайсы Без ихтияр иткән изгеләрдән иде».** (Сад: 48)

Әйткәнебезчә балалар, Әльясәгъ ﷺ кавемен бер Аллаһка гыйбадәт кылырга чакырды һәм бик зур тырышлык вә сабырлык күрсәтте.

Әльясәгъ галәйһиссәлам үзенә йөкләнгән пәйгамбәрлек вазыйфасын тиешенчә үтәп, ошбу дөньядан Аллаһның әмере белән китеп барды.

Гәзиз нәниләрем! Әльясәгъ пәйгамбәр хакындагы бик кыска сәяхәтебез шушында тәмам. Аллаһ тәгалә безгә бу пәйгамбәрнең тормыш юлыннан бик күп файдалар алырга насыйп итсен вә барчабызны да Фирдәвес Җәннәтләренә ирештерсен. Әмин!

Киләсе пәйгамбәрләр тарихында очрашканчыга кадәр, вәссәламү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:


**1)** – Әльясәгъ ﷺ Бәнү Исраил кавеменә җибәрелгән пәйгамбәрләрдән булды.

**2)** – Әльясәгъ ﷺ Ильяс ﷺ белән бер чорда яшәде һәм һәрвакыт аның сүзләренә итагать итеп, аның белән бергә Аллаһка гыйбадәттә булды.


**3)** – Әльясәгъ ﷺ кешеләр арасында гаделлек урнаштырды һәм Аллаһка гыйбадәт кылырга өндәде.

**4)** – Әльясәгъның ﷺ көндезләрен уразада булса, кичләрен гыйбадәт кылып уздыра торган иде.

**5)** – Аллаһ тәгалә Әльясәгъны ﷺ Үзенең иң күркәм, юмарт, саф бәндәләреннән итте.




Димәшкъ шәһәрендәге, яһүд Җүбир чиркәвеннән бер күренеш


Әльясәгъ
галәйһиссәлам
Ахтуб
Шәүтәләм
Ифраим
Йосыф
галәйһиссәлам
Ягъкуп
галәйһиссәлам
Исхак
галәйһиссәлам
Ибраһим
галәйһиссәлам
Буыны
Пәйгам
бәр
Олуг
пәйгамбәр
Әльясәгъ галәйһис-
сәламнең нәсәбе

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Аллаһ тәгалә Әльясәгъ галәйһиссәламне кемнәргә пәйгамбәр итеп җибәрде?

**2)** – Әльясәгъ галәйһиссәлам кешеләрне нәрсәгә өндәде?

**3)** – Әльясәгъ галәйһиссәлам нинди пәйгамбәр белән бер вакытта булды?

Буш урыннарга тиешле сүзләрне куй:

**1)** – Әльясәгъ галәйһиссәламне .............. тәгалә ............ кавеменә .......... итеп җибәрде.

**2)** – ...................... галәйһиссәламнең ................ сыйфатларыннан: ул көндезләрен ............ тотып, ә ................ гыйбадәттә үткәрә иде.

# Зәкәрия һәм Яхъя галәйһиссәламнәр

Бәнү Исраилдә бозыклык, золым, дошманлык күбәеп тирә-якка тарала башлады. Алар шул кадәр бозык эшләргә баттылар ки, хәтта шәйтан аларның акылларын явлап алып, ничек теләсә шулай әйләндерде. Муса галәйһиссәламгә иңгән Тәүрат китабын үзләренең нәфселәренә ничек уңай булса, шулай үзгәрттеләр. Сүзләрен боздылар, җөмләләрен алыштырдылар. Шул көферлекләре, бозыклыклары сәбәпле, Аллаһ тәгалә аларны кимсетүгә вә мескен хәлгә төшерде. Шуның белән Раббыларының ачулы каһәрләрен өсләренә алдылар.

Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде (мәгънәсе): **«Мөселманнар белән кайда гына сугыш кылсалар да, аларга түбәнчелек тамгасы орылган инде, мәгәр Ислам хөкүмәте астында булсалар, Аллаһның вә мөэминнәрнең хөкеме белән җизия түләп имин булырлар. Шулай булсалар да, алар Аллаһның ачулы каһәрен өсләренә алдылар һәм дә аларга мескенлек лязем ителде. Бу җәзалар аларга лязем ителде, Аллаһның аятьләрен инкяр иткәннәре вә пәйгамбәрләрне хаксыз үтергәннәре өчен. Аллаһның каһәрендә калулары, Аллаһка карышып, хактан батыл тарафына үтүләре сәбәпледер».** (Әли Гыймран: 112)

Шушы бозыклык һәм фәсәд таралган җирдә, балалар, Гыймран исемле, Аллаһка гыйбадәт кылучы изге бер кеше бар иде. Аның хатыны да изге, тәкъва хатыннардан булды. Аллаһның динен куәтләүче, әл-Әкъса мәчетендә хезмәт итүче баласы булуын, ул бик тә тели торган иде.

Аллаһ тәгалә аның теләкләрен тормышка ашырды һәм Гыймранның хатыны бәбигә узды. Авырлы икәнен белгәч, ул хатын болай дип әйтте (мәгънәсе): **«Гыймран хатыны Раббысына ялварып әйтте: «Әй Раббым! Мин үземнең карынымда булган баланы Сиңа нәзер иттем, миннән кабул ит, хакыйкатьтә, Син ишетүче, белүчесең».** (Әли Гыймран: 35)

Шулай көннәр узып балаларының дөньяга туу вакыты җиткәч, аның ир бала булмыйча, кыз бала икәнлеге ачыкланды. Инде ни эшләргә? Ул бит әл-Әкъса мәчетенә хезмәткә дип нәзер кылган иде, ә кыз бала ул, ир бала кебек түгел. Шуңа карамастан да Гыймранның хатыны нәзерен үтәргә карар кылды вә аны Мәрьям дип атады.

Аллаһ Коръәндә бу күренешне менә ничек тасвирлый, газиз балалар (мәгънәсе): «Гыймранның хатыны баланы тудыргач: «Әй Раббым! Мин кыз бала тудырдым», — диде. Аллаһ белүчерәктер нинди бала тудырганыңны, ә ир бала, әлбәттә кыз бала кебек түгел, мин аңа Мәрьям дип исем куштым. Әй Раббым, бу баланы вә аннан туачак балаларны рәхмәтеңнән сөрелмеш шәйтаннан саклавыңны сорыйм», — диде». (Әли Гыймран: 36)

Әтисе Гыймран үлгәч, Мәрьям ятим калды һәм имезү вакыты узгач, әнисе аны нәзерен үтәргә дип әл-Әкъса мәчетенә илтте. Мәчеттәгеләргә баланы биргәч, алар арасында Мәрьямне барысы да карарга алырга теләгәнлектән, низаг чыкты. Чөнки аның әтисен һәммәсе дә белеп, ярата торган иделәр, шуңа да әтисе хөрмәтенә барысы да изгелек эшләргә теләделәр. Шунда Зәкәрия галәйһиссәлам торып Мәрьямне үзенә алмакчы булды. Ләкин башкалар аңа каршы чыгып: «Без шобага салырга тиешбез, кемгә чыкса, шул алсын», — диделәр. Шобага салгач беренчесендә үк Зәкәрия галәйһиссәламгә чыкты. Калганнар моның белән риза булмыйча тагын шобага салдырдылар. Анысында да Зәкәрия галәйһиссәламгә чыкты. Шулай риза булмыйча берничә тапкыр шобага салдылар. Ләкин барысы да Зәкәрия галәйһиссәламгә чыккач, кешеләр теләр теләмәс кенә Мәрьямне Зәкәрия галәйһиссәлам карамагына бирергә ризалаштылар.

Зәкәрия галәйһиссәлам Мәрьямне алып үзенең кызы кебек тәрбияләп үстерде. Инде Мәрьям бераз зурая төшкәч Зәкәрия галәйһиссәлам аны мәчеткә илтте һәм анда һичкем кермәслек, Мәрьям өчен генә урын (бүлмә) әзерләде. Һәрвакыт Мәрьям мәчеткә карата булган, үзенә йөкләнгән эшләрне эшләгәч, аның өчен генә махсус булган урында Аллаһка гыйбадәт кыла иде. Зәкәрия галәйһиссәлам кайбер вакытларда Мәрьям янына кереп, аның бүлмәсендә бик күп нигъмәт-ризыклар күреп аптырый иде. Җәй көннәрендә кыш кына үсә торган ризыклар, ә кыш көннәрендә җәй генә үсә торган җиләк-җимешләрне

күреп: «Әй Мәрьям, бу ризыклар сиңа кайдан килде?», — дип сорагач, Аллаһка хак иман китереп ышанучы вә аны һәм башкаларны ризыкландыручы икәнен белгән Мәрьям: «Болар һәммәсе дә Аллаһ тәгаләдән», — дип җавап бирә иде.

Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә менә ничек әйтә, балалар (мәгънәсе): **«Мәрьямне Раббысы күркәм кабул итү белән кабул итте һәм яхшы тәрбия белән тәрбияләде һәм тәрбияләп үстермәк өчен Зәкәрия пәйгамбәргә йөкләде. Зәкәрия Мәрьям янына кайчан гына керсә дә, алдында төрле җимешләр һәм башка ризыкларны күрер иде. Бер кергәнендә: «Әй Мәрьям, бу ризыклар сиңа кайдан килә?», — дип сорады. Мәрьям әйтте: «Бу ризыклар Аллаһ тәгаләдән, Аллаһ, әлбәттә, Үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландыра».** (Әли Гыймран сүрәсе 37нче аять)

Белгәнегезчә, кадерле балалар, Гарәп ярым утравындагы кыш, Рәсәйдәге кыш кебек түгел, шулай ук андагы җәй, Рәсәй җәе кебек түгел. Кыскасы, ул Гарәп җирләрендә ел әйләнәсендә нинди дә булса җимеш җитешә.

Зәкәрия галәйһиссәлам картаеп олыгая төшкәч, үзеннән соң, бер Аллаһка дәгъват кылу туктамасын, дип Раббысына дога кылды. Белүебезчә, Бәнү Исраил кавеме бозыклыкка вә фәсәдкә чумганнар иде. Шуңа да Зәкәрия галәйһиссәлам үзеннән соң дәгъват өчен борчылды. Аллаһ тәгалә Зәкәрия галәйһиссәламнең догасын кабул итте һәм аны Яхъя галәйһиссәлам белән ризыкландырды.

Бу күренеш хакында Коръәндә менә ничек әйтелә нәниләр (мәгънәсе): **«Вә Зәкәрияне дә хәтерләгез, Раббысына дога кылып әйтте: «Йә Раббым, мине баласыз ялгыз калдырма, бит Син варисләрнең иң хәерлесесең!». Аның догасын кабул иттек вә аңа Яхъяны бирдек вә аның хатыны бала тудырмый торган иде, тудыра торган кылдык, алар яхшы эшләргә ашыгучы булдылар вә Безнең хозурыбызда булган савапка кызыгып һәм куркып, дога кылалар иде һәм Бездән даим куркучы булдылар».** (Пәйгамбәрләр: 89 – 90)

Мәгънәсе: **«Кәф-һә-йә-гәйн-сад. (Мәгънәсен фәкать Аллаһ белер). Түбәндә укылачак аятьләр Раббыңның колы Зәкәриягә, Аның рәхмәтенең бәянедер. Зәкәрия** عليه السلام **теләгән нәрсәсен сораганда, Раббысына яшерен тавыш белән нида кылды. Әйтте: «Әй Раббым, минем сөягем зәгыйфьләнде вә башым ак чәчләр белән тулды вә мин Раббым, сиңа кылган догамнан кире кайтарылучы булмадым, һәрвакыт догамны кабул кылдың. Үлгәнемнән соң вәли булып калачак кемсәләрнең золым ителүләреннән куркамын, ә минем хатыным бала тудырмый торган кысыр булды, Үзеңнең фазылыңнан миңа бер изге бала бир! Ул бала миңа варис булыр вә Ягъкуп балаларына варис булыр. Йә Раббым! Ул улымны Үз каршыңда разый кыл!». Әй Зәкәрия, Без сине сөендерәбез бер малай белән, аның исеме Яхъя. Моннан элек ул исемдә һичкемне кылмадык. Әйтте Зәкәрия: «Әй Раббым, ничек минем улым булыр икән, хәлбуки хатыным кысыр, үзем картлыкның ахыр чигенә**

**җиттем». Аллаһ әйтте: «Әйе, эш син әйткәнчәдер, ләкин синең Раббың болай әйтте: карт көнегездә сездән бала китерү Миңа бик җиңел, тәхкыйк, Мин сине халык кылдым Яхъядан элек, син ул вакытта һич нәрсә түгел идең».** (Мәрьям: 1 – 9)

Зәкәрия галәйһиссәламнең бу хәле безгә гаҗәеп булып күренә, газиз балалар. Чөнки ул үзе дә вә аның хатыны да зур яшьтә иделәр. Ләкин, Аллаһның кодрәте чиксез, ни теләсә шул була. Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасыннан белгәнегезчә нәниләрем. Исхакъ галәйһиссәлам дә, әтисе Ибраһим вә әнисе Сара зур яшьтә булганда дөньяга килде. Без моңа хак иман белән ышанырга тиеш, чөнки һәрнәрсә Аллаһ теләге буенча (мәгънәсе): **«Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать: «Бар бул!», — дип әйтер һәм ул нәрсә булыр».** (Йәсин: 82)

Зәкәрия галәйһиссәлам бу хәбәргә бик тә шатланды һәм: «Әй Раббым! Минем хәләл җефетем Яхъя белән авырлы булса, миңа шуны белер өчен бер галәмәт бир», — дип сорады. Аллаһ тәгалә аңа: «Әгәр синең хатының Яхъя белән авырлы булса, син кешеләр белән өч көн вә өч төн сөйләшә алмассың, бары тик ишәраләр белән генә аңлашырсың. Шунда син, хатының Яхъяга авырлы икәнен белерсең һәм Мине бөекләп зикер вә тәсбихлар кылырсың», — диде.

Шулай, күпмедер вакыт узгач, Зәкәрия галәйһиссәлам кешеләрне изгелеккә өндәргә дип чыкса, кинәт кенә сөйләшә алмый башлады. Ул үзенең хатынының Яхъя белән авырлы икәнен аңлап, Раббысына күп итеп зикер-тәсбихләр кылырга тотынды.

Көннәр артыннан көннәр узды. Зәкәрия галәйһиссәламнең хатыны бик тә матур вә сөйкемле бала тапты.

Бу күренеш Коръәндә менә ничек тасвирлана кадерлеләрем (мәгънәсе): **«Зәкәрия ﷺ әйтте: «Әй Раббым, хатынымның балага калганлыгын белдереп миңа бер галәмәт бир!». Аллаһ әйтте: «Галәмәт сиңа шул булыр, чирләмәгән хәлеңдә, тоташтан өч кич кешеләр белән сөйләшә алмассың». Гыйбадәт йортыннан чыгып кавеме янына барды сөйләшә алмый иде, иртә вә кичке намазларны укырсыз вә тәсбихлар әйтерсез, дип, кавеменә ишарәт илә аңлатты».** (Мәрьям: 10 – 11)

Шулай итеп көннәр, айлар, еллар узды. Яхъя галәйһиссәлам дөньяга килеп үсә төште. Ләкин, ул башка балалар кебек булмады. Аллаһ тәгалә аны изге, тәкъва балалардан кылып, хикмәт вә башка күркәм сыйфатлар белән дә нигъмәтләгән иде. Яхъя галәйһиссәлам әти-әнисенә карата бик тә йомшак вә тыңлаучан булып, беркайчан да тәкәбберләнмәде, каршы дәшмәде, аларга гел дә күркәм холык белән җавап бирә торган иде.

Газиз нәниләрем! Без дә Яхъя галәйһиссәламнән үрнәк алып әти-әниләребезгә карата игелекле, рәхимле булып үсәргә тиешбез. Әгәр дә алар Аллаһ тәгаләнең шәригатенә каршы чакырмасалар, әйткәннәрен, кушканнарын уфтанмыйча тыңлап үтәргә, нәсыйхәтләрен кабул итеп әти-әниебезгә мәрхәмәтле булырга тиешбез. Чөнки алар безнең бу дөньяга килүебезгә сәбәпчеләр, без дөньяга килгәч

үзләре ач булса да безне ашаттылар, төннәрен йокламыйча безне юаттылар.

Яхъя галәйһиссәламнең ошбу күркәмлеге хакында АллаһтәгаләКоръәндәменәнәрсәәйтәкадерлеләрем (мәгънәсе): **«Әй Яхъя! Ал Тәүратны ныклап, куәт белән! Вә Без Яхъяга сабый чагында хикмәт, гыйлем бирдек. Без Яхъяга бирдек рәхимле булуны, күңел йомшаклыгы һәм көферлек, мөшриклек вә гөнаһ кереннән пакьлекне бирдек. Вә ул, Аллаһтан куркучы, тәкъва булды. Вә ата-анасына изгелек итүче иде вә ул, Аллаһка гөнаһ кылучы булмады һәм тәкәбберлек кылмады. Вә Яхъяга туган көнендә вә үлгән көнендә һәм дә кабердән кубарылган көндә Аллаһтан сәламнәр булды».** (Мәрьям: 12 – 15)

Аллаһ тәгалә Яхъя галәйһиссәламнең йөрәген фәкыйрьләргә һәм мескеннәргә, авырлыкта булган төрле хайваннарга карата мәхәббәт белән тутырды. Ул үзе ач кала торган булса да, янындагы ризыкны мохтаҗларга бирде. Әтисеннән соң кешеләрне Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыруын дәвам итте һәм бу изге эштә һичкемнән курыкмады.

Бәнү Исраил кавеме (яһүдләр) Яхъя галәйһиссәламнең һичкемнән курыкмыйча тәүхидкә, Бер Аллаһка гына өндәвен күреп, аны үтерергә мәкерлек кора башладылар. Шәйтан аларның бу эшләрен яхшы итеп күрсәтеп, бөтенләй туры юлдан адаштырды.

Балалар! Ни өчен соң Бәнү Исраил кавеме шул кадәр Яхъя галәйһиссәламне үтерергә теләделәр?


Әйе, башка пәйгамбәрләргә дә дошманлык кылган кебек, алар Яхъя галәйһиссәламне дә тәүхидкә, Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырып, җир йөзендә гаделлек таратканы өчен генә аны үтерергә теләделәр. Чөнки гаделлек булса, ул мөшрикләр, кәферләр үзләренең нәфселәре теләгән хәрам вә башка Аллаһ тәгалә шәригатендә тыелган нәрсәләрне эшли алмыйлар.

Чынлыкта да, балалар, Бәнү Исраил кавеме башка бик күп пәйгамбәрләрне үтергән кебек үк, Яхъя галәйһиссәламне дә үтерделәр. Шулай көферлек кылып, кешеләрне хак юлдан station аздырып һәм пәйгамбәрләрне үтергәннәре өчен, Аллаһ тәгалә аларны мескенлеккә вә түбәнчелеккә салды. Аларга Раббыларының ачу-нәфрәте иреште.


Бәнү Исраил кавеме үтергән башка пәйгамбәрләр кебек үк, Яхъя галәйһиссәлам дә шәһид булып үлде. Яхъяга туган көнендә вә үлгән көнендә һәм дә кабердән кубарылган көндә, Аллаһтан сәламнәр булды.

Инде, кадерле нәниләрем, Зәкәрия белән Яхъя галәйһиссәлам кыйссалары шуның белән тәмам. Аллаһ раббыбыз ошбу күркәм пәйгамбәрләребезнең тормышларыннан файдалар алып, дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле итсә иде. Әмин!

Газиз балалар! Киләсе пәйгамбәр тормышына сәяхәт кылганчы сезнең белән саубуллашып торабыз. Вәссәләму галәйкум вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!


Яхъя
галәйһиссәлам
Зәкәрия
галәйһиссәлам
Дан
Мәслим
Садук
Хашбан
Давыд
Сөләйман
Мәслим
Сыйддыйка
Бирихья
Бәлгата
Нахур
Шалум
Юһфәшит
Инәмин
Рәхәбгам
Сөләйман
галәйһиссәлам
Давыд
галәйһиссәлам
Буын
Пәйгамбәр
Зәкәрия һәм Яхъя
галәйһиссәламнәр-
нең нәсәбе


Мерсин
Искендерун
Антакья
Хәләб
(Алеппо)
Евфрат елгасы
Кипр
Урта диңгез
Триполи
Бәгләбәк
Бәйрут
Димәшкъ
Шам(Сурия) чүле
Хайфа
Тиверия
Иордан елгасы
Яффә
Әл-Кудс
(Иерусалим)
Амман
Әл-Хәлил
(Хеврон)
Үле диңгез
Бир-әс-Сәбг
Сәдүм
Нәгев чүле
Зәкәрия
галәйһиссәлам


Урта диңгез
Литани елгасы
Димәшкъ
Сайда
Хайфа
Тиверия
Иордан елгасы
Амман
Шам(Сурия) чүле
Яффә
Әл-Кудс
(Иерусалим)
Үле диңгез
Әл-Хәлил
(Хеврон)
Бир-әс-Сәбг
Сәдүм
Негев чүле
Яхъя
галәйһиссәлам

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Бәнү Исраил кавемендә бозыклык, золым, фәсәд, җинаятьчелек һәм башка бик күп гөнаһлы эшләр киң таралган иде.

**2)** – Шәйтан бәнү Исраил кавеменең акылларын яулап алу сәбәпле, алар Тәүрат китабын үзгәрттеләр, пәйгамбәрләрне үтерделәр һәм шул сәбәпле Аллаһ тәгалә аларны мескен вә түбәнчелек хәленә төшерде.

**3)** – Гыйммранның хатыны бала белән ризыклануын бик тә теләде һәм ул баланы әл-Әкъса мәчетенә хезмәт итәргә бирер идем дип, нәзер кылды.

**4)** – Гыймран изге-салих кешеләрдән булды. Ул үлгәч аның кызы Мәрьямне Зәкәрия عليه السلام карамакка алды.

**5)** – Мәрьям изге-салиха хатыннардан булып, Аллаһка бик тә күп гыйбадәт кыла торган иде.

**6)** – Аллаһ тәгалә кодрәтенең иге-чиге юк һәм Ул нәрсә теләсә — шул була.

**7)** – Зәкәрия галәйһиссәлам Аллаһ тәгаләдән бала сорап дога кылды һәм аны Аллаһ, Яхъя галәйһиссәлам белән ризыкландырды.

**8)** – Яхъя галәйһиссәлам тәкъва булып, бик күп күркәм сыйфатлар белән сыйфатланды. Әти-әнисенә карата йомшак холык вә итагатьлек белән аерылып торды.

**9)** – Аллаһ тәгалә Яхъя галәйһиссәламнең йөрәген фәкыйрьләргә вә мескеннәргә карата мәрхәмәтлелек вә шәфкатьлек белән тутырды.

**10)** – Яхъя галәйһиссәлам кешеләр арасында гаделлек тарата башлагач, Бәнү Исраил кавеме аңа карата дошманлык белдерде һәм кабахәт мәкерлек кылып аны үтерделәр.

**11)** – Бәнү Исраил кавеме тарафыннан үтерелгән башка пәйгамбәрләр кебек үк, Яхъя галәйһиссәлам дә шәһидләрдән үлде.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Гыймран нинди кешеләрдән иде?

**2)** – Гыймранның хатыны нинди нәзер кылды?

**3)** – Әгәр дә бер кеше нәзер кылса, ул нишләргә тиеш?

**4)** – Мәрьямне үз карамагына кем алды?

**5)** – Яһүдләр нинди китапны бозып үзгәрттеләр?

Дөрес җөмләләргә ( √ ) ошбу билгене, ә хаталы җөмләләргә ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Гыймран Аллаһка гыйбадәт кылучы, изге-салих кешеләрдән иде (  )

**2)** – Зәкәрия галәйһиссәлам Гыйрак әһеленә җибәрелгән пәйгамбәрләрдән булды (  )

**3)** – Бәнү Исраил кавеме шул кадәр адаштылар ки, хәтта Тәүрат китабын да үзгәрттеләр (  )

**4)** – Әл-Әкъса мәчетендә Мәрьямне Идрис عليه السلام үз карамагына алды (  )

**5)** – Зәкәрия عليه السلام Раббысыннан бала сорап дога кылды һәм Аллаһ тәгалә аның догасын кабул итте ( )

Буш урыннарга тиешле сүзләрне куй:

Зәкәрия عليه السلام ........... янына кергәч, аның табынында ............. көне җәйге җимешләрне, ә җәй көне ........... җимешләрне күреп: «Бу синдә каян?», — дип сорагач, Мәръям: « ........... тәгалә ризыкландыручы», — дип җавап кайтарды.

# Гыйсә ﷺ

Кадерле вә газиз балалар! Инде бу китабыбызны шушы пәйгамбәр тормышына сәяхәт белән тәмамларбыз. Чөнки Гыйсә галәйһиссәламнән соң килүче пәйгамбәр, ул — Мөхәммәд ﷺ. Ул инде барча галәмгә, кешеләргә дә, җеннәргә дә җибәрелүче соңгы пәйгамбәр буларак, без аның тормышына аерым тукталып, аны яңа бер китап итеп чыгарырбыз, иншәАллаһ. Ә хәзергә нәниләр, Гыйсә галәйһиссәлам тормышына сәяхәтне башлыйбыз.

Мәрьямнең әтисе дә һәм әнисе дә изге-салих кешеләрдән иделәр. Әнисе нәзер кылуынча, аны әл-Әкъса мәчетенә илтеп тапшыргач, Мәрьямне үзенә карамакка дип, Зәкәрия галәйһиссәлам алды. Бераз үсеп, әйберләрне аера башлагач, Зәкәрия галәйһиссәлам Мәрьям өчен әл-Әкъса мәчетендә, аерым махсус урын әзерләде. Мәрьям гел дә мәчеткә карата булган йөкләмәләрен үтәгәч, үзенә билгеләнгән махсус бүлмәгә кереп, Раббысына гыйбадәт кыла торган иде. Аның күркәм әхлагы, пакьлеге вә гыйффәтлеге башкаларга яхшы үрнәк булды.

Бер көнне, ул үзенең гыйбадәт кыла торган бүлмәсендә, аны чакыручы тавыш ишетте (мәгънәсе): **«Фәрештәләр әйтте: «Әй Мәрьям, дөреслектә,**

**Аллаһ сине сайлады вә сине гөнаһтан пакьләде һәм бөтен дөнья хатыннарыннан сине өстен кылды. Әй Мәрьям, Раббыңа итагать кыл һәм рөкүгъ, сәҗдә кылып намаз укучылар белән намаз укы!».** (Әли Гыймран: 42 – 43)

Аллаһ тәгалә Мәрьямне дөньяда иң хәерле хатын-кызлардан кылды һәм аны күркәм сыйфатлар белән сыйфатлады. Шулай көннәрнең берендә, аның каршына бик гүзәл бер ир-ат пәйда булды. Нишләргә? Кем ул? Мәрьям аптырап калды. Юк, монда ниндидер сер, ниндидер могҗиза булырга тиеш! Мәрьям куркып вә аннан читләшеп кенә (мәгънәсе): **«Мин синең явызлыгыңнан Аллаһка сыгынамын, әгәр син тәкъва булсаң, миңа якын килмә», — диде».** (Мәрьям сүрәсе 18нче аять)

Ләкин, ул Мәрьямнең күңелен тынычландырып: «Әй Мәрьям! Курыкма, мин Аллаһның илчесе, фәрештә Җибрил, Раббыңның әмере белән сине зәки-пакь бер бала белән шатландырырга килдем», — диде. Мәрьямнең ул баланы табуы гаҗәеп могҗизалардан булды һәм белүебезчә, могҗизаны һичкем булдыра алмый, бары тик Аллаһ тәгалә генә. Ул Җибрил фәрештәдән сорый башлады: «Ничек инде аның кияүгә чыкмаган килеш баласы булсын һәм ул фәхишәлектән дә пакь, аңа һичбер ир-атның кулы тигәне юк? Бу ни гаҗәп?».

Ләкин, белгәнебезчә балалар, Аллаһ бернәрсәнең булуын теләсә: «Бар бул!», — ди һәм ул була. Шулай бит, нәниләр?!

Бу Аллаһның әмере, тәкъдире белән. Аллаһ тәгалә ни теләсә — шул була, ул әмерне үзгәртү мөмкин түгел. Мәрьям моның шулай булуына хак иман белән инанып, тынычлап калды. Әгәр дә кеше үзен Аллаһка тапшырып, хакыйкый тәвәкәллек кылса, ул беләчәк, нинди генә авырлыктан соң булса да, аңа җиңеллек киләчәк һәм без моны Мәрьям кыйссасыннан күрәчәкбез.

Мәрьям авырлы булуын сизгәч, кешеләр аны кыерсытмасын дип, кавеменнән ераккарак читләште. Балалар, бу күренешләрне Аллаһ тәгалә Коръәндә менә ничек тасвирлый (мәгънәсе): **«Җибрил әйтте: «Мин Раббыңның расүлемен, сиңа гөнаһтан пакь бер бала һибә итмәк өчен килдем». Мәрьям әйтте: «Минем ничек балам булсын? Мине һичбер ир тотканы юк һәм мин зина кылучы да булмадым». Җибрил әйтте: «Әй Мәрьям, эш әлбәттә син әйткәнчә, ләкин Раббың әйтә: «Атасыз бала тудыру Миңа бик җиңел. Без аны атасыз тудырдык, кодрәтебезгә галәмәт булсын вә аңа ияргәннәргә рәхмәт булсын өчен, аның атасыз тууы әзәлдә хөкем ителгән әмер булды, әлбәттә, гамәлгә ашар. Мәрьям Гыйсәгә йөкле булды һәм кавеме аның хакында сүз йөртүдән куркып, алардан аерылып, ерак җиргә китте».** (Мәрьям: 19 – 22)

Аллаһ тәгалә фәрештәләре аша Мәрьямнең бу дөньяда да, ахирәттә дә югары дәрәҗәләргә ия булучы һәм бишектә үк кешеләр белән сөйләшүче изге баласы булуы белән шатландырды.

Коръән аятьләрендә бу хакта болай әйтелде (мәгънәсе): **«Фәрештәләр әйтте: «Әй Мәрьям,**

**Аллаһ сине бер бала белән шатландыра. Ул бала атасыз, Аллаһның: «Бар бул!», — дип әйтүе белән булыр, ул баланың исеме Гыйсә Мәрьям улы булыр. Ул бала дөньяда да һәм ахирәттә дә дәрәҗә иясе вә Аллаһка якыннардан булыр. Ул — Гыйсә, бишектә чагында һәм үсеп җиткәч кешеләр белән хикмәтле сүзләр белән сөйләшер һәм ул изгеләрдән булыр». Мәрьям әйтте: «Әй Раббым, миңа бала кайдан булсын, чөнки миңа ир затының кулы тигәне юк?». Әйтте: «Әнә шулай, Аллаһ Үзе теләгән нәрсәне халык кылыр. Бер нәрсәне булдырырга теләсә фәкать: «Бул», — дияр, ул нәрсә Ул теләгәнчә бар булыр».** (Әли Гыймран: 45 – 47)

Бала табу вакыты җиткәч, Мәрьям кешеләрдән ераграк китеп, бер хөрмә агачы янына утырды һәм бик тә кайгырган хәлдә: «Бу нәрсәләрне күрмичә вә мине искә алучы булмыйча онтылган булсам иде», — дип борчылуга төште. Ләкин Җибрил галәйһиссәлам аны тынычландырып, кайгырмаска кушты.

Кечкенәләрем, бу күренеш Коръәндә менә ничек сурәтләнә (мәгънәсе): **«Мәрьям Гыйсәгә йөкле булды һәм корсагындагы йөген күтәреп, кавеменнән аерылып, ерак җиргә китте. Бала табуның авырлыгы, китерде ул Мәрьямне хөрмә агачының кәүсәсенә. Мәрьям әйтте: «Бу хәлне күрмәс борын үлгән булып онытылып беткән булсам иде». Мәрьямнең урыныннан, түбән җирдән тавыш ишетелде: «Әй Мәрьям, кайгырма, тәхкыйк Раббың аяк астында чишмә кылды. Әй Мәрьям, хөрмә агачының кәүсәсеннән тотып үзеңә таба селкет, төшерер сиңа яңа өлгергән хөрмә җимешен. Ул**

**хөрмәне аша вә чишмә суын эч, ул улың Гыйсә белән күзең тынычланып, кайгың бетсен! Әгәр бер кеше балаң хакында синнән сораса, әйт: «Мин Аллаһ ризалыгы өчен һичкем белән сөйләшмәскә нәзер әйттем, шуның өчен бу көндә һичкем белән сөйләшмим», — диген».** (Мәрьям: 22 – 26)

Мәрьям Гыйсәне табып кавеме янына кайткач, кешеләр аның гыйффәтлегендә, пакълегендә шикләнеп төрле сүзләр сөйли башладылар һәм аңа: «Әй Мәрьям! Син ярамаган зур эш белән килдең. Син бит Һарунның тәкъва булган кыз кардәше һәм синең әти-әниең дә азгын кешеләрдән түгелләр иде. Ничек синең бала күтәреп килүеңне аңларга», — дип, аны кимсетеп кыерсыттылар. Мәрьям Раббысының әмеренә буйсынып, алар белән сөйләшмичә улы Гыйсә белән сөйләшергә дип, кавеменә ишарәт итте. Кешеләр, ничек инде бу бишектәге сабый белән сөйләшик дип аптыраштылар.

Менә монда кадерле балалар, Аллаһ тәгаләнең чиксез кодрәте вә изге бәндәләренә булган шиксез ярдәме чагылды. Мәрьям кешеләргә бишектәге Гыйсәгә ишарәт ясагач, алар аптырап калдылар. Ни гаҗәеп күренеш, бишектәге бала Аллаһның әмере белән телгә килде. Аларга ул — үзенең Аллаһ тәгаләнең колы булып, аңа Раббысы тарафыннан Инҗил китабы бирелүе, намаз вә зәкәт белән боерылуы һәм Аның Бәнү Исраил кавеменә җибәрелгән пәйгамбәр вә изгелек кылучы бәндә икәнлеген әйтте.

Нәниләрем, бу хакта Коръәндә ничек әйтелгәнен тыңлап карыйк (мәгънәсе): **«Мәрьям, улы Гыйсә**

**белән сөйләшергә ишарәт итте. Алар әйттеләр: «Безне мәсхәрә итәсең, бишектәге сабый бала белән ничек сөйләшик?». Гыйсә аларның сүзләрен ишеткәч, әйтте: «Мин Аллаһ тәгаләнең колымын, Ул миңа китап бирде һәм мине пәйгамбәр итте. Кайда гына булсам да кешеләр өчен мине мөбарәк вә файдалы итте вә миңа тере булган вакытымда намаз укырга һәм зәкәт бирергә әмер итте. Янә анама изгелек итүче кылды, мине тәкәбберләнүче вә үзенә гөнаһ эшләүче кылмады. Туган көнемдә вә үлгән көнемдә һәм кабердән кубарылган көнемдә Аллаһтан миңа сәлам».** (Мәрьям: 29 – 33)


Бишектәге баланың сөйләшүе турындагы хәбәр кешеләр арасында таралды. Ул җирдәге яһүдләр бу баланың пәйгамбәр булуын белеп калдылар. Үзләренең кабахәт эшләреннән булган Тәүратны үзгәртүләре вә аларның кешеләргә золым кылган гамәлләре ачыклануы мөмкин дип, алар Мәрьямгә вә Гыйсә галәйһиссәламгә каршы төрле мәкерлекләр кыла башладылар. Гыйсә галәйһиссәлам хакындагы хәбәрләр шулай ук патшага да барып җитте. Ул да үзенә карата Гыйсә галәйһиссәламнән куркыныч киләчәген сизеп, сихерчеләре вә күрәзәчеләре белән киңәшләшеп, аны үтерергә кирәк дип, карар кылды.


Мәрьям янына бер кеше килеп, бу нәрсәләрдән хәбәр бирде һәм Фәләстыйн җирен ташлап Мисыр җиренә күчеп китәргә кушты.

Мәрьям кечкенә Гыйсәне алып, Мисыр җиренә күчеп китте һәм Гыйсә عليه السلام үсеп ныгыганчы, шунда калды.

Аллаһ тәгалә Мәрьямгә Гыйсәне алып Фәләстыйн җиренә кайтырга кирәклеген белгерткәч, ул улы белән кире Фәләстыйнга кайтты. Гыйсә галәйһиссәлам намазлар укып Раббысына гыйбадәттә булды. Үзе белән бер вакытта яшәгән әнисенең апасының улы Яхъя галәйһиссәлам белән, бик тә якын дус булдылар. Яхъя галәйһиссәламне яһүдләр үтергән вакытта, Гыйсә галәйһиссәлам "ӘнНасыйра" дигән авылда гыйбадәт кыла торган иде. Көннәрнең берендә, ул шул хәлендә гыйбадәттә булганда, Аллаһ тәгалә аңа кешеләрне гаделлек белән хөкем итәр өчен, Җибрил галәйһиссәламне изге китап "Инҗил" белән җибәрде. Шулай ук аңа, Бәнү Исраил кавемен гөнаһлы гамәлләрдән тыярга вә бер Аллаһка гына иман китерүләренә өндәргә әмер итте.

Гыйсә галәйһиссәлам Раббысының әмеренә буйсынып, кешеләрне бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга өнди башлады. Аллаһ тәгалә аны бу изге гамәлендә, аның дәгъватенең, сүзенең хак икәнлеген белгертүче бик күп могҗизалар белән ныгытты. Гыйсә галәйһиссәламгә бирелгән зур могҗизалардан — аның сукырларны, ала тән чире белән авыручыларны дәвалавы, үлеләрне терелтүе һәм башкалар булды.


Гыйсә
галәйһиссәлам
Мәрьям
Гыймран
Исегездәме соң, Мәрьям утлы Гайсә:
— Әй, Исраил токымы, мин Аллаһның сезгә җибәргән илчесе буламын, миннән алда килгән Тәүратны дәресләүче вә миннән соң да киләчәк Әхмәт исемле бер пәйгамбәр турында сөенечле хәбәр китердем, — диде. Бу хакта ул ышанычлы дәлилләр китергәч, алар:
— Бу — көн кебек ап-ачык бер сихер, — диделәр. Саф 6.
Мәсәнә
Әлгәзир
Илюр
Ихтәр
Садук
Гаязур
Әлякыйм
Ибуд
Зирянил
Шәлтәл
Юхинә
Биршә
Әмун
Мишә
Хизкия
Әхаз
Мүнәм
Газрия
Юрам
Биһфәшит
Ишә
Ибә
Рәхәбгам
Сөләйман
галәйһиссәлам
Давыд
галәйһиссәлам
Буын
Пәйгамбәр
Гыйсә галәйһис-
сәламнең нәсәбе


Гыйсә галәйһиссәлам
Урта диңгез
Димәшкъ
Амман
Иордан елгасы
Үлә диңгез
Әл-Кудс
Бәйт-Ләхм
Бир-әс-Сәбг
Хайфа
Ән-Насыйра
Газа
Нәгәв чүле
Гакаба култыгы
Әл-Гәриш
Синай
Тур тавы
Сүәеш (Суэц) култыгы
Әче күл
Каһирә
Гелиополис
Мемфис
Мисыр
Искәндәрия
Нил елгасы

Бу хакта Коръәндә менә ничек диелде (мәгънәсе): **«Аллаһ Гыйсәгә язу белемен, шәригать хөкемнәрен һәм Тәүрат, Инҗил китапларын өйрәтте. Вә Бәнү Исраилгә расүл кылды һәм әйтте: «Мин сезгә Раббыгыздан пәйгамбәр булуыма ачык дәлилләр һәм галәмәтләр белән килдем. Ул галәмәтләрнең берсе: балчыктан кош сурәте ясармын да аңа өрермен, Аллаһ әмере белән кош булып очар. Янә Аллаһ әмере белән сукырларны күзле итәрмен, ала тәнле кешеләрне сәламәтләндерермен һәм үлекләрне тергезермен. Янә мин сезгә нәрсә ашаганыгыздан, өйләрегездә яшереп саклаган нәрсәләрегездән хәбәр бирермен. Бу нәрсәләрдә, әлбәттә, минем пәйгамбәрлегемне раслаучы галәмәтләр бар, әгәр хаклыкка ышанучылардан булсагыз». Миннән әүвәл иңдерелгән Тәүратны раслаучы булып һәм сезгә хәрам булган нәрсәләрнең кайберләрен хәләл иткәнем хәлдә, Раббыгыздан галәмәтләр белән сезгә пәйгамбәр булып килдем. Аллаһтан куркыгыз, миңа итагать итегез һәм карышудан сакланыгыз! Дөреслектә, Аллаһ мине дә, сезне дә тәрбия кылучы. Тәрбияче булган Аллаһка, әлбәттә, гыйбадәт кылыгыз! Бит Аллаһка итагать итү һәм Аңа гына гыйбадәт кылу — иң туры юл».** (Әли Гыймран: 48 – 51)

Ләкин, кешеләргә бик күп золым кылган, Тәүратны үзгәрткән кабахәт яһүдләр, бу могҗизаларны сихер, дип, үзләренең Гыйсәгә каршы булган мәкерлелекләрен тормышка ашыруда уңайлы форсат көттеләр. Никадәр генә изалап-җәфаласалар да, ул зур сабырлык күрсәтте. Бер төркем кеше аңа иман ките-

реп, аның шәкертләреннән, иярченнәреннән булды. Ул төркем кешеләр Коръәндә “хәварийуннар” дип исемләнә. Аллаһ тәгалә аларны дошманнарына каршы ярдәм белән ныгытты.

Бу күренеш хакында Коръәндә болай әйтелде (мәгънәсе): **«Ий мөэминнәр, Аллаһ дине — Исламга ярдәм итүчеләр булыгыз, Мәрьям улы Гыйсә үзенә ияргән хәварийуннарга әйткән кебек: «Аллаһ дине — Исламны, кешеләргә таратырга, куәтләтергә миңа кем ярдәм бирә? Ихласлы хәварийуннар Аллаһ диненә без ярдәм бирүчеләрбез», — диделәр. Бәнү Исраилдән бер таифә иман китереп мөселман булдылар, вә бер таифә иман китермәделәр, кәфер булып калдылар. Иман китергән таифәгә куәт вә ярдәм бирдек, дошманнарын җиңеп өстен булырга һәм алар өскә чыгып Ислам динен тарату белән дөньяга фаш булдылар».** (Саф: 14)

Гыйсә عليه السلام кавеменә һәрвакыт нәсыйхәт кыла торган булды. Көннәрнең берендә хәварийуннар аңа: «Әй Гыйсә, синең Раббың безгә күктән ризык белән ашъяулыгы төшерә аламы?», — дип сорадылар. Гыйсә галәйһиссәлам аларга: «Аллаһтан куркыгыз, әгәр мөэминнәрдән булсагыз», — дип җаваплагач, алар: «Без ул ризыклардан ризыкланырга һәм дә күңелебезне тынычландырырга телибез», — диделәр. Гыйсә عليه السلام Раббысыннан сорап дога кылды һәм Аллаһ тәгалә аларга күктән ашъяулыгы белән табын төшерде.

Газиз балалар, Коръәндә менә ничек тасвирлана бу күренеш (мәгънәсе): **«Хәварийуннар әйттеләр:**

**«Әй Мәрьям улы Гыйсә, синең Раббыңның безгә күктән ашъяулыгы белән ризык иңдерергә көче җитәме?», — дип. Гыйсә әйтте: «Аллаһтан куркыгыз — газабыннан сакланыгыз, үзегезне бәлаказага салмагыз! Әгәр хак мөэминнәрдән булсагыз». Алар әйттеләр: «Күктән иңгән ризык белән ризыкланырга һәм күңелебезне тынычландырырга телибез, дәхи: «Мин Аллаһның расүле», — дигән сүзеңнең хаклыгын белмәкче булабыз, янә ул ризыкның Аллаһтан иңдерелгәнлегенә шаһитләрдән булуыбызны телибез». Мәрьям улы Гыйсә әйтте: «Әй тәрбиячебез — Аллаһ! Безгә күктән ашъяулыгы белән ризык иңдер, ризык иңгән көн әүвәлгеләребезгә дә һәм ахыргыларыбызга да бәйрәм көне булсын! Янә минем пәйгамбәрлегемә дә дәлил булсын! Әй Раббыбыз, безне ризыкландыр, Син, әлбәттә, ризыкландыручыларның иң хәерлесесең». Аллаһ тәгалә әйтте: «Мин, әлбәттә, сез сораганны күктән иңдерүчемен, ул сезгә иңгәннән соң сезләрдән берәрегез хыянәт итсә, яки шөкер итүне һәм Аллаһтан иңдерелгәнне инкяр кылып кәфер булса, ул кешене галәмнәрдә һичкемне газап кылмаган каты газап белән газап кылырмын».** (Мәидә: 112 – 115)

Гыйсә галәйһиссәлам кешеләргә, барча пәйгамбәрләрнең дә дәгъвате бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга өндәүдән гыйбәрәт булганын аңлатты. Ул үзен Мусаның عليه السلام шәригатен җимерергә түгел, ә тулыландырырга, дәвам итәргә җибәрелгәнен бәян кылды. Ул Бәнү Исраил кавеменә соңгы пәйгамбәр

булып, аңардан соң аларга һич пәйгамбәр булмаячагын, бары тик Гарәп ярымутыравыннан Мөхәммәд бин Габдуллаһның барча кешеләр вә җеннәр өчен пәйгамбәр булып киләсен хәбәр итте. Ул пәйгамбәр Исмәгыйль бин Ибраһим нәселеннән булып, кешеләр һәм җеннәр, каралар һәм аклар, көнчыгыштан алып көнбатышка кадәр булган һәммәсен хак юлга — Ислам юлына, бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешү юлына чакырачак. Ул ахыргы вә йомгаклаучы пәйгамбәр булып, аннан соң һичкемгә пәйгамбәрлек килмәячәген төшендерде. Әйткәнебезчә балалар, без Мөхәммәд ﷺ тормышын, аерым китап итеп язачакбыз, иншәАллаһ.

Ә хәзер, Гыйсә галәйһиссәламнең ошбу әйткәннәре хакында, Коръән аятьләрен тыңлап карыйк (мәгънәсе): **«Дәхи Мәрьям улы Гыйсә әйтте: «Әй Бәни Исраил, тәхкыйк мин Аллаһтан сезгә җибәрелгән пәйгамбәрмен, миннән элек иңдерелгән Тәүратныраслаучымын һәм миннән соң килә торган пәйгамбәр беләν сөенеч бирәм, аның исеме Әхмәд (Мөхәммәд) булыр», — диде. Мөхәммәд пәйгамбәр аларга аятьләр вә могҗизалар белән килде исә, бу ачык сихер диделәр».** (Саф: 6)

Гыйсә عليه السلام дәгъват кылган саен, аңа иман китереп артыннан иярүчеләр күбәйгәннән күбәйде. Бу хәлне күреп, яһүдләр вә аларның сихерчеләре вә күрәзәчеләре үзләренең Гыйсә галәйһиссәламне үтерергә корган мәкерлекләрен тормышка ашырыр өчен Фәләстыйндагы Рим патшасына барып: «Гыйсә галәйһиссәлам сиңа каршы фетнә әзерли, шуңа да үзенең янына иярченнәр җыя һәм без моны, аны

үтереп баганага тәре итеп кадаклап ассак кына туктата алабыз», — дип, Гыйсә галәйһиссәламгә яла якtылар.

Гыйсә галәйһиссәлам бу хакта хәбәрдәр булды. Ул үзенең шәкертләрен җыеп, аларга бу хәлне белгертте. Шулай ук, Аллаһ тәгалә Үзенең чиксез кодрәте белән аларны дошманнарыннан саклаячагын, Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылып, тәкъва булып, Ислам шәригатеннән әзгә генә дә тайпылмыйча яшәүләрен таләп итеп нәсыйхәт кылды.

Аллаһ тәгалә Гыйсә галәйһиссәламне Үзенә күтәрде. Яһүдләр аны үтерәбез дип Гыйсәгә охшаган икенче бер кешене үтереп, тәрегә кадакладылар һәм аны үтереп кадакладык, дип уйладылар.

Бу хакта Коръәндә менә ничек әйтелә, балалар (мәгънәсе): **«Янә аларны Аллаһ ләгънәт кылды: «Без, әлбәттә, Аллаһ расүле Мәрьям улы Гыйсәне үтердек», — дигән сүзләре өчен. Алар Гыйсәне үтермәделәр һәм асмадылар, ләкин аларның бер юлдашы аларга Гыйсә сурәтендә күренде. Яһүдләр, әлбәттә, Гыйсә хакында ихтилафта булдылар, әгәр Гыйсәне үтергән булсак, юлдашыбыз кайда? Әгәр юлдашыбызны үтергән булсак, Гыйсә кайда, диештеләр. Аларның бу ихтилафлары, әлбәттә, занга иярүләреннән булды, алар һичшиксез Гыйсәне үтермәделәр. Бәлки Аллаһ аны үз хозурына күтәрде. Аллаһ тәгалә һәр эштә галиб һәм хикмәт белән эшләүче булды».** (Нисә: 157 — 158)

Ошбу хәлләрдән соң Гыйсәнең عليه السلام шәкертләре өчкә бүленде. Беренчеләре: «Гыйсә عليه السلام ул — Аллаһ», — диделәр. Икенчеләре: «Гыйсә عليه السلام ул — Аллаһның улы», — диделәр. Бу ике төркем дә ошбу сүзләре белән кәфер булдылар. Ә өченче төркем, Гыйсә عليه السلام өйрәткәнчә: «Гыйсә عليه السلام ул — Аллаһның колы һәм Аның пәйгамбәре», — дип мөселман булып калдылар. Хәзерге көндә, бу өченче төркем юк инде балалар, чөнки аларның булганнары, соңгы пәйгамбәр Мөхәммәднең ﷺ дәгъвате белән, аңа иярделәр. Шуңа да, хәзерге заманда беренче вә икенче төркемнәр генә калды һәм алар, Исламга кергәнчегә кадәр — кәфер булып калалар.

Кадерле нәниләр! Гыйсәнең عليه السلام күккә күтәрелүе белән кыйссабызны тәмамлыйбыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәдисләрендә әйткәнчә, Гыйсә عليه السلام Кыямәт көне алдыннан төшәчәк һәм мөселманнар белән алдакчы Дәҗҗәлгә каршы сугышка чыгачак. Бу сугышта ул Дәҗҗәлне үтереп, тәреләрне сындырачак вә дуңгызларны үтереп, барча диннәрне батыл кылып, бердәнбер хак — Ислам диненә чакырачак. Гыйсә عليه السلام җир йөзендә кырык ел калачак. Бу чорда җир йөзендә бәрәкәт вә нигъмәтләр булачак.

Кадерле вә газиз балалар! Без сезнең белән ошбу урында пәйгамбәрләр тарихына сәяхәтебезне тәмамлыйбыз. Киләсе пәйгамбәребезнең тормышына аерым китапта сәяхәт кылырбыз. Белгәнегезчә ул пәйгамбәрнең исеме — Мөхәммәд ﷺ. Аллаһ тәгалә безгә бу күркәм пәйгамбәрләрдән үрнәк алып, гыйбрәтле тормышларыннан файда алып гамәл

кылырга насыйп итсен. Ахыргы урыннарыбызны Фирдәвес Җәннәтләреннән кылсын. Әмин!

**Беренче:** Бу кыйссадан алынган файдалар:

**1)** – Гыймранның кызы Мәрьям, Аллаһка гыйбадәт кылучы, тәкъва хатын-кызлардан булды.

**2)** – Аллаһ тәгалә Мәрьямне барлык җир йөзендәге хатыннарның иң хәерлеләреннән итте.

**3)** – Җибрил عليه السلام Мәрьям янына кеше сурәтендә килде.

**4)** – Аллаһ тәгаләнең кодрәтенең иге-чиге юк. Ул берәр нәрсә булуын теләсә, аңа: «Бар бул!», — дип кенә әйтә һәм ул шунда ук була.

**5)** – Аллаһның әмере белән Мәрьям Гыйсәгә йөкле булды.

**6)** – Мәрьям Гыйсәне табып кавеменә кире кайткач, алар аны начар сүзләр белән кыерсыттылар. Аллаһ тәгалә Үзенең чиксез кодрәте белән, әле яңа гына туган Гыйсәне могҗиза белән сөйләшәтереп, аның әнисенең гыйффәтле вә пакъ булуын күрсәтте.

**7)** – Гыйсә галәйһиссәлам әнисенә карата ягымлы вә яхшы холыклы булды.

**8)** – Гыйсә عليه السلام бишектә үк үзенең Аллаһ тәгалә колы һәм пәйгамбәре булганына шәһадәт бирде. Бу шәһадәт, насараларның Гыйсә галәйһиссәламне Аллаһның улы дип әйтүләрен юкка чыгарды.

**9)** – Яһүдләр Гыйсә галәйһиссәламнең пәйгамбәр икәнлеген белгәч, аны үтерергә дип кабахәт мәкерлекләрен кыла башладылар.

**10)** – Гыйсә галәйһиссәлам Бәнү Исраил кавемен Бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырды.

**11)** – Яһүдләр Гыйсәне үтерергә дип кылган мәкерлекләрен тормышка ашырырга теләгәндә, Аллаһ тәгалә Гыйсәне күккә күтәрде.

**12)** – Гыйсәнең عليه السلام шәкертләре өч төркемгә бүленде.

**13)** – Хәзерге вакытта булган яһүдләр һәм насаралар барысы да ялгышлыкта, чөнки алар Аллаһ иңдергән китапларны үзгәртеп, туры юлдан адаштылар.

**Икенче:** Үз-үзеңне тикшер:

Түбәндәге сорауларга җавап бир:

**1)** – Мәрьям Җибрилне күргәч нишләде?

**2)** – Мәрьям кавеменә кечкенә баласы белән кайткач, аны кавеме ничек каршы алды?

**3)** – Мәрьям үзен алардан ничек саклады?

**4)** – Яһүдләр Гыйсә галәйһиссәламгә иман китереп иярделәрме? Ни өчен?

**5)** – Гыйсәгә عليه السلام бирелгән могҗизалардан берничәсен әйтеп уз.

**6)** – Яһүдләр Гыйсәгә عليه السلام каршы нәрсә уйладылар?

Дөрес җөмләләргә ( √ ) ошбу билгене, ә хаталы җөмләләргә ( X ) ошбу билгене куй:

**1)** – Яһүдләр Гыйсәгә عليه السلام иман китереп, аңа ярдәм итәргә ашыктылар (  )

**2)** – Мәрьям янына Җибрил عليه السلام килгәч, ул аннан курыкты (  )

**3)** – Аллаһ тәгалә Гыйсә галәйһиссәламне яһүдләрнең кабахәт мәкерлекләреннән саклап калды ( )

**4)** – Аллаһ тәгалә Гыйсә галәйһиссәламне Мисырга, Фиргавен кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрде ( )

Җөмләләрне укы һәм астындагы иң дөрес җавап алдына ( √ ) ошбу билгене куй:

**1)** – Гыйсә галәйһиссәламнең тууы:

а) гади нәрсә иде

б) әнисе өчен зур шатлык иде

в) Мәрьямнең кавеменә сөенеч булды

г) Аллаһ тәгаләнең чиксез кодрәтен күрсәтүдә, кешеләргә дәлил булды

**2)** – Аллаһ тәгалә Гыйсә галәйһиссәламне:

а) Фиргавенгә җибәрде

б) Бәнү Исраилгә җибәрде

в) Фиргавен һәм Бәнү Исраилгә җибәрде

г) Барча кешеләргә җибәрде

**3)** – Яһүдләр Гыйсәгә عليه السلام каршы мәкерлелекләрен кылгач, аны:

а) үтерделәр

б) тәрегә кадакладылар

в) куып чыгардылар

г) Аллаһ тәгалә аны күккә күтәрде

# Йомгаклау

Әлхәмдүлилләһ, Аллаһның ярдәме һәм теләге илә хәерле вә изге гамәлләр тәмамлана. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә ﷺ һәм аның әһле-бәйтенә, сахәбәләренә вә Кыяматкә кадәр аңа ияргән барча мөэмин-мөселманнарга салават вә сәламнәребез булсын!

Аллаһ Раббыбыз барча кимчелек вә хаталарыбызны ярлыкап, ниятләребезне ихлас кылып, тәүбәләребезне вә кылган гамәлләребезне кабул итсен!

Без инде кечкенә дусларыбыз өчен «Балаларга пәйгамбәрләр тарихы» китабын тәмамладык, Аллаһ насыйп итсә, киләчәктә, шулай ук, карталар белән Сөекле Пәйгамбәребезгә багышланган һәм аннан соң Расулебезнең Сахәбәләренә багышланган аерым-аерым китап-дәреслекләребезне әзерләрбез.

Йә Аллаһ! Син калебләрнең Хуҗасы! Безнең калебләребезне Үзеңнең динеңдә ныклы кыл, һәм дә безне Фирдәвес Җәннәтләреңә керт!

## Эчтәлек

Кереш сүз........................................................3
Адәм галәйһиссәлам............................................10
Идрис галәйһиссәлам..........................................24
Нух галәйһиссәлам..............................................28
Һуд галәйһиссәлам...............................................41
Салих галәйһиссәлам..........................................49
Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһиссәламнәр.......63
Исхак галәйһиссәлам...........................................83
Лут галәйһиссәлам.............................................100
Ягъкуп галәйһиссәлам.........................................98
Йосыф галәйһиссәлам........................................106
Шөгайб галәйһиссәлам.......................................124
Әюп галәйһиссәлам............................................137
Зүл-Кифел галәйһиссәлам..................................144
Муса галәйһиссәлам...........................................148
Һарун галәйһиссәлам..........................................175
Давыд галәйһиссәлам.........................................181
Сөләймән галәйһиссәлам....................................194
Юныс галәйһиссәлам..........................................210
Ильяс галәйһиссәлам..........................................218
Әльясәгъ галәйһиссәлам.....................................225
Зәкәрия һәм Яхъя галәйһиссәламнәр................230
Гыйсә галәйһиссәлам..........................................245